С.Б...
F27

МӘЖИТ ГАФУРИ

САЙЛАНМА
ӘСӘРЛӘР

50890

МӘКТӘП КИТАПХАНӘСЕ

Г28.

МӘҖИТ ГАФУРИ

САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

ШИГЫРЬЛӘР, МӘСӘЛЛӘР, ХИКӘЯЛӘР

50890

ТАТКНИГОИЗДАТ
ЯШЬЛӘР-БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ РЕДАКЦИЯСЕ
КАЗАН 1954

☆

Редакторлары
Д. ЗӨБӘЕРОВА, Р. ДАУТОВ

☆ ☆

Тышлык художнигы
М. ВИНОГРАДОВА

☆

УРТА ҺӘМ ОЛЫ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН

М. ГАФУРИ

ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ

(на тат. языке)

Художество редакторы *Э. Дьячкова*
Техник редакторы *М. Шәрәфетдинова*
Корректорлары *М. Мирсалихова һәм И. Уразова*

Наборга бирелде 13/X-1953 ел. Басарга кул куелды 13/II-1954 ел. ПФ 01056.
Кәгазь форматы $84 \times 108^1/_{32}$-5,19 к. т. Учет-изд. 14,60 таб. Басма табак 17,01.
Табакта 44.000 хәреф. Заказ № 0344. Тираж 10000. Бәясе 6 сум 90 тиен.

ТАССР Министрлар Советы янындагы Полиграфия промышленносте,
издательстволар һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең Татполиграф
типографиясе. Казан, Миславский ур., йорт 9.

ШИГЫРЬЛӘР

ХӨРРИЯТ ИРТӘСЕ

Тордым иртән... Көн матур, балкып тора,
Сайраша кошлар, адәмнәр кычкыра...

Гүя, күктән җир йөзенә нур ява.
Ник болай бу?.. Нәрсә булган дөньяга?..

Бер дә бәйрәмсез вакыт бәйрәм көне...
Агыла алга кешеләр төркеме...

Шатлыгымнан белмимен ни эшләргә дә,
Белмимен туктарга да, китәргә дә!..

Әй, халык шат!..
Һәммәсе уйный, көлә...
Каршыдан балкып кызыл байрак килә!..

Эшчеләрнең ирләре һәм кызлары
Җырлыйлар бердән азатлык җырлары...

Җырлыйлар бердән болар шатлык белән,
Бер-берсен котлый азатлык белән.

Бер карыймын: бу халыкның шатлыгын,
Барча хәсрәт, кайгыдан азатлыгын.

Бер карыймын шатланып ал якка мин,
Җилфердәп килгән кызыл байракка мин.

Һәм сорыйм:
— „Бу нинди шатлык, нинди эш!"
— „Патшаның тәхете җимерелгән!.." имеш.

— Бар залимнәр зир-зөбәр[1] килгән имеш,
Бар явызлар төрмәгә кергән имеш!..

---

[1] Зир-зөбәр — асты-өскә.

Беткән икән бу әсарәт[1] зынжыры,
Жырлана икән шуңа „Хөррият жыры“...

Белдем эшнең аслын инде, бетте гәп[2],
Мин дә жырлыйм шатлыгымнан бергәләп...

„Канлы байраклар“ югары селкенә,
Саф йөрәкләр сөенеченнән җилкенә...

Оныта алмам мәңге бу шатлык көнен...
— Яшәсен чын хөррият! — Актык сүзем.

1917

---

[1] Әсарәт — коллык.
[2] Гәп — сүз.

БЕТСЕН СУГЫШ

Без ирекле, без граждан, һәммәбез шат, без азат,
Тик әнә анда һаман кан, куркыныч, көн-төн җиһад[1].

Монда без кешелек өчен „һәркем тигез булсын!..“
дибез,
Анда шәһәрләр, авыллар җир белән булган тигез.

Монда хөррият авазы җирне, күкне яңгырата,
Анда безнең күп туганнар тилмереп телсез ята.

Анда хәсрәт, анда кайгы, анда кан һәм күз яше,
Анда мылтык, анда сөнге, анда тик туп ядрәсе.

Андагы безнең туганнар туп ата бер-берсенә,
Кырыла анда нинди җаннар, каннары җиргә сеңә.

Ул туганнарның кулын чишең, алар булсын азат,
Кычкырыйк без берьюлы: „Бетсен сугыш!..
Бетсен җиһад!..“

1917

---

[1] Җиһад — сугыш.

КЫЗЫЛ БАЙРАК

Кара син алга!
Күрәмсең анда:
Кызыл байракны
Буялган канга.

Көчле эшчеләр
Күтәргән аны,
Буялган аңа
Шаһитлар каны.

Хөрлек, тигезлек
Аның шигаре[1],
Һәммә байрактан
Тора югары.

Шунда хакыйкать,
Шунда чын иман[2],
Кузгал эшчеләр!
Таң калсын җиһан[3].

Иткән тәҗәссем[4]
Халыкның көчен,
Бу кызыл байрак
Шуның билгесе.

Кузгал, эшчеләр!..
Дошман җиңелсен,
Көч кемдәлеген
Бар дөнья белсен.

---

[1] Шигар — лозунг.
[2] Иман — ышану.
[3] Җиһан — дөнья.
[4] Тәҗәссем иткән — гәүдәләндергән.

Кара көчләргә
Каршы торган ул,
Бирде бу юлда
Миллион корбан ул.

Бөтен кара көч
Аннан җиңелде,
Шуның өчен бүген
Югары эленде.

Бүген патша ул
Бөтен дөньяга,
Аңа нинди көч
Каршы тора ала?

Егылды инде
Башка әләмнәр,
Җиңелде инде
Залим адәмнәр.

Әй кызыл байрак,
Нур бир җиһанга!..
Әйдә, эшчеләр,
Алга вә алга!..

1917

ИРЕКЛЕ КӨННӘР

Әй, кояш! Арттыр нурыңны,
Җир йөзен тизрәк эрет!..
Батма, яктырт, бар урынны
Чәчкәләр белән өрет...

Әй, матур ай! Син дә тиз тул!
Дөнья булсын яктырак,
Тагы да артык нурлырак бул,
Җиргә кил син якынрак!..

Кичке җил, син мөнтәзам[1] ис!
Чәчкәләрне көлдереп,
Аңкысын дөньяга хуш ис,
Төрле яктан бөркелеп.

Әй, кызыл кыз! Елмаеп көл,
Бир матурлык дөньяга,
Чәчкә ат та, әй кызыл гөл,
Син шуларны сип аңа.

Белдегезме, нәрсә әйттем,
Әй кояш, кыз, җил вә ай,
Һәммәгез бизәнегез сез
Мин ничек куштым, шулай.

Таки хөррият көнендә
Нурланып торсын җиһан,
Һәр кеше күрсен бу эшне
Һәм китерсен чын иман.

Шул матурлыклар эчендә
Шатланыйм мин, рухланыйм,

[1] Мөнтәзам — тәртипле.

Көндезендә һәм кичендә
Сызланыйм, балкып яныйм.

Их күңелле!.. Нинди шатлык!..
Шунда торсак бергәләп,
Мәңгегә килсен азатлык,
Мин калыйм шунда әбәд [1].

1917

---

[1] Әбәд — мәңге.

АЖДАҺА

(Корнилов фетнәсе мөнәсәбәте белән язылган иде)

Хөррият байрагыдыр тотканыбыз,
Әйдә шул юлда түгелсенканыбыз,
Кызганыч түгел бөтен мал-җаныбыз —

Әһле хөррият, тагын кузгалыгыз!..
Баш күтәрмәкче була дошманыгыз...

Бакчы! Дошман үлмәгән, ул кузгала,
Хөррият җимешен халыктан кызгана,
Акрын-акрын канлы кылычын кулга ала —

Әһле хөррият, тагын кузгалыгыз!..
Баш күтәрмәкче була дошманыгыз...

Хөррият әһлен алар җиңмәкчеләр,
Кол итеп безне һаман измәкчеләр,
Эшчеләрне әт итеп җикмәкчеләр —

Әһле хөррият, тагын кузгалыгыз!
Баш күтәрмәкче була дошманыгыз...

Канлы байракларны тәкрар кулга алыйк,
Ул явыз дошманга каршы кузгалыйк,
Хөррият җырларыны җырлап барыйк —

Әһле хөррият, тагын кузгалыгыз!..
Баш күтәрмәкче була дошманыгыз...

Мәңгегә үтерелсен ул зур „аждаһа“,
Баш күтәрмәслек булып бу дөньяга,
Бу халыкларга бирелсен чын бәһа —

Әһле хөррият, тагын кузгалыгыз!..
Баш күтәрмәкче була дошманыгыз...

1917

ХӨРРИЯТКӘ КАРШЫ ТОРУЧЫЛАРГА

Хакыйкатьне әйтер чак,
Тик тору бик зур гөнаһ.
Халык мескен уенчык,
Кем көчле, шул булды илаһ.

Халыкның иркен алып,
Акрын-акрын басалар,
Алга бармыйм мин дисәң,
Артта тотып асалар.

Чын сүзне әйтүчегә
Дөнья тар, тел көрмәлә,
„Бетсен сугышлар!“ дисәң,
Ябалар тотып төрмәгә.

Ике халык арасын
Канлы пәрдә каплаган,
Мескен адәм баласын
Кемнәр соң елатмаган...

Җитәр инде алдашу!..
Юк! Бу бетәргә тиеш;
Барсын әнә үзләре!
Кирәк дисәләр бу „эш“.

Халык кулы күтәргән
Кызыл байрак аумасын,
Пычрак куллар пычратмасын
Инсаният дөньясын...

1917

АЗАТЛЫК ХӨРМӘТЕНӘ

... Яп-яңа, чиксез караңгы, куркынычлы төн иде,
Бар халык мазлум иде, мескен иде, мәхкүм иде.

Шул караңгылык эчендә кычкыру мәмнүгъ[1] иде,
Кузгалырга, эзләнергә һич тә рөхсәт юк иде.

Йоклатып ил өстенә баскан иде албастылар,
Нур белән безнең арада бар иде таштан дивар.

Яктылык эзләп күзеңне ачты исәң мәгъюп[2] идең.
Әллә кем булсаң да сан юк, син һаман бер чүп идең.

Эшчеләрнең хәмләсе берлән ватылды таш дивар,
Хөррият шунда ук бөтен дөньяга күрсәтте дидар[3].

Төште куллардан, аяклардан әсарәт[4] чылбыры,
Бар кешегә тип-тигез төште гадәләтнең нуры.

Нишләрен белми халык, анда матурлык, монда ямь,
Ул кара көчләр җәһәннәмгә егылды йөзтүбән.

Әй ирек, син ит тәҗәссем[5], гөл йөзеңнән бер үбим.
Күп кешеләрдән сине көткән гашыйкның берсе мин.

1917

---

[1] Мәмнүгъ — тыелган.
[2] Мәгъюп — гаепле.
[3] Дидар — йөз, бит.
[4] Әсарәт — коллык, эсирлек.
[5] Тәҗәссем — гәүдәләнү.

НУР

Кара куллы явыз дошман!
Үзеңчә, шатлыгың бик зур,
Синең күзне чагылдырган,
Имеш сүнгән икән бер нур.

Дөрес, син шатланып көлдең,
Аның бер сүнгәнен күргәч,
Караңгыда очып йөрдең,
Янып торган чыраг сүнгәч.

Котылдым дип шушы нурдан,
Эчеңнән уйлагансыңдыр.
Фәкать алдандың, әй дошман!
Бөтенләй сүнмәде ул нур.

Үзе сүнгән кебек бетте,
Ләкин ул чәчте күп якты,
Күрәмсең инде төн үтте,
Офыктан якты таң атты.

Беләмсез, ошбу нур, ул кем?
Ачындык ул чыраг сүнгәч,
Биреп торган иде зур ямь —
Югалган Мулланур иптәш.

Аны без һичбер онытмыйбыз,
Олуглыйбыз вә зурлыйбыз,
Халыкның корбаны булды
Каһарман Мулланур, дибез.

Аның исеме күңелләрдә
Язылган — мәңге онытылмас,
Аңа дошман кешеләргә
Гомергә якты көн булмас.

1919

БЕЗНЕҢ ЮЛ

Алда дошман бар икән, дип
Игътикадым какшамас,
Ни зыян бар изге юлда
Мәңгелеккә китсә баш.

Кайда барсаң бер үлемдер;
Тик сәбәпләр башкача,
Куркынып башны түбән салу
Үлемнән сакламас.

Килде шул көн: я үлемдер,
Я җиңүдер — башка юк.
Чын каһарман мондый чакта
Курыкмас вә артка атламас.

Нинди хурлык! Кулга тоткан
Байрагың ташлап чигү,
Юк, бу булмас!.. Ташларын ват,
Суларын кич, алга бас!..

Ник кыямәт купмый, ник җимерелми
Барча дөньясы!..
Чын иманлы ир егетләр
Какшамас һәм каушамас.

Нурлы йолдызлар белән тулган
Аяз күңелем күген
Шик вә шөбһәле томаннар
Һәм болытлар капламас.

„Бу көрәш, алда бәхет бар",—
Дип язылган күңелемә,
Әллә нинди иблисең дә
Пычрата алмас, таптамас!..

1919

ҖИЛБЕРДӘСЕН КЫЗЫЛ БАЙРАК

Шәрекъта кып-кызыл утлар яна, ялт-йолт итеп балкый,
Уянды мәллә күп еллар гафил яткан шәрекъ[1] халкы?

Күренде инкыйлап ялкыннары Һинд таулары аша,
Капитал золымы берлән анда кемнәрдер бик ыңгыраша.

Тянь-Шань тауларыннан шаулап аккан шарлама төсле,
Арысландай каһәрләнгән тавышлар бар гаҗәп көчле!..

Башы күккә чыгып торган биек таулар башы ап-ак,
Әнә шул җирдә җилбердәп күренсен кып-кызыл байрак!

1919

[1] Шәрекъ — көнчыгыш.

50890

ТАТАР ЕГЕТЕНӘ

(Шуралар җөмһүриятен[1] гамәлгә куючы егетләребезгә багышлана)

Вакыт җитте, егет! Җаның булса,
Уян, сикереп күк бүз атка мен!
Күрәсеңме Идел буйларында
Матур, ал, кызыл таң атканын.

Урал тауларыннан күк таш алып
Кайра кылычыңны шуңарга,
Таң җилләре искән матур чакта
Кит син дошманнарны куарга.

Бернәрсәдән курыкмый, җанфәрманга
Алга чап син җирләр селкетеп,
„Дөнья безнең!“ дип кычкыр шунда
Гайрәт белән, йөрәк җилкетеп.

Шулай итеп вәхши ерткычларның
Котларын ал, салып куркыныч,
Кып-кызыл кан белән бизәкләнсен
Кулларыңа тоткан шул кылыч.

Шул вакытта чынлап тынычланыр
Күкрәгеңдә янган йөрәгең,
Шул вакытта биргән булырсың син
Мазлум илнең көткән теләген...

1920

---

[1] Шуралар җөмһүрияте — Советлар республикасы.

БИР КУЛЫҢНЫ

Кил әле син, иптәш! Бир син миңа
Сөялләнеп каткан кулыңны.
Янган йөрәк белән чын ихластан
Тәбрик итим изге юлыңны.

Бир син миңа, туган, көн-төн эшләп
Таш пулатлар салган кулыңны,
Бир син миңа утлар тирәсендә
Эшләп, кызарып янган кулыңны.

Бир син миңа, кырда сабан сөрен,
Туфракланып каткан кулыңны,
Бир син миңа дошман күкрәгенә
Төзәп мылтык аткан кулыңны.

Бир син миңа, сугышып, шул сугышта
Кызыл каннар аккан кулыңны,
Дошманнарның биек калгаләрен[1]
Тар-мар итеп ваткан кулыңны.

Бир син миңа хәләл көчең белән
Эшләп тиргә баткан кулыңны,
Эштән арып тагын көч җыярга
Аска салып яткан кулыңны...

Бир син миңа, гайрәт белән сугып,
Дошман башын ваткан кулыңны.
Дуслар битен үпкән кебек үбим,
Сөялләнеп каткан кулыңны.

1920

---

[1] Калга — крепость, ныгытма.

ГАҖӘПМЕ

Кичә күз яшьләре тамган урында
Бүген гөл чәчкәсе уссә—гаҗәпме?

Авырлык берлән үткән бу минутлар
Җиңеллек берлә тиз үтсә—гаҗәпме?

Күгемне каплаган салкын болытлар
Башымнан мәңгегә китсә—гаҗәпме?

Вөҗүдне чолгап алган кайгы, хәсрәт
Таралып юк булып бетсә—гаҗәпме?

Гыйшык белән исергән бу башымны
Гүзәл йөзле матур көтсә—гаҗәпме?

1920

ГАҺЕТ[1]

(Кызыл каһарман авызыннан)

Үземдә көч, күңелдә эш, тагын үткен кылыч кулда,
Алырмын җан, түгәрмен кан шушы изге кызыл юлда.

Халык дошманнарын таптап батырмыйча кара канга,
Кыныннан бер суырган бу кылычны тыкмамын кынга.

Барырмын һәрвакыт алга, сугышта бирмәмен арка:
Аларның күплеген күргән саен тик гайрәтем арта.

Тагып йөрмәм „егет“ исемен, әгәр курыксам
сугышларда,
Керермен нәкъ арысландай ярып зур куркынычларга.

Сугыш мәйданының нәкъ уртасыдыр ир егет урыны,
Ярып, җимереп үтәрмен кап-кара урман вә киң
кырны.

Гаһет кылдым, ямин иттем, Кызыл байрак тотып
кулга:
„Алырмын җан, түгәрмен кан шушы изге кызыл
юлда!“

1920

---

[1] Гаһет — ант.

УРАК БЕЛӘН ЧҮКЕЧ

Ничә еллар буе кырда йөреп
Бөкерәеп беткән бер урак.
Теше сынып, тәмам эштән чыгып,
Чормада ятты бик озак.

Ятты чормада берничә ел,
Һичкем аңар күзен салмады.
Үзе төшә алмады хәлсезлектән,
Башка берәү килеп алмады...

Вакыт житте. Бер көн берәү килеп
Аны урыныннан кузгатты.
Яңадан тешәп эшкә кертү өчен,
Алып тимерчегә озатты.

Барып керде урак тимерчегә,
Кергәч сәлам бирде кычкырып,
Карап керде тирә-якка,
Бүреген култыгына кыстырып.

Шунда чүкеч күрде бу уракны,
(Бер күргәндәй булды кайдадыр?)
Урак иптәшеннән сәлам алды,
Диде: „әйдә, иптәш, түргә уз!“

— Урак иптәш икән! Белми торам,
Нинди ябыккансың, беткәнсең,
Тешең төшеп, тәмам картайгансың,
Тәмам эштән чыгып беткәнсең!..

Урак, чүкеч сүзен ишеткәчтән,
Килде тагын бераз алгарак,
Кулын сузды чүкеч иптәшенә,
Башын иеп, түбәнгә карап...

— Башың имә, иптәш, әйдә алга,
Мин ясармын сине яңадан,
Яңарырсың, баскан тутың бетәр,
Яңа туган кебек анадан...

Шунда урак, тагын алга атлап,
Кочаклады изге иптәшен.
Чүкеч сөртте шунда иптәшенең
Күзләреннән аккан күз яшен.

Кочаклашып шунда серләштеләр,
Бер-берсенең хәлен белделәр.
Чын мәхәббәт белән кул кысышып,
Аерылмаслык вәгъдә бирделәр...

Урак вәгъдә бирде: бу көннән соң,
Чын дәрт белән урак урырга,
Чүкеч иптәшенә һәрвакытта
Төрле азык биреп торырга.

Чүкеч вәгъдә бирде моңа каршы:
Аның биргән азыгын ашарга,
Шуны ашап, урак иптәшенә
Төрле-төрле нәрсә ясарга.

Шулай бергә-бергә көн күрергә,
Яңа, яхшы тормыш корырга;
Ике көчне җыеп бер урынга,
Дошманнарга каршы торырга...

Изге, пакь эш белән ант иттеләр
Вәгъдәләрен исбат итәргә.
Бер эз белән барып һәрвакытта,
Бергә-бергә дөнья көтәргә.

Шатлыгыннан шунда көлде урак,
Тирә-яклар китте ялтырап,
Күкрәк сукты чүкеч гайрәт белән,
Китте бөтен җирләр калтырап...

Урак белән чүкеч бу вакытта,
Аерым булса да, бер иде.
Алар күрешеп кочаклашкан вакыт
Нәкъ җиденче ноябрь иде.

1921

БЕРЕНЧЕ МАЙ

(Жырлыйк)

Күңелләрдә теләк бер булгачтын,
Жырларны да бергә жырлашыйк,
Бара торган юллар киң булгачтын,
Жир селкетеп бердән нык басыйк!..
Әйдә жырлыйк, шундый жырларны без,
Дәһшәтеннән җирләр яңгырасын!
Дөнья халкы яңа көчләр барын
Күзе белән күреп аңласын...
Олуг идея, изге ил өстенә
Кадап куеп гөлләр бәйләмен,
Жырлап-жырлап чиксез шатлык белән
Итик олуг җиңү бәйрәмен...
Әйдә жырлыйк, фабрик, заводларда
Кибеп сулган эшче жырларын,
Шунда күмелеп калган теләкләрен,
Шунда түгелеп калган моңнарын...
Әйдә жырлыйк мазлум милләтләрнең
Көчлеләрдән күргән хурлыгын,
Чәчик җир йөзендә чын азатлык,
Чын туганлык, дуслык орлыгын...
Монда гына калмас безнең тавыш,
Ишетелер бөтен дөньяга:
Диңгез артларына, Африкага,
Европага, бөтен Азиягә!..
Кемнәр хурлык күргән, кем изелгән,
Шулар безнең сафка тезелер.
Үлгән илләр яңадан терелер,
Коллык зынҗырлары өзелер.

1922

РКСМ

I

Күрәм картларны: алар көтәләр
Алда җәннәтләр, назлы нигъмәтләр...
Шуның юлында төрле теләкләр
Теләп аларга коллык итәләр...
Дер-дер калтырап, алладан сорап,
Тик бер үзенең бәхетен югалтмас
Өчен дөньяда торып китәләр...
Әйдә, китсеннәр меңләп вә йөзләп,
Монда торганчы дөнья тыгызлап,
Кеше көченнән тамак туйдырып,
Бәлешләр ашап тозлап, борычлап.
Күрәм тагын да:
Йөри агайлар
Ошбу дөньяда еллар вә айлар,
Эшсез көенчә тормыш күрәм, ди,
Гүзәл хатынга ефәк, атлас,
Алтын, асылташ алып бирәм, ди...
Тыштан ялтырап, эчтән калтырап,
Эшче өстенә авыр йөк булып,
Ак тән өстенә ямьсез төк булып,
Буш мичкә кебек шаулап, ялтырап,
Шулай йөрерләр, йөреп кибәрләр,
Бер көн бөтенләй эзсез сүнәрләр...
Әйдә сүнсеннәр, кайгырма син дә,
Алар кирәкми безгә бер тиенгә...

II

Күрәм:
Киң юлда, соңгы биш елда
Кемнәрдер килә дөнья тетрәтеп,
Утлар яудырып, күкләр күкрәтеп,

Җирне нурлатып, тормыш үзгәртеп,
Дусны көлдереп, дошман елатып,
Мескен картларның йөрәген сызлатып,
Коллык төбендә моңнар чыңлатып,
Капитал дөньясын эттәй улатып,
Черек диннәрнең кәгъбәсен ватып.
Боларны күреп, эчтән калтырап,
Динле кешеләр торалар шаккатып.
Куркак кешеләр куркып өркәләр,
„Дөнья бетә!..“ дип, мәхшәр көтәләр.
Кемнәр соң болар, шаулап киләләр
Ачып киң юллар?..
Боларны күргәч,
Бик күп кешеләр шып-шым булдылар...
Мәгъбәдләренә барып тулдылар.
Дөнья тетрәткән
Кемнәр соң болар?..
— Яшьләр гаскәре — РКСМ лар ул.
Күкрәкләр киереп,
Яңа тормышка киң юл салучы —
Әнә шулар ул...
Дөнья тетрәтеп, күкләр күкрәтеп
Киләләр алар безгә алмашка!..

1923

КОРБАННАР

(Лена вакыйгасында үтерелгән иптәшләргә)

Ирек корбаннарын хөрмәт итеп
Һәр ел саен искә алабыз...
Җиңүебезне уйлап шатланабыз,
Сезне уйлап уйга калабыз...

Кар өстендә аккан каныгызның
Һаман күрәбез без эзләрен...
Газап күреп үлгән җаныгызның
Онытмыйбыз соңгы сүзләрен...

Сезгә төзәп аткан канлы куллар,
Берәм-берәм тотылып киселде,
Сезне чапкан сатлык залимнарның
Канлы кылычлары кителде...

Мең мәртәбә артык үч алынды,
Һәрберсенә җәза бирелде,
Сез сызган эз белән юл салынды,
Сезнең хезмәт чынлап күренде.

Сарайларын ваттык, һәйкәлләрен
Җимереп җиргә салып таптадык...
Сезнең исемегезне күңлебездә
Шушы көнгә чаклы сакладык.

Сезнең нахак аккан каныгызның
Тамчысы да әрәм китмәде,
Үзегез изге юлда бетсәгез дә,
Изге теләгегез бетмәде.

1923

ОЧАР ИДЕМ

Җирдән карап торам: бөркет күккә аша,
Оча-оча болытларга якынлаша.
Көнләшәм мин шул вакытта аны күреп:
Күктә йөреп җирне кылганга тамаша...

Яшь идем мин ул заманда, көчле идем.
Иөрәксенгән нәкъ арслан төсле идем.
— „Их, шул бөркет кебек мин дә күктә очсам?!."
Дигән уйлар белән кырда эшли идем.

Еллар үтте, һаман шундый уйда йөрдем,
Бу дөньяда байтак еллар гомер сөрдем,
Бил бөкрәеп, чәч агарган вакытымда,
Күктә очкан шул бөркетне тагын күрдем...

Бөркетме ул?.. Нәрсә оча аяз көндә?
Ук җитмәслек, туп җитмәслек күк йөзендә.
Бөркет кебек ике якта канаты бар,
Койрыксыман бернәрсә дә бар үзендә...

Бик мәһабәт, тавышланып очып бара.
Тиздән күздән югала бит... кара, кара!
Кош дигәнем аэроплан булып чыкты.
Ул югалды, еракланды безнең ара.

Хәзер уйлыйм: әгәр дә мин, яшь чак булып,
Йөрсәм күктә шул очкычка үзем утырып,
Болытлардан үтеп, зәңгәр күк йөзендә
Очып йөрсәм, машинасын үзем борып...

Яшь чакларым булган булса... мин, бу көннән
Башлап төшми йөрер идем күк йөзеннән,
Дошманнарның котын алып очар идем!..
Дип кайгырам һәм зарланам үз-үземнән...

Мин яшь булсам, тормас идем бер көн монда,
Китәр идем алар кайда, мин дә шунда...
Очкычларны үзем ясап, үзем корып,
Очар идем күк йөзендә гайрәт орып!...

1923

ЯҢА КӨЧЛӘРГӘ

Мәйдан ачылды яңа көчләргә —
Беләк сызганып,
Дәррәү кузгалып,
Дөнья яңгыратып, эшләр эшләргә...

Кызыл байракны
Бердәм кулга алып,
Җирне биләргә, күккә менәргә,
Җир шарын коршап торган зынҗырны
Корыч кул белән
Ваклап кисәргә!..

Шаулап, чайкалып котырган диңгезне,
Бернигә күрми,
Ары кичәргә.
Юллар ачылды
Көчле яшьләргә!..

Кара йөрәкле, искергән ирләр,
Сезгә юл биреп,
Артка чигәләр!..
Черегән йолалар, тузган фикерләр
Чикләнер көннең
Җитүен сизәләр.

Мәйдан ачылды яңа көчләргә
Тормыш юлларын яңадан төзергә,
Җирне бизәргә...
Күккә менәргә!..

1924

ШАХТЕР

Каты ташны тук-тук чукый-чукый
Кәйләсенең очы ашала,
Тупаслана. Шуннан аны ташлап,
Өр-яңасын тагын кулга ала...

Аның белән тагын тук-тук чукып,
Катлау-катлау ташны җимерә,
Өстә калын катлау җир калдырып,
Астан каты ташны кимерә.

Дистә-дистә шундый кәйләләрне
Туздырган ул ташлар актарып.
Ул туздырган шундый кәйләләрнең
Саны җитә меңнәргә барып...

Ул казыган ташларны бергә өйсәң,
Кечкенәрәк биек тау булыр,
Ул чыгарган ташны җиргә җәйсәң,
Күплегеннән кип-киң кыр тулыр.

Аның каршысында чыдамаган тимер, ташлар...
Ә ул үзе һаман тап-таза.
Аның кулы белән күкрәгеннән
Көчле нинди көч бар дөньяда?..

1925

КАРТ БАТЫР ТЕЛӘГЕ

Туры юлдан бардым ат уйнатып,
Хакыйкатьләр өчен җан атып,
Уңга-сулга селтәп кылычымны,
Дошман күкрәгенә ук атып...

Мин картайдым хәзер, хәлдән тайдым,
Тик йөрәгем һаман кайнаша,
Кылыч тоткан кулым калтырана,
Дошман күрсәм, күзем кан баса!..

Кылыч тотып уйлыйм шул вакытта:
— „Бу кылычны миннән кем алыр?..
Сугыш мәйданына кемнәр чыгар,
Минем урным тотып кем калыр?..“

Шул сүзләрем ишетеп, бер яшь егет
Килеп басты минем каршыма.
Утлар чәчеп шулай сүз башлады:
— „Әй, карт батыр, юкка борчылма!

Кайда үткер кылычың? Бир син миңа,
Сугышларга үзем барырмын!..
Каршы килгән дошман яуларының
Сафларын мин үзем ярырмын!..

Син салган эз бетмәс!.. Бетермәбез!..
Зурайтырбыз аны тагын да.
Синең урының менә без тотарбыз,
Хафаланма, без бар чагында!..“

Ишеткәчтен аның бу сүзләрен,
Күрешәм мин аңа биреп кул:
— „Ал, яшь егет, үткер кылычымны,
Миннән сиңа изге мирас ул...“

1925

ЧИТ ИЛ КУНАКЛАРЫ

Россиядә үзгәреш!..
Байлар качканнар, имеш...
Эшче кулларга күчкән
Бөтен корал, һәммә эш!..

1918 нче ел

I

— Канлы сугыш... Каты сугыш... Көрәш бик зур!..
Эшләр ничек бара? — күзәтеп тор!

— „Булмас бу эш!..
Капиталны җиңәлмәсләр!..
Эшче халкы — алар аңсыз, алар сукыр..." —
Диделәр
Чит дошманнар безгә карап.
Ә шулай да җиңеп чыкты СССР.

— „Чыкты чыгуын... Булыр бер көн алар харап.
Мин әйтте, дип, әйтерсез, кара да тор..." —
Диделәр
Акыллы баш сәясиләр.
— „Большевиклар күз чыгарып каш ясыйлар...
Фән-белемне бетерәләр... Чеп-чи надан
Эшчеләрне бөтен илгә баш ясыйлар!.." —
Диделәр җиңелеп читкә качкан аклар.
(Чынлап булды безгә шулай әйткән чаклар.)
Үткән сигез еллык тарих искә төште
СССРга күп килгәчтен чит кунаклар.

Артка баксак, бар иде бит шундый заман:
Ялгыз калып, киселеп тордык бар дөньядан...
Ә бу көндә груһ-груһ кунак килә
Европадан, Америкадан һәм Азиядән.

Бар кунаклар арасында эшчеләр дә,
(Алар белән ике арада юктыр пәрдә.)
Бар кунаклар арасында битлек киеп,
Сынар өчен килгән кара эчлеләр дә...

II

— Уйна, оркестр, хәзер син,
Уйна Интернационал!
Гәүдәләндер зур теләкләрне,
Матурлап көйгә сал!..

Җир шарында бер генә булган
Совет дөньясына
Дус булып килгән кунакларны
Кадерләп каршы ал...

Курыкмый уйна!
— Тавышыңа китсен күңелләр кузгалып,
Тыңласыннар дус кунаклар
Чын иректә тын алып...

Күрсәт уйнап дөньяда
Бар эшчеләрнең берлеген...
Дәртләнеп китсен кунаклар,
Җанланып һәм шатланып...

Шатлыгымнан көйләп алдым кыска көйгә,
Җырламаска, шатланмаска безгә нигә,
Чит илләрдә миллионлаган эшчеләрдән
Вәкил булып кунак килгәч безнең илгә.

— Иптәшләр!.. Хөрмәт белән сәлам сезгә,
Сез күптән якын безнең күңелебезгә...
Әйдәгез, кешелек өчен күп көрәшеп
Яңа тормыш корган иркен илебезгә...

Сезгә безнең ишек ачык шәрран-яра.
Биш бармактан якын безнең — сезнең ара,
Яңа тормыш корган СССРның
Авылын кара, фабрик белән заводын кара.

Йөреп бөтең СССРның дөньясын күр,
Кырымын күр, Кавказын күр, Донбассын күр.
Безнең монда төрле милләт ничек яши;
Татарын күр, башкортын күр, чувашын күр.

Яшермибез, ачык ята бары шунда,
Теләгәнчә карагыз сез барысын да.
— Безнең эшләр менә шулай,
Дип әйтәбез,
Бөтен дөнья эшчеләре каршысында.

Язып бетереп булмас ахры монда барын:
Кунакларның нинди тәэсир алганнарын,
Җавапларын... Шатлыкларын... Безне күргәч
Аңлауларын дошманнарның ялганнарын,

Куллар кысып, зур көрәшкә вәгъдә биреп,
Һәрбер эшкә күзне ныклап салганнарын.
Сүз озынга китмәсен, дип, язмадым мин,
Газетларда укырсыз дип, калганнарын.

Кыскасы шул: киткән чакта ул эшчеләр:
— „Без көткәннән артык сездә эшләр чибәр,
Сезгә каршы дошманнарга без дә дошман...
Һәрвакыт без сезнең белән бергә!..“ диләр.

III

Алтын күзлек кигәннәр,
Болар кайдан килгәннәр?
Алар сездән шикләнгәннәр,
Сынар өчен килгәннәр:

— „Бетми торган бу каһәрләр нинди халык!..
Торалар бит капиталга тәшвиш салып.
Файда чыкмас читтән карап тик торудан,
Булмас ахры... үзләренә барып карыйк“

Дип сөйләшкәч галимнәре... банкирлары,
Вак ирләре белән бергә шәп ирләре,
Җибәрделәр СССРга „кешеләрен“:
Бу соңгылар шул сыйныфның вәкилләре.

— Пожалуйста югарыдан... чит „кунаклар“!
(Бар иде бит сезнең бездән качкан чаклар.)
Менә сезгә вагон, менә автомобиль,
Кирәк булса, менә сезгә аргамаклар...

Килгәнсездер бераз йөреп күп сынарга.
Без өйрәнгән инде сездәй „сынчыларга“.
Хакыйкатьне күреп дөрес сөйләсәгез,
Хәзергә риза әле без шуңарга.

Су буенда җофар күп,
Җофардан да сусәр күп,
Дошман күп дип, курыкмыйбыз,
Дошманнардан дуслар күп,

Болай тыштан сез чибәр,
Эчтән дошман көнчеләр.
Сез безгә дус булмасагыз,
Дуслар безгә эшчеләр.

— „Ник җырлыйсың шуларга...“
Дип әйтсәгез, дөресен әйтәм:
Килсен, әйдә килсеннәр,
СССРда йөрсеннәр,
Бөтен эшне күрсеннәр,
Эшнең асылын белсеннәр.

Әгәр тели икән — килсен Чемберлен да,
Якын дусты Черчилль яки Бриан белән,
Европаның „мәшһүр-олуг“ ирәннәре
Җыелсыннар да килсеннәр бары бергә.

Безнекеләр өстәл тирәсендә бергә
Утырырлар беррәттән алар берлә.
Шунысы бар тик: сез шул юлдан барган чакта
Һичвакытта килә алмаслар бер фикергә.

Мәгълүм инде сез бер юлда, без бер юлда,
Балкып торган кызыл байрак безнең кулда.
Сезнең артта санлы гына байлар булса,
Миллион-миллион эшче тора безнең тылда.

Шунысы булыр: сез китәрсез бераз йөреп,
Яңа тормыш корган совет илен күреп...
Һәрбер эшне үзегезчә тәэвил итеп,
Бу эшләргә үзегезчә мәгънә биреп!

— Хуш хәзергә... Сау булыгыз киткән көндә.
Төш түгелдер, ошбу эшләр бары өндә.
Актык көрәшү түгел... Сезнең белән тагын
Көрәшербез бөтен дөнья көрәшендә.

Исәп-хисаплар өзелер бары шунда,
Шул вакытта карап торырсыз барын да,
Ала-кола, кара-чуар бары бетәр:
Кызыл байрак кына калыр җир шарында...

1926

КЫЗЫЛ АРМИЯ

(Сигез еллык бәйрәм хөрмәтенә)

I

Гөлт! итеп чыкты янар таудай булып,
Кап-караңгы төндә айдай булып...
Нәгъруә берлән кычкырып чыккач та ул
Яктырып дүрт якка ачты якты юл...
Җир шарындагы бөтен мазлум халык
Салдылар күз, шаккатып, хәйран калып:
— „Нинди якты бу янар таулар!.. — диләр,—
Ә шулар икән кызыл яулар!..“—диләр.

II

Үсте ул, үткән саен еллар саны,
Каплап алды дөньяны шәүкәт даны.
Ул, бу көндә шаулаган дулкын кебек,
Өйрелеп торган олуг упкын кебек,
Гомеренә аумас биек скал кебек,
Һичвакыт сынмас каты сталь кебек.
Танклар... тупларга каршы ул барыр,
Чын азатлыкка мәгәр ул юл ярыр!..
Бу капитал тырнагыннан җир йөзен
Тик шулар беркөнне чынлап коткарыр!..
Ябрылып килгәндә яу ил өстенә,
Ул булыр җимерелми торган стена!..

1926

МАЙ АЕ

Матурлыкта башка унбер айдан
Узып киткән нурлы ай бит ул,
Җир йөзенә хәят, җанга шатлык
Бирә торган җанлы май бит ул...

Майдан башлап нурга манчыладыр,
Бизәләдер безнең җиребез...
Төрле майны көтә җан-тән белән
Ирек сөйгән безнең илебез.

Карагыз сез: нурлар сибеп торган
Көннәренә... Ай-һай көннәре!
Күз салыгыз йокы бирми торган
Төннәренә... Ай-һай төннәре!..

Тормыш таңы бит ул — май көннәре,
Анда кемнәр генә җырламас...
Кайсы җан иясе шатланмас та,
Нинди кошлар гына сайрамас?..

Нигә шауламасын бөтен шәһәр,
Нигә шатланмасын авыллар?..
Нигә ташымасын ташкын сулар,
Нигә җанланмасын басулар?..

1926

ТОРМЫШ КӨРӘШЕ

I

Иске авылны яңартырга „Яңа авыл“
Үрнәк булып, күрсәтергә туп-туры юл,
Дөньяга көрәш өчен чыкканына
Бүген килеп тулган икән нәкъ ике ел[1].

Шуннан башлап ике арада китте көрәш,
Боларның берсе бик карт, берсе бик яшь,
Көрәш булгач, сугыш булгач, мәгълүм инде:
Һәр ике як үзенә җыя көч вә иптәш.

Ышана үзенең яшь көченә яңа авыл,
Шуның белән бергә фәнгә таяна ул.
Моңарчы соң фәнне кемнең җиңгәне бар?
Фән-белемгә моңарчы кем бирмәде юл?

Һәр ике як шулай сүзгә килештеләр,
Җан-тән белән хәзерлеккә керештеләр,
Сугышсыз эш чикләнмәве мәгълүм булгач,
Бер-берсенә ультиматум бирештеләр.

Билгеләнде сугыш җире итеп басу,
Уңай булыр анда, диеп, көч сынашу,
Һәр ике як шулай итеп вәгъдәләшкәч,
Башланды киң мәйданга корал ташу.

II

Иске авыл чыгып китте кырга табан,
Кораллары: ватык арба, иске сабан,
Агач тырма, кабык тубал, үтмәс балта,
Өстенә кигән яшькелт иске чапан.

---

[1] Бу шигырь Уфада чыккан „Яңа авыл“ газетасына ике ел тулу уңае белән язылган.

Башына мескен бүрек киеп алган,
Юкә баулы чабагачын аска салган,
Тешсез иске уракларын кулга тоткан,
Ат куарга чыбык алган яшел талдан.

Шул рәвешле хәзерләнеп китте кырга,
Дошман белән эш урынында очрашырга,
Бер яктан ул дога кыла зар иңгерәп,
Яңа көчләр белән көчен сынашырга.

III

Шулай ук „Яңа авыл“ да китте кырга,
Утырып матур көчле тракторга,
Тагып алды өч төрәнле тимер сабан,
Янына алган тагын тимер тырма.

Моннан башка тагын бик күп кораллар бар,
Ура торган, суга торган машиналар,
Җилгәргечләр... белмим тагын әллә ниләр...
Һәммәсе дә чатнап торган тимер алар.

Трактор, төтен чәчеп, кызып китте,
Юлда чакта ук иске авылны узып китте,
Иске авылның аты өркеп, юлдан чыгып,
Арбасының тәртәләре сынып китте.

Карганып калды юлдан читтә туктап,
Ачуыннан арык-торык атын тукмап,
Тәртәләрен төзәтергә керешкте ул,
Ни эшләргә белмәенчә тирләп, ухлап.

IV

Тагын килик „Яңа авыл“ һәм гаскәренә:
Ул шаулап килеп житте эш жиренә,
Килү белән гаскәрләрен эшкә кушты,
Тәртип белән бер эш биреп һәрберенә.

Трактор тыр-тыр итеп китте йөреп,
Күп төрәнле сабан белән җирне сөреп,
Җем-җем итеп кара туфрак дулкынлана,
Шаккатты иске авыл моны күреп.

Артыннан тимер тырма атлап килә,
Зур кәсләрне тузан кебек ваклап килә,
Чүп-чарларның женен өзеп, тамырын кырып,
Җир башына өем-өем ташлап килә.

Бер җирдә машинасы урак ура,
Бер машина пыр туздырып ашлык суга,
Шаулап торган төрле-төрле машиналар
Матур күренеш һәм җан бирә зур басуга.

V

Иске авыл кырга килә чак-чак атлап,
Төш җитәр чакта китте эшкә башлап,
Агач сабан, рәте һич юк, юньле сөрми,
Кай җирләрне чи калдырып китә ташлап.

Булмады бу нәрсәдән дә, каһәр суккан.
Әллә сынган, әллә берәр чөе чыккан,
Ни эшләтсәң дә көйгә килми, бара торгач,
Мескен сука бөтенләйгә чыкты сафтан.

Атлары да — бака кебек, чак кузгала,
Тырмасы да тырмый алмый... йөзе кара!
Эшкә кушкан бернәрсәсе эшкә ашмый,
Берсеннән соң берсе сафтан чыга бара.

Дошманнан җиңелмәс, сер бирмәс өчен,
Иске авыл сынап карый барлык көчен,
Дога кыла, ялварына, булмый һаман,
Бара торгач өмет өзеп ташлый эшен.

Болай булгач чикми булмый артка таба,
Йөрәк яна, күңел һаман кытыклана,
Аптырагач, кырны ташлап, кайтып китә,
Дога кылып, мәчетенә ышыклана.

VI

„Яңа авыл“ һаман эшли пыр туздырып,
Машинаның берсе сөреп, берсе урып,
Берсе сугып, тагын берсе җилгәрәдер,
Карап торган кешеләрне кызыктырып.

Сугыш бетә „Яңа авыл“ җиңү белән,
Иске авыл куркып артка чигү белән,
Тирә-якка матур үрнәк булсын өчен
Фән аркылы яхшы орлык игү белән.

Эш эшләнә гамьсез уйнап-көлү белән,
Фән-белемне эшкә нигез кылу белән...
Эш беткәч, горурланып кайтып китте
Авылдагы мәктәп белән клубына.

Яңа тормыш килеп чыкты булып өстен,
Ул күрсәтте якты йөзен, ныклы көчен,
Ике тормыш көрәшене күрсәтергә
Алдым монда „Яңа авыл“ны мисал өчен.

1926

ЧИТ ДОШМАННАР

Чит дошманнар һаман Совет илен
Вак-вак кына көчекләр аша
Талатмакчы булып өсләтәләр,
Ә үзләре читтән тамаша
Кылган булып, арттан корал биреп,
Зәһәр чәчеп, карап яталар...
Сатлык җаннар аша советларга
Каршы агулы ут аталар...
Чит илләрнең эшчеләре түгел,
Эшчеләрне изгән байлары...
Крестьяннары, ярлылары түгел,
Байлары, паннары
Шулай кыланалар... Ачуларын
Эчләрендә саклый алмагач.
Шулай куркытмакчы була алар,
Башка әмәл-чара калмагач...
Юк!
Курыкмаслар инде алай гына,
Совет куркулардан үткән ул!..
Миллиард эшче белән крестьян
Моннан соңра сезгә булмас кол!..
Сезнең йөрәк булса каты тимер,
Безнең йөрәк каты корычтан!..
Сезнең куллар үткер хәнҗәр булса,
Безнен куллар үткер кылычтан!..
Сезнең яктан миллион туплар булса,
Безнең яктан курыкмас йөрәк бар!..
Сезнең терәк „алтын тәре“ булса,
Бездә эшче диган терәк бар!..

1927

ГӨЛЛӘР БАКЧАСЫНДА

Беркөн шулай, гөлләр бакчасында
Чәчкәләрне кылдым тамаша.
Хуш исләре белән җан шатлана,
Нурларыннан күзләр камаша.

Нәфис төсләренә, буйларына
Хәйран калып, кызыгып карадым,
— Әй чәчәкләр, сезгә кемнәр дуслар?
Кемнәр дошманнар? — дип сорадым.

Гүя, алар шунда җанландылар,
Нурлар чәчеп җем-җем көлделәр.
Әкрен генә искән җил аркылы
Миңа болай җавап бирделәр:

— Кемнәр эшли, кемнәр җирләр казый,
Кемнәр безгә сулар сибәләр...
Кемнәр чәчкә кебек саф күңелле,
Шулар безгә дуслар... — диделәр.

— Кемнәр кара эчле, тар күңелле,
Кемнәр чын эшкә кул бирмиләр.
Кемнәр килеп безне хаксыз өзә —
Шулар безгә дошман!.. — диделәр.

Чәчкәләрнең шушы җавапларын
Алгач, „Дөрес!..“ дидем аларга,

Эшсез кешеләрнең[1] хаклары юк
Сезне түшләренә кадарга...

Күңелле эш, матур тормыш белән
Ел артыннан еллар агарлар...
Эшчән егет белән эшчән кызлар
Сезне түшләренә кадарлар...

1927

---

[1] Эшсез кешеләрнең — эшләмичә яши торган кешеләрнең, эксплуататорларның дигән мәгънәдә — *Ред.*

ТАНТАНАЛЫ БӘЙРӘМ

Зур Октябрь,
Аның ун еллыгы.
Бәйрәм бөтен дөнья халкына,
Дигән сүзләр чынлап киткән чакта,
Йөрәк тибә, күңел талпына.

Чиксез олуг, тиңсез бу бәйрәмгә,
Хаслап язам, дисәм сүземне,
Хәйран калам...
Чиксез зур диңгездә
Йөзгән кебек күрәм үземне.

Ул зур үзгәрешне язам, дисәм,
Чын мәгънәсен уйлыйм мин аның.
Күз алдымнан тезелеп үтә башлый
Үткән гомере бу карт дөньяның.

Октябрьдан элек үткән тормыш
Килеп баса күзем алдына,
Җанлы золым, канлы кылыч тотып
Алда басып торгандай була.

Эшче күкрәгенә штык терәп:
— „Кузгалма син!..“—
Дигәндәй була.
— „Мерзавец син, тик тор!
Эшләвең бел!..“—
Дип, җикереп йөргәндәй була.

Искә төшә симез капиталның
Баш күтәреп йөргән чаклары,
Миллионлаган эшче, батракларны
Эттән түбән күргән чаклары...

Күз алдына килә, һич хокуксыз
Гомер иткән шәрекъ илләре,
Капиталның золым кылычы белән
Канга сугарылган җирләре.

Күз алдыннан үтә болытланып,
Октябрьдан элек без ничек
Тордык...
Шул эшләрнең һәммәсенә
Зур Октябрь китереп куйды чик.

Без! — дибез без хәзер, чөнки хәзер
Күп „без“ бергә булган бертигез,
Бергә тормыш күреп, яңа нигез
Кору эшен бергә эшлибез.

Яңгырата хәзер җирнең йөзен
Эшчеләрнең көчле нидасы [1].
Хәзер СССРга гаһед [2] биреп
Килә чиксез эшче имзасы.

Миллиард халык бүген безгә карый,
Чын мәхәббәт, ихлас күңелдән,
Бүгенге көн безнең СССРга
Миллиард ялкынлы күз тегәлгән.

Онытылды бәйтелмөкаддәсләр,
Истән чыкты кәгъбәтулласы.
Хәзер СССР булып әверелде
Бөтен җир шарының кыйбласы.

Иске тормыш куркып калтырана,
Белми хәзерге көн ни эшләрен.
Читлек эчендәге ерткыч кебек,
Шыкырдатып ята тешләрен.

Бүген зур дәрт белән ялкынланып,
Тантаналы бәйрәм итәбез.
Тиздән җир шарының бар җирендә
Шундый бәйрәм булуын көтәбез.

1927

---

[1] Нида — эндәшү.
[2] Гаһед — ант.

КОШЛАР КИТКӘНДӘ

Көз көнендә... Кошлар төркем-төркем
Киткән чакта безнең бу илдән,
Үткән чакта урман өсләреннән,
Матур күлләрдән һәм Иделдән...

Төрле тавыш белән моңланышып
Бер-берсенә нидер сөйлиләр...
Безгә карап алар шул вакытта:
— „Сау булыгыз, сау бул!..“ диделәр.

— Сау булырбыз!.. Чөнки сау калдык без
Ут эчендә калган чакта да,
Төрле яктан төрле дошман килеп
Илне камап алган чакта да...

Шул сүзләрне әйткәч мин аларга:
— „Сез дә сау булыгыз!..“ дидем дә,
Кереп киттем тагын эш эшләргә,
— „Хуш... Хуш!..“ диеп башым идем дә.

1927

ТӘНКЫЙТЬ

„...Үзара тәнкыйтьтән башка — партияне, сыйныфны, массаларны дөрес тәрбияләп булмый..."

Иптәш Сталин сүзе.

Житешсезлек — дошман өчен шатлык,
Дошман шуннан бәхетләр көтә,
Җимерек урыннарны күргән чакта
Шатлыгыннан елмаеп үтә.

Гөрләп торган фабрик-заводларны
Күрсә аның йөрәге кага.
Эшчәннәргә шатлык биргән эшләр
Кайгы-хәсрәт сала дошманга.

Чын дус, алга киткән якны күрсә,
Китә йөзе айдай ачылып,
Житешсезлек, җимереклекне күрсә,
Тәнкыйть итә эчтән ачынып.

Күмәк тәнкыйть белән
Житешсезлекләрнең бетерелүләренә ышана,
Җимерек урыннарның төзәлгәнен
Күрсә, аның күңеле хушлана.

Алдашулар, төрле хыянәтләр
Җәрәхәтли аның йөрәген,
Гөрләгән эш белән җанлы тормыш
Нурландыра аның йөрәген.

Пәрдә астында яшерен нәрсәләрне
Көчле тәнкыйть ача да сала,
Ул тәнкыйтьнең көчле тырнагыннан
Нинди карга, козгын кача ала?

Совет илендәге көчле тәнкыйть
Һичбер сынмый торган корыч ул,
Җитешсезлекләрнең башын кисеп
Ташлый торган үткер кылыч ул!

Ябалаклар белән төлкеләрнең
Хәйләләрен ачкан якты ул,
Кайберәүләр өчен бик авыр ул,
Әмма эшчән өчен яхшы ул.

1928

ЗЛАТОУСТ

I

Күккә күтәрелгән таш тауларын
Ярып үткән тимер юл белән
Барган чакта тирә-якка карап,
Ниләр генә үтми күңелдән.

Искә төшә шунда: таш тауларын
Ватып эшләп йөргән кешеләр —
Моннан ничә дистә еллар элек
Шушы юлны салган эшчеләр.

Искә төшә: элек булып үткән
Пугач белән Салават яулары,
Канлы тарихларны сөйләп торган
Кебек була биек таулары.

Искә төшә: моннан ун ел элек,
Шушы зур-зур тауларны ярып,
Кызыл гаскәрләрнең үтүләре
Дошманнарның көчен актарып.

Искә төшә: Колчак гаскәренең
Өркеп качулары Себергә,
Буржуйларның Совет илләреннән
Алынып ташлануы гомергә.

Кара: ничек кара урманнары,
Дәһшәт биреп, шаулап торалар,
Үткән канлы көрәш тарихларын
Сөйләп торган кебек булалар.

Алар сине шаулап каршы алып,
Шаулап алга табан озата.

Урал тауларының һәр почмагы
Төрле-төрле уйлар уйлата.

Шулай уйлап алга бара торгач,
Дистәләгән озын трубалар,
Таулар арасында төтеннәрен
Чәчеп — бик мәһабәт торалар.

Ялт-йолт итеп балкып күренәләр
Чуен коса торган домналар,
Алар эш дөньясын күз алдына
Китереп бастыргандай булалар.

Зур тауларга дәһшәт биреп торган
Бу заводлар нинди күңелле!
Шушы шигъремә маузуг булган
Мәшһүр Златоуст шул инде.

II

Карт завод ул — яше ике йөзгә
Якынлашкан, озак яшәгән,
Ул, туганнан бирле чуен ашап,
Гомер иткән... корыч күшәгән...

Карт Уралның бик күп рудаларын,
Агачларын ашап үскән ул,
Аның ак ташларын ерып аккан
Саф суларын бик күп эчкән ул.

Аның тирәсендә ирек сөйгән
Күпме эшче каны түгелгән. .
Карап торсаң, үткән шомлы көннәр
Берәм-берәм үтә күңелдән.

Дистәләгән озын трубалардан
Кара-кучкыл төтеннәр чәчеп,
Хәл җыймыйча көнен төнгә катып,
Эшләп килгән үзен яшәтеп.

Күп кычкыра торгач тавышы да
Юанайган, карлыккан кебек
Ишетелә... Озак эшли торгач,
Эштән бераз ялыккан кебек...

Тирә-ягындагы зур-зур таулар
Аннан курыккан кебек торалар,
Ул кычкырткан чакта үзләре дә
Аңа кушылып тамак кыралар.

Ак сакаллы картлач Таганай[1] да
Аннан куркып торгандай тора.
— „Бу ахрысы минем ташларны да
Йотар!“ — дигән төсле утыра.

Карап торсаң, таулар курыкмаслык та
Түгел аның чиксез көченнән,
Кул сызганып, тиргә батып эшләп
Йөргән эшчеләрнең эшеннән.

Чиксез кызулыкны эченә җыйган,
Гөжләп торган мартен мичләре.
Тау-ташларны куркытмаслык түгел
Шаулап торган завод эчләре.

Каты тимерләрне чыкырдатып
Чәйнәп йоткан төрле машина
Ничек җитмәсен соң, тирә-якта
Тезелеп торган таулар башына.

III

Шулай, иске тормышта күп торып,
Картайган ул, элек бәсәргән,
Ләкин хәзер яңа көчләр, яңа
Яшь рухлар белән яшәргән.

Хәзер эшли анда яңа көчләр,
Яңа рухлы, яңа кешеләр,
— „Социализмга корыч нигез
Салабыз без!“ — дигән эшчеләр.

Хәзер анда йөрми бай фәрманы,
Эшче үзе хуҗа, үзе баш.

---

[1] Таганай — Златоуст заводыннан күренеп торган, 1230 метр биеклегендә булган мәшһүр бер тауның исеме.

Анда кайнашкан эш туктамас та,
Аның нигезе мәңге какшамас.

Шуның өчен анда күңелле дә,
Шуның өчен анда ямьле дә...
Әйдә, андый завод Урал ташын
Ашап дәвам итсен мәңгегә!..

1928

БАЛАЛАРГА

Үтәр сездән дә тиздән
Җәйге көндә уйнаган чаклар,
Үтәр туплар сикертүләр,
Үтәр уйнаулар ат-атлар.

Килерсез җыелышып мәктәпкә
Көз җиткәч тә сез, яшьләр,
Булырсыз чын якын дуслар,
Туганнар төсле иптәшләр.

Китапларны алып бик шат,
Укырсыз бергәләп шунда,
Кирәкле фән-белемнәрнең
Белерсез шунда барысын да.

Белерсез: сезгә кемнәр дус,
Вә кемнәр дус түгел, дошман,
Бу мәктәпләрне кем ачкан,
Күрерсез шунда укыгачтан.

Өйрәнерсез чын эш, тормыш
Төзү юлларыны анда,
Кызык булыр матур тормыш
Кору җәйге уеннан да.

Пионерлар булып анда
Өйрәнерсез көрәшләргә,
Бөтен дөньядагы яшьләр
Белән сез бергә эшләргә.

Алып кулга кызыл байрак
Китәрсез алга нык атлап,
Ленин сызган матур юлдан
Көрәш, эш җырларын җырлап.

Барырсыз сез зур абзыйларыгыз
Салган матур эздән,
Алар, юл күрсәтеп сезгә,
Матур эшләр көтә сездән!

1928

ЭШ ҺӘМ БЕЛЕМ

Эшчән кеше булу бик зур бәхет,
Эш ул — бу тормышның үзәге.
Укый-яза белү шул тормышның
Җәүһәр төсле матур бизәге.

Укый-яза белү — тормышыңны
Ачып күрсәтүче көзге ул;
Аң-белемгә таба ишек ачып,
Яктылыкка барган туры юл.

Эш һәм белем бергә җыелсалар
Гына тормыш матур була ала.
Уку-язу белән коралланган кеше
Аңлы тормыш кора ала.

1928

КЫЗЫЛ ГАСКӘРЛӘР ҖЫРЫ

Без ирекле илнең көчле егетләре,
Сайланып нәкъ арслан кебекләре,
Барабыз алга табан каты басып,
Тетрәсен дошманнарның йөрәкләре.

Без әзер һәрбер куркыныч чакларга,
Совет илен дошманнардан сакларга,
Барабыз алга, алга, алга!
Куркыныч салып бөтен дошманнарга.

Гайрәт белән тулган курыкмас йөрәгебез,
Дәрт белән тулган безнең күкрәгебез,
Безгә каршы килгән төрле дошманнарга
Яшен кебек атылып, көчле күкрәрбез без!

Без әзер... (Кушымта. Ахырына кадәр кабат-
лана.)

Тетрәсен, тетрәп торсын җирнең өсте,
Дошманнар күреп торсын безнең көчне,
Җир шарының мазлумнарын азат итү
Көрәшендә белсен дөнья безнең эшне.

(Кушымта.)

Азатлык һәм тигезлек безнең теләк,
Кайнап тора шулар белән безнең йөрәк!
Без бар чакта дошман безгә кул суза алмас,
Совет безгә, без советка сынмас терәк.

(Кушымта.)

Кайралган кылычыбыз кыныбызда,
Кирәк чакта коралыбыз кулыбызда.
Куркуның ни икәнен белмибез без,
Барабыз бара торган юлыбызда!

(Кушымта.)

1929

СЕБЕР ИСТӘЛЕГЕ

I

Әле дә истә авыл картларының
Себер турындагы сүзләре,
Йөрәгемнән китми:
— „Башы Себер китте!..“—
Дигән сүзнең эзләре.

Чынлап караганда, юкка гына
Курыкмаганнар алар Себердән,
Ник курыкканлыкларын күрсәтергә
Сезгә өч-дүрт мисал китерәм.

Берсе: мәңге Себер җибәргәннәр
Безнең авылның бер кешесен,
Сугып еккан өчен бер боярның
Бик кадерле булган бер этен.

Икенчесе: күрше бер авылның
Сүзгә оста — үткер кешесен
Себер җибәргәннәр бер чиновник
Белән сүзгә килешкән өчен.

Өченчесе: завод эшчеләре
Баш күтәреп чыкканнар шаулап,
Башлыкларын Себер җибәргәннәр,
Аяк-кулларыны богаулап.

Дүртенчесе: кайсы авылныңдыр
Бер кешесе кеше үтергән,
Ул да шулай тегеләр рәтеннән
Себер белән хөкем ителгән.

Ул заманда шулай, кеше үтергән
Кешеләрне дә шунда сөргәннәр.
Хөкүмәткә каршы кешеләрне дә,
Шунда сөреп, җәза биргәннәр.

Себер — авыр җәза урыны булып,
Эз калдырган минем күңелдә.
Анда озатылган һәрбер кеше
Киткән кебек булган үлемгә.

Үтеп чыга алмаслык тайгаларда
Зур-зур төрмәлар... таш коймалар...
Анда богауланган каторжаннар
Әле дә күз алдымда торалар.

II

Үсә төшкәч белгән идем инде
Эшчеләрнең сыйнфый дошманын,
Киң Себерне кемнәр нәрсә өчен
„Сөрген җире" итеп тотканын.

Белә идем, канлы сугыштан соң,
Ак бандалар тәмам җиңелгәч,
Кара еланнарның каһәреннән
Иркен Себер азат ителгәч,

Анда яңа тормыш төзелгәнен,
Якты кояш нуры төшкәнен,
Йөрәк яргыч төрмәләр урынына
Гигант заводларның үскәнен.

Белә идем, чиксез киң кырларның
Бизәлгәнен колхозлар белән,
Киң сахралар тула башлаганын
Төрле-төрле совхозлар белән.

III

Үз гомеремдә быел беренче рәт
Бардым мин дә иркен Себергә.
Яшь чагымда ямьсез, куркынычлы
Эз калдырган җирне күрергә.

Барам... Үзем уйлыйм:
— Шушы икән
Азат Себер, чиксез киң Себер...
Яшь чагымда ямьсез эз калдырган
Эшләр күренмиләр берсе-бер.

Искән жилгә ярышып барган поезд
Үтә чиксез басулар аша,
Минут саен яңа бирәр эшне
Ул кылдыра сиңа тамаша.

Зур заводлар, яңа элеваторлар,
Яңартылган зур-зур калалар,
Колхоз, совхозлар һәм коммуналар
Ике яклап тезелеп калалар.

Күреп үтәсең эш кайнаганын,
Гигант заводларның нигезен,
Йөзеп үткән кебек хис итәсең
Кайнап торган тормыш диңгезен.

Шундый диңгез: аның дулкыннары
Өстенлеккә карап юл тота,
Иске, зур корабның ватыкларын
Юлдан читкә алып ыргыта.

Алга барган саен, яңа тормыш
Төзелгәнен ачык күрәсең,
Күздән үткәрәсең миллионлаган
Эшчәннәрнең жиңү көрәшен.

Киң Себернең „сөрген жире“ булып
Торган вакты исеңнән чыга,
Аның һәр почмагын аерым-аерым
Күрер өчен күңел кызыга.

Тагын биш-ун елдан ничек булыр
Безнең азат Себер, киң Себер,—
Дип уйладым шунда.
Иске уйлар —
Калмадылар хәзер берсе-бер.

Матур Кырымнан да, Кавказдан да
Якын күренден син күңелгә,
Исән булсам, тагын бер килермен,
Хуш бул әле, Себер, хәзергә...

1930

ЯГЕЗ, ӘЙТЕГЕЗ

Әз-мәз җыерчыкланган йөземә
Яртылаш ак кергән чәчемә,
Бераз бөкерәйгән гәүдәм белән,
Олыгая төшкән төсемә...

Карыйлар да... мине танымаган
Яшьләр яңа исем бирәләр:
— Бабай!
Диләр миңа сүз кушканда,
Картлар рәтенә тезәләр.

Ялгышалар алар миңа „бабай"
Исемен биреп болай вакытсыз.
Әгәр бабай булсам, булыр идем:
Мин ялкынсыз, дәртсез һәм рухсыз!

Бик тиз генә сүнү ихтималы
Булмаган бер уттай мин янам,
Тагын да берничә бишьеллыкны
Күрүемә ныклы ышанам.

Көтәм әле:
Йөзәр мең гектарлы
Совхозларның меңәрләгәнен,
Аларда эш кайнап, миллиард потлар
Белән иген әзерләнгәнен.

Машиналар белән коралланган
Зур колхозлар тезелеп рәттән,
Шаулап торган җанлы тормышларның
Булуын көтәмен чын йөрәктән.

Нигезләре яңа корылып яткан
Гигант заводларның эшләнеп

Бетүләрен, кайнап эшләүләрен
Күтәм,
Шатлык белән дәртләнеп.

Әле минем, бөтен җир шарының
Инкыйлабын[1] күрәсем килә,
Өлкән инкыйлапның шатлыкларын
Күреп уйнап-көләсем килә.

Шул зур инкыйлапның бер солдаты
Булырымны уйлап шатланам,
Шул вакытта ялкынлы җырларны
Тагын язар минем шат каләм!

Көрәш барган чакта картаерга
Ярыймы соң дәртле кешегә,
Мин хәзергә бабай булганым юк,
Карамагыз минем төсемә!
Алдан бармасам да зур көрәштә,
Барырмын мин сафта бертигез,
Шундый кеше бабай буламыни,
Ягез, шуны миңа әйтегез!

1932

---

[1] Инкыйлап — революция.

МИН ВАТАНЧЫ[1]

Чиксез ватанчы мин
Совет иле
Булу шарты белән ул ватан,
Советларга дошман кеше миңа —
Дошман, әгәр булса да атам!
Совет, кешеләрне бөлгенлеккә
Салган сугышларга каршы,
Бездә сугыш маршыннан элек
Уйналадыр солых маршы.
Шуңа карамастан безгә берәр
Дошман башлап һөҗүм ясаса,
Беребез дә тыныч тора алмабыз,
Читтән генә кылып тамаша...

1932

[1] Язылып бетмәгән шигырь.

УЛ ҮЛМӘДЕ

Якын күршеләр дә белми кала
Кайбер кешеләрнең үлгәнен,
— Ул үлек кем?
Аның кемнәре бар?
Аны кемнәр илтеп күмгәнен!

Кайберәүнең үлеме мәгълүм була
Тик бер таныш-белешләренә,
Аның югалуы тик шуларга
Бераз кайгы булып күренә.

Кайбер олыларның үлүенә
Аерым берәр катлам кайгыра,
Я булмаса капиталист, байлар
Сыйнфы гына төшә кайгыга.

Аның өчен матәм тотучылар
Йөзләр, меңнәр белән чикләнә,
Ләкин дөнья эшчәннәре өчен
Исәпләнми ике тиенгә дә.

Әмма кайбер кешенең үлүе
Кайгы була миллионнар өчен,
Миллионнарча кеше йөрәгенә
Кадый зур югалту билгесен.

Шундый югалтуга мисал алсак:
Ильич Ленин аның мисалы,
Аның үлүеннән әсәрләнә
Шиксез бөтен эшчән җир шары!

Кайберәүләр үлсә, еллар үтү
Белән истән чыга — онытыла.
Аның эзе ком бураны баскан
Кебек бетә... бер көн юк була.

Әмма, кайберәүләр еллар үткән
Саен күбрәк искә алына,
Күп җирләрдә һәйкәл салына,
Исеме күңелләргә языла.

Аның тәгълиматы миллионнарча
Кешеләр тарафыннан ятлана,
Аның үзе...
Сөйләгән сүзләре
Күңелләрдә мәңге саклана.

Аның юлы оста инженерлар
Салган туры,тигез юл кебек
Булып ялтырап тора,
Юк сикелтә, юк пычрак
Һәм дә юк өзек.

Менә хәзер шуңа мисал өчен
Иң муафыйк һәм иң яхшысы
Ленин булыр,
Мәңге балкып торган
Җир йөзендә сүнмәс яктысы!

Үлгән кебек түгел миңа Ленин,
Ул һаман да исән төследер,
Чөнки аның корыч партиясе
Армас-талмас, сүнмәс көч бүген.

Шуның өчен еллар үткән саен
Хөрмәт белән тәкъдир ителә,
Аның тәгълиматы өскә чыга,
Дошман барган саен җиңелә.

1933

КОЛХОЗ ФРОНТЫНДА ҖИҢҮЧЕЛӘРГӘ

(Ударчы колхозчылар съездына багышлана)

I

Ачык сугышларда дошманнарның
Көче һәм алар кемлеге,
Аңа каршы торган гаскәрләргә
Бик күп яктан була билгеле.

Андый сугышларда сыйфатыннан
Беленеп тора синең дошманың,
Мәгълүм дошман белән көрәшүнең
Җиңел яклары да күп аның.

II

Була шундый көрәш: бу көрәштә
Дошман йөри, бергә, арада,
Искәртмәстән сиңа аяк чалып
Егу уе яна аларда.

Уйлары бер була ул халыкның,
Торсалар да төрле урында,
Мондый дошманнарның ите-чиге
Булмый сыйнфый көрәш чорында.

Алар иске тормыш „гаскәрләре“,
Яңалыкка чиксез дошман як;
Хата булмас, барын бергә җыеп,
„Иске тормыш“ белән атасак.

III

Күп яшәгән, карт ул „иске тормыш“,
Форсат тапкан җирдә көчле ул,
Ачык фронтларда җиңелгәннән
Бирле, яшерен генә эшли ул.

Микроб төсле, бер дә сиздермичә,
Тезелә ул безнең рәткә,
Ачык дошман төсле бер сурәттә
Тормый, керә төрле сурәткә:

Бүген мулла сыйфатында булса,
Икенче көн попка әйләнә,
Бүген сүнгән күмер төсле йөрсә,
Форсат тапса, утка әйләнә.

Кайсыберсе аның „спец“ булып
Керәп ала бик зур урынга,
Синең белән „яхшы мөгамәлә“ итә,
Спай була үзе буй-сынга.

Көләч йөзе, йомшак сүзе белән
Керә кешеләрнең эченә,
Үз эшеннән артык карагандай
Күренә советларның эшенә.

Әмма советларга чиксез ачу белән
Тулган була аның йөрәге,
Кайда зарар итү мөмкин булса,
Зарар итү була теләге.

Кайчагында кулак коткысында
Йөргән батрак булып китә ул,
Иске „батрак“лыгын корал итеп,
Колхозларны сүгеп тетә ул.

Ул була ала урыны килгән чакта
Юлбасар да, усал карак та,
Бугазыңнан буарга әзер ул
Сине очратса аулакта.

Кайбер вакыт мескен... бетеренгән,
Тәмам „яхшыланган“ бер кеше
Булып күренә ул, берәр эшкә
Яки бер колхозга кергәнче.

Эшкә кергән чорда бик сакланып
Җыеп йөри итәк чабуын,
Әмма, бераз тамыр җәю белән
Чәчә башлый үзенең агуын.

IV

Карт ул „иске тормыш“, карт булса да,
Һаман аның яшисе килә,
Ләкин хәзер бик нык чолганылган,
Инде җибәрелмәс иркенә.

Эчке дошманнарның:
„Бу дошман“,— дип,
Булмый маңгаена язулы,
Ләкин алар аңсыз күп миләргә
Һаман җибәрәләр агуны.

Бу дошманнар белән көрәшергә
Көчле гайрәт, зур ирлек кирәк,
Һәрбер хәрәкәтләрен белеп торыр
Өчен чиксез сизгерлек кирәк.

Алар советларга каршы астан
Бик нык көрәшәләр, күрәсез;
Нинди дошман бар соң, җир йөзендә
Егылсын ул җиргә көрәшсез!

V

Бездә көрәш фронтлары бик күп,
Әллә ничә якта тармагы,
Колхозларны яхшы төзү өчен
Көрәш бу фронтның бер ягы.

„Иске тормыш“ның сез дошманлыгын
Нәкъ үз вакытында сиздегез,

Колхоз фронтында сез аларны
Бик яхшылап, шиксез, җиңдегез.

Туры килде сезне тәбрик итеп
Шулай берничә сүз сөйләргә.
— Рәхмәт, колхоз төзү фронтында
Дошманнарны җиңүчеләргә!

1933

БОЛЫТСЫЗ КҮК КҮКРӘГӘНДӘ[1]

(Кызыл Армиянең XV еллыгына)

Кояш бүген артык юмартланган,
Күз чагыла көчле яктыга,
Күк йөзендә болыт кисәге юк,
Очып йөргән аккош чаклы да.

Күз җитмәслек җиргә сузылган күк
Тонык сулардан да тып-тонык.
Усак яфрагын да селкетерлек
Җил юк бүген,
Шундый көн тынык.

Көн болытсыз. Шуңа карамастан
Күк күкри өсте-өстенә,
Әллә кайдан, җирне дер селкетеп,
Торган шәп тавышлар ишетелә...

Чиксез зур куркыныч көткән кебек
Шәһәр шаулый,
Халык гөж килә.
Әйтерсең лә, диңгез басып килә,
Яисә тиздән була зилзилә[2].

Бу „куркыныч“ ләкин күп кешеләрдә
Барган саен шатлык тудыра,
Гүя болар өчен тиз арада
Бик күңелле зур бәйрәм була.

---

[1] Гражданнар сугышы чорында данлыклы Кызыл Армия тарафыннан Уфа шәһәре алыну күренешләреннән бер өземтә.
[2] Зилзилә — җир тетрәү.

Бизгәк тоткан төсле калтырана
Куркуыннан кайбер кешеләр,
Киндер кебек агарган йөзләре,
Хәзердән үк үлек төслеләр.

Бу „кешеләр“ качар урын эзли,
Курыккан кеше төсле үлемнән,
Байлык белән торган тормышыннан
Аерылган кебек бүгеннән.

Кайберләре сукыр тычкан кебек
Җиргә күмә алтын, көмешен,
Хәлдән таеп ящерен чокыр казый,
Мал-мөлкәтен ящерер өчен.

Кайберләре байлыкларын төяп,
Качу юлын карый Себергә,
„Бу куркыныч барып җитмәс җиргә“,
Шунда тыныч гомер сөрергә...

Кайберләре үзенең алласына
Дога кылып, шуңа баш ия.
Калтырата аны:
Давыл кебек
Басып килгән Кызыл Армия!

Ахры, дошман каршы тора алмады
Кызыл Армиянең көченә:
Курку алган Колчак гаскәрләре
Сыендылар шәһәр эченә.

Мәйданнарга туплар тезелделәр,
Кызыл гаскәр өстенә төзәп,
Каты давыл кебек шаулап килгән
Көчнең юлын буарга теләп.

Шәп аучылар куып, камап алган,
Үлем алдындагы бүреләр
Ничек булса, Колчак бандитлары
Шундый ерткыч төсле йөриләр.

„Нинди генә хәлләр булганда да
Уфа кызылларга бирелмәс!
Данлы гаскәребез бу урыннан
Бер адым да артка чигенмәс!..

Шул теләктә булырга тиешле
Сәдакатьле ватан баласы,
Дошман яклы булган хаиннәргә
Мәрхәмәтсез үлем җәзасы!"—

Дип басылган кара сәхифәләр
Чуарлады урам чатларын...
Атлы казаклары „көч" күрсәтеп
Чаптыралар менгән атларын.

Мондый кешеләргә урамнарга
Чыгып йөрү кискен тыелды,
Урам саен шымчы, почмак саен
Көчле каравыллар куелды...

Атты беренче туп,
Колакларны тондырырлык булып
Шартлады.
Аның артыннан ук дистәләгән
Туплар бердән ата башлады.

(Катгый[1] сугыш хәзер, һәр ике як
Бер-берсенә каршы ярсыган),
Снарядка каршы снарядлар
Белән җавап килде каршыдан.

Моннан алай, аннан болай таба,
Бердән берничә туп атыла,
Һава калтырана... җир тетри...
Туплар төшкән өйләр ватыла...

Бертуктаусыз һава гөрләп тора,
Әйтерсең лә җирләр убыла,
Яисә җирдән бәреп чыккан вулкан
Белән таулар шаулап умырыла...

Бу куркыныч сугыш бертуктаусыз
Дәвам итте атна буена.
(Мондый кешеләргә бу куркыныч
Мәңге бетмәс кебек тоела)...

---

[1] Катгый — кискен.

Менә беркөн, никтер капыл гына,
Туплар, пулеметлар тындылар,
Аклар шым булдылар... зур шәһәрне
Ташлап әллә кайда шылдылар...
— Ура-ура!..
— Нәрсә булды, иптәш?..

— Нәрсә булсын, әнә Кызыллар
Нәкъ ярсыган арсланнар кебек
Төрле яктан кереп тулдылар.
— Шулаймыни, чынмы?..
— Ура-ура!..
— Зур бәйрәм бу эшчәннәр өчен!
Дошман гаскәрләрен тар-мар иткән
Данлы Кызыл гаскәр яшәсен!..

1933

ЭЛЕККЕ „УЛ“ ИНДЕ КЕШЕ БУЛДЫ

I

Үлек дисәң, болай үлек түгел,
Һич шөбһәсез, тере иде „ул“.
Хайван дисәң, дүрт аяклы түгел,
Ике аяклап йөри иде „ул“.

„Зәгыйфьтер бу“ — дигән уйга килсәң,
Зәгыйфь төсле түгел иде „ул“,
Таңнан алып кара төнгә чаклы
Һичтуктаусыз эшли иде „ул“.

Болай телсез кебек күренсә дә,
Телсез түгел иде — телле иде.
Тавышын ирләр ишетмәслек җирдә
Сөйләшүе шуңа билге иде.

Ир-ат заты булмаган җирләрдә
Бик моңланып җырлый иде „ул“.
Күп вакытта авыр кайгысыннан
Үксеп-үксеп елый иде „ул“.

Һәрбер „бүрекле баш“ очраганда
Битен каплап кача иде „ул“.
Өйдә ялгыз калган чакта гына
Бөркәнчеген ача иде „ул“.

Җир йөзендә һичбер җан иясе
Йөзен ябып йөрми, йөрмәде.
Тик бу мескен генә ябынып йөрде,
Йөзе кояш нурын күрмәде.

Хайван яисә товар төсле булып,
Сатыла торган иде „ул“ үзе.

Хакы сатучының, алучының
Байлыгына карап йөреде:

„Түбән нәселле“ һәм ярлы, батрак
Булса әгәр ата-анасы,
Сарык, кәҗә белән бер чамада
Йөри иде „аның“ бәясе.

Ятим булса, аңа билгеле бер
Хак та куеп тормыйлар иде.
Кайда барса — анда ул мескенне
Мыскыл итеп, хурлыйлар иде.

Ипле сәнәк, яхшы тырмаларны
Кулга тотып (бер дә күңелсез),
Диләр иде:
— „Иллә шәп икән соң...
Ятим кызларга да биргесез!..“

Шулай хайван төсле сатканнан соң,
„Аның“ озын, бөтен бер гомерен,
Мулла никах укып баса иде
„Аңа“ мәңге коллык мөһерен[1].

Карамыйча „аның“ күз яшенә,
Дөрләп янган йөрәк утына,
Һушсыз хәлдә озаталар иде
Яңа хуҗасының йортына.

Анда баргач, ямьсез кара бер көч,
Шыкырдатып азау тешләрен,
Ачу белән карап сөйли иде
„Аның“ моннан соңгы эшләрен.

— Менә сиңа себерке, пумала,
Ялгаш, көянтә һәм бидрәләр,
Күптән мирас килгән бу нәрсәләр
Инде синең кулга биреләләр.

Әнә сиңа табак, таба, казан,
Җилпуч һәм чүмеч, кашыклар.

---

[1] Мөһер — печать.

Яхшы аңла,
Синең гомерең буе
Иптәшләрең булыр шушылар!

Кыр эшләрен эшләргә тиеш син!
Монда санап тормыйм аларын.
Сыер савып, малларны карарсың,
Тазартырсың сыер абзарын!

Ирнең өстен-башын, аякларын
Чишендерү, кулын юдыру...
Мунча ягу, аңа сулар ташу,
Тары төю, керләрне юу —

Һәммәсе дә сиңа йөкләнәләр!..
Сүзсез эшләү синең бурычың,
Шулар белән үтәргә тиешле
Гомер буе синең тормышың.

Син шулардан башка бернәрсә дә
Аңламаска, белмәскә тиеш!
— „Бу ник болай?
— Теге нигә алай?“ —
Дип сораулар түгел синең эш!

Аның бу сүзләрен башын иеп,
Кул кавыштырып тыңлый иде „ул“.
Аның кушканнарын гомер буе
Эшли, каршы тормый иде „ул“...

II

Элекке „ул“ инде кеше булды,
Унбиш елдан бирле кеше ул,
Яңа тормыш төзү көрәшендә
Төп ике көчнең берсе ул.

Яшәмиләр хәзер тоткынлыкта,
Көн күрмиләр кысынкылыкта.
Башка илләрдәге хатын-кызлар төсле
Чикләнмиләр алар хокукта.

Колхоз, совхоз, фабрик-заводларда
Алар җиң сызганып эшлиләр.
Совет төзелеше турысында
Сөйләгәндә ярып сөйлиләр.

Рабфаклар, төрле техникумнар,
Әллә ничә төрле ВУЗларга
Керү белән, очрыйсың син анда
Йөзәрләгән хатын-кызларга...

Хәзер доктор, техник, агрономнар
Азмы алардан безнең арада?
Элекке „ул“ хәзер инде үзе
ВУЗда укытучы була ала.

Элекке „ул“ хәзер бергә эшли
Ирләр белән торып янәшә.
Башка илләрдәге хатын-кызлар
Азатлыгы өчен көрәшә.

Эшлә, укы! Укып, аң-белем ал,
Янып торган эшчән кеше бул!
Кайнап торган хәзерге тормышта
Сиңа киң рәвештә ачык юл!..

1933

ДӘРТЛЕ ЯШЬЛӘР

(1912 нче елда туганнарны Кызыл Армиягә чакыру уңае белән.)

Җыелганнар бүген призывка
Көчле илнең дәртле яшьләре,
Эшчәннәрнең Совет туфрагында
Яңа үсеп җиткән көчләре.

Ярышып торган төсле күренәләр
Кызыл гаскәр исемен алырга,
Хәзердән үк хәзер торган кебек
Дошманнарга курку салырга.

1934

МӘСӘЛЛӘР

САРЫКНЫ КЕМ АШАГАН

Бер аучының бер сарыгы кырда калган,
Эзләп тә тапмаганнар — ул югалган.
Бер-ике көн үтеп киткәч, безнең аучы:
„Бүре ашаган сарыкны“,— дип хәбәр алган.

Моны ишеткәч, аучы чиксез ачуланды,
Ерткычларның бу эшенә көйде, янды.
— Сарыкның үчен алмый калмамын,— дип,
Җанварларга шушылай дип хәбәр салды:

„Кызганып тора идем үзем сезне,
Ачулансам, калдырмамын берегезне.
Сарыгымны кем ашаса, шул кешене
Таләп кыйлам, миңа тотып бирүегезне!“

Аучыны белә урманда һәрбер җанвар.
Бу хәбәрне ишеткәчтән таң калдылар.
„Аучыны тизрәк риза итик“ диеп,
Киңәш өчен бер урынга җыелдылар.

Мәҗлестә төлке катип[1], бүре рәис[2],
Рәис сүз башлап әйтте: „Бу нинди эш!..
Аучының сарыгын кем ашады?
Танмаенча ошбу җирдә әйтү тиеш.

Шул эш өчен чакырдым мин монда сезне:
Ачуланса аучы кырыр һәммәбезне.
Кем ашаса, шуны биреп котылаек,
Тугрылыктан аермагыз үзегезне...“

---

[1] Катип — секретарь.
[2] Рәис — председатель.

Әүвәл бүре: „Ашамадым“,— диде, танды,
Төлке дә тугрылыгын сөйләп алды.
Һәммә ерткыч үзләрене ахладылар.
Бер як читтә ерткыч түгел куян калды.

Диде бүре: „Читтә торып ялгыз үзең,
Бур кешенең күзе төсле ике күзең.
Сарыкны ашаган кеше син түгелме?
Әйтеп кал! Монда килеп, әйтер сүзең!“

Куян мескен куркуыннан калтырады,
„Ашаучы мин түгел“,— дип, чак әйтә алды.
Шөбһәле кеше төсле җавап биргәч,
Барча ерткыч: „Ашаучы шул“,— дип аваз
салды.

(Ашамый куян һичбер вакытта ит),
Әйтә алмады: ашаган мин түгел дип.
„Сарыкны ашаган дуңгыз шушы икән“,—
Диде бүре: „Китерегез бәйләргә җеп“.

Шул сәгать әллә кайдан җеп таптылар,
Куянның муенына җеп тактылар.
„Усаллыгың җәзасын тарт, менә инде“,—
дип,
Аучының авылына озаттылар.

Бүре төсле ерткычларга киңдер җиһан,
Һәркайда золым күрер мескен куян.
Зарарлы бәндә булып күренерсең,
Башкаларга кыйлмасаң да һичбер зыян.

1913

ИКЕ ЧЕБЕН

Бер үгез көн буенча сөреп сабан,
Авылга кайтып килә кичкә табан.
Үгезнең мөгезенә кунып килгән
Бу чебенгә бер танышы очраган.

Танышы шул вакытта моны күрде,
Килә бу сабан сөргән үгез белән.
„Күземә күренмәдең көн буенча,
Кайдан кайтып киләсең син?“—дип сораган.

Теге чебен эреләнеп, моңа карап —
Зурланып, тамак кырып бирде җавап:
„Көн буе сабан сөреп, арып киләм,
Вакытсыз йөрмә әле бимазалап“.

Сөйләшсәң чебен төсле кеше белән,
Мактаныр эшләмәгән эше белән,
Көн күргән кешеләр күп бу дөньяда,
Чебен кебек, башкаларның көче белән.

1911

БАБАЙ БЕЛӘН АЮ

Аю белән бабай бер ел икәүләп чәчтеләр шалкан.
Үсеп җиткән бу шалканнар, кап уртаклап бүлү калган.

Бабай әйткән: „Син ал яфракларын, тамырын алырмын мин“.
Аю „ярар“ дигән, риза булып, яфракларын алган.

Икенче ел шулай ук бергә-бергә чәчтеләр богдай[1].
Пешеп богдай, урыр вакыт якынлашкач, диде бабай:

„Кил, иптәшем, аю, богдай тәмам пешкән, ни дисең син?
Бу ел тамырын син ал инде, башакларын алырмын мин“.

Аю, үткән ел алдангач, бу ел алданмыймын мин дип,
Диде: „Хуш, тамырыны алыйм, башакларны гына ал“,— дип.

Риза булып, аю тамырын, бабай гел башларын алды:
Аю, ахмак, ике ел да гакыллы карттан алданды.

Шулай ук бу кешеләрдә аюга охшаганнар күп.
Яман, яхшы арасын белмәгән, аермаганнар күп.

Кешегә файдалы эшне зарар дип уйлаганнар күп,
Зарарлы эшне дә файдалы дип әйткән наданнар күп.

1913

---

[1] Богдай — бодай.

ТАВЫК БЕЛӘН ҮРДӘК

Бер тавык бер үрдәк белән бергә торып,
Бер курада бергә ашап, бергә йөреп,
Бара торгач, бер-берсенә дуслаштылар,
Берсе-берсен туган төсле якын күреп.

Үрдәк бара көн саен бер күл буена,
Аннан кайткач, йортта тора көн буена;
Тавык өйдә ялгыз торып калган чакта,
Төрле күңелсезлек төшәдер уена.

Беркөнне диде тавык: „Туганкаем!
Кайда барып кайтасың син һәр көн саен?
Миңа монда ялгыз тору бик күңелсез,
Синнән башка торып һичбер ямь тапмаем“.

Диде үрдәк: „Барамын мин һәр көн күлгә,
Күлдә йөрсәм, рәхәт буладыр күңелгә;
Анда мин йөзәм, чумам, кагынамын,
Тазарам, матурланам йөзеп күлдә“.

Тавык сорый: „Ул матур күл кайсы җирдә,
Моңарчы ник әйтмәдең миңа бер дә?
Мин дә барып, рәхәтләнеп йөрер идем,
Йөзеп, чумып уйнар идек бергә-бергә“.

Үрдәк әйтә: „Барам дисәң, ярый, бик хуш;
Ник бармаска, безнең төслүк син дә бер кош.
Йөзеп, чумып, юынып, тазарып кайтырсың,
Көн буена бикләнеп, тик торганчы буш“.

Киттеләр болар күлгә иртүк торып,
Тавык бара йөзәр өчен план корып;
Бару белән, үрдәк күлгә төшеп китте,
Чума, йонын юа башын борып-борып.

„Ни карыйсың? Әйдә инде син дә төш“, ди;
Шулай дигәч, тавык суга барып төште.
Төшү белән тавык суга бата башлап,
Ихтыярсыз байтак кына су да эчте.

Чыгарга әйтә, үзе һаман китә эчкә,
Аягы җитми торган тирән төшкә,
Үрдәк тә хәйран булып карап тора,
Якын дусы дучар булгач мондый эшкә.

Тавык, мескен, үлмәс өчен чабаланды,
Җаныннан өмет өзде, гаҗиз калды.
Ярый әле шул вакытта берәү күреп,
Кызганып, бу тавыкны төшеп алды.

Тавык өйгә кайтып керде көчкә-көчкә,
Гадәттән тыш су тулган булгач эчкә;
Үкенде батырчылык кыйлганына
Кулыннан килми торган мондый эшкә.

1913

ПЕСИ ҺӘМ ТЫЧКАННАР

I

Менә бер яшь кенә тычкан олуг тычканга барган, ди,
Төсе киткән, хәле беткән, үзе тәмам агарган, ди.

„Ни булды? Нәрсә күрдең?“ — дип, кабат-кабат
сорый картың;
Теге тычкан да куркудан кабат-кабат карый артын.

„Менә вәт нәрсә!“ — ди дә сүзен тәмам итә алмый;
Гаҗәп курыкканлыгыннан ул тора урынында
кузгалмый.

Бераз торгач: „Ишеттеңме? Песи бит патша
булган“, — ди;
„Ки ягъни ошбу көннән соң бу дөньяга песи
хан“, — ди.

Моны ишеткәч тә, карт тычкан керешге чара
эзләргә;
Гакыл яисә куәт берлә дөньяны тигезләргә.

Диде: „Гаскәр җыеп сансыз үземез барча тычканнан,
Безә[1] файдалы эш булмас явыз белән сугышканнан“.

II

Кылып төрле киңәш, соңра сугыш кылмакчы
булдылар.
Песи тәхетен җимермәкче булып бергә җыелдылар.

---

[1] Б е з ә — безгә.

Песи гафләттә торганда, һөҗүм итмәк булып бергә,
Кара чәукә кебек, тычкан китә „мичбаш“ дигән җиргә.

Баралар, күрәләр анда — песи карап тора ялт-йолт.
Менә кычкыра тычканнар: „Әнә, дуңгыз песине тот!“

Карап тик утыра песи, тавышка илтифат итми:
Кая курку дигән-нәрсә? Колак, койрык та селкетми.

Ничә мең булсалар да, куркалар шул, берсе дә бармый,
Бере-берсенә: „Син бар!“ ди, теге әйтә: „Үзең бар!“ ди.

Нигәдер?.. тик тора торгач, песи койрыкны селкетте,
Дөбер-тасыр, бу тычканнар бары үз урынына китте.

Бераздан кылдылар тәфтиш[1], бер иптәшләре юк булган,
Димәк, шул арада аны явыз патша тотып калган.

Бере-берсен кылып шелтә, диләр: „Син мут, элек качтың,
Бүтәннәр үлсәләр үлсен, үзеңне коткару кастың![2]“

III

Үтә көннәр, песи тычкан ашый, бер көн карап ятмый,
Песинең золымы үткәннән бу тычканнарга аш батмый.

Шулай дөньяда хәсрәт берлә көн күрә хәлсезләр,
Тәмам гаҗиз булып һичбер чара тапмый тонар күзләр.

---

[1] Кылдылар тәфтиш — тикшерделәр.
[2] Кастың — теләгең.

IV

Бара торгач, песи тычкан тотуны да авырсынды,
Әзер ит, май куелган җиргә беркөнне барып кунды.

Шулай һәр көндә ит, майны барып ашап ята
хәлсез.
Тотып торасы да юктыр, бигрәк тә михнәтсез.
Бара торгач, песинең бу хыянәтен хуҗа сизде,
„Минем икмәк вә тоз хакын белә алмады бу
комсыз“, диде.

Ике-өч тапкыр тотылды бу песи, хуҗа һаман түзде.
Бишенче рәт тотылгач та песинең муенын өзде.

Шулай, дус, дөньяда бик төрлечә була икән көчләр.
Гаҗиз булган кешеләрнең гүзәл булып китә эшләр.

Шулай ук дөньяда бар көчлеләрдән дә дәхи көчле...
Золымның чигенә җиткәч, һәлак булыр песи төсле.

1910

ЧИКЕРТКӘ БЕЛӘН КЫРМЫСКА

Чикерткә җәй буе шатлык белән үткәрде көннәрне,
Һавалар саф, үләннәр чәчкәләнгән, сахралар ямьле.

Эссе көннәр, әзер өй бар, ашыйм дисә, азыклар мул,
Әзерне ашый, әзерне эчә, әзер өйдә тора бит ул.

Үтеп көннәр, җитеп көзләр, һавалар салкынайт-
качтан,
Менә чикерткә нишләргә белә алмый гаклыннан
шашкан.

Үләннәр шиңделәр, саргайдылар; инде карын ачты;
Суыклык белән ачлыктан үләр көннәр якынлашты.

Гаҗәеп карны ачкач, күршесе кырмыскага барды:
„Мине туйдыр, җылы җирдә урын бирсәнә,
зинһар“,— ди.

Диде кырмыска: „И ахмак! Йөрисең җәй буе сайрап:
Бу салкынлык килүне белмәдеңме җәй көне азрак.

„Бүген ашарыма бар“ дип, хафасыз бушка йөрмиләр,
Җылы көн, кулда форсат бар вакыт кышлык
әзерлиләр“.

Гакыллылар эшен вакытында эшли,
Чикерткә кеби тик йөрмәү тиешле.

1913

ҖИЛӘК БЕЛӘН АЛМА АГАЧЫ

Ике-өч еллык кына алма янында бер җиләк үсте,
Шушы язда чәчәк атты, бер айдан соң тәмам
пеште.

Шушы бик аз вакытта бу җиләк алланды, балланды;
Матур көннәрдә көнгә каршы ялтырап, ут кебек
янды.

Җиләк күрә үзендә бу кызыллыкны, матурлыкны;
Күрә алма агачында җитешсезлек вә хурлыкны.

Карап алма агачына, диде: „Әй, бик якын күршем!
Үсәсең берничә еллар — һаман да юк синең
җимешең.

Мин үстем, чәчкә аттым һәм җимешләндем ике
айда;
Торасың берничә еллар, сиңа бу зур бәхет кайда?“

Диде алма агачы: „Әй җиләк, бел, кемдәдер кимлек:
Ике-өч айда җимешләнсәң, синең бәхетең дә өч
көнлек.

Синең төсле ике айда бөтенләйгә бетеп калмам,
Үсәрмен берничә еллар, булыр һәр ел саен алмам...“

Озак та үтмәде шуннан, каты яңгырлы җил исте,
Шушы җилгә чыдый алмый, җиләк җиргә авып
төште.

1913

ИКЕ КАЗ БЕЛӘН БАКА

Бар иде бер күл, тирә-ягында саз.
Көн итә иде монда бака һәм ике каз.
Дус булып торды болар бергә-бергә.
Бара торгач, булып китте көннәр аяз...

Көннән-көн сеңә күлнең суы җиргә,
Казларга уңайсызланды йөзәргә,
Ике каз, китми булмас бу җирдән дип,
Килделәр бака янына күрешергә.

Диделәр: „Якынлашты су бетәргә,
Мәҗбүр булдык инде бу җирдән китәргә".
Бака әйтә: „Сусыз мин дә тора алмыйм,
Инде соң алай булгач, мин ни эшләргә?

Мөмкин түгел көн күрүем сусыз җирдә,
Кил зинһар! Алсагызчы мине бергә".
Ике каз: „Ярый алай булса" дигәч,
Бака әйтте: „Юл бармы соң күтәрергә?"

— „Чыбыкның икебез ике башыннан
Күтәрербез, син тешләрсең уртасыннан;
Безне күреп кешеләр гаҗәпләнә калса,
Сакланырсың авыз ачып сөйләшүдән".

Чыбыкны тешләп алды бака әфәнде;
Казлар да бик югары очып менде.
„Казларның уртасында бака бар" дип,
Карап торган һәммә кеше гаҗәпләнде.

Күргән бер кеше эче катып көлде.
Боларның көлгәннәрен бака белде:

„Күзегез чыксын, кешеләр“ димәк булып,
Авызын ачкан иде... төште, үлде.

Уйласаң, монда да бар бер гыйбрәт:
Сүзне дә урынында сөйләү кирәк,
Нәсыйхәтне тыңламасаң, күп сөйләсәң,
Зарарын үзең күрерсең бигрәк.

1913

ӘТӘЧ БЕЛӘН САНДУГАЧ

Әтәч йөри җим эзләп, аяк илә типкәләп,
Янында бар тавыклар—бары җиде сигезләп.

Әтәч мохтаҗ азыкка һәм ихласы — зәвыкка,
Сирәк-сирәк кычкырып, гайрәт кыла тавыкка.

Сандугач күзен салып, урыныннан кузгалып,
Тәрәзәнең төбеннән әйтте әтәчкә мактанып:

— Әй әтәч, син бичара, болай таба бер кара!
Кечкенә бу сандугач ничек көнен уздыра!

Тәмле орлыклар ашап, рәхәтлек илә яшәп,
Синең кебек җир казып, күрмимен һичбер азап.

Чүплек башына барып, йөрмимен чүп актарып!
Әтәч, моны ишеткәч, җавап бирде кайтарып:

„Ни файда аш куплектән? Чыга алмыйсың
читлектән.
Хөр көенчә азык эзләү күп артыктыр чүплектән.

Мине кара, ничек хөр! Кайда барсам анда бер,
Ошбу йөргән җиде тавык — барысы минем
хатындыр.

Уйнап-көләм теләсәм, теләгәнчә сөйләшәм,
Кайсы җирем синнән ким, орлык ашап үсмәсәм?

Торган урының бик тар, тарлыкта ни рәхәт бар?
Кайгы-хәсрәтең куплектән, кыйласың син аһ-зар.

Адәмнәргә син әсир, торган җирең бик тар җир.
Ничек чыдап торасың, сандугачым, җавап бир!“

Әтәчкә җавап тапмый, гаҗиз калды сандугач.
Башыны түбән салды, башка хәйлә тапмагач.

Гыйбрәт илә монда бак, әтәчнең һәр сүзе хак,
Әсир булып тук торудан хөр булу артыграк.

Булмаса һич ихтыяр, ләззәттә ни рәхәт бар?
Хөрлек ни дигән сүз ул? Өйрәнегез балалар!

1907

КӘҖӘ ТӘКӘСЕ БЕЛӘН КӨЗГЕ

Бер тәкә урам буйлап гизеп йөрде,
Йөри торгач, ярминкәгә барып керде;
Әрле-бирле куылгалап йөри торгач,
Сөяп куйган гаҗәеп зур көзге күрде.

Көзгенең каршысына барып торды,
Көзгедә үзе төсле тәкә күрде;
„Мотлака[1] сөзешү лазым булды[2]“ диеп,
Башыны бер күтәрде, бер төшерде.

Көзгегә карап тора күзен алмый,
Җилкенә, тик тора алмый, чыдаша алмый;
Бу кузгалса, теге тәкә һәм кузгала,
Кузгалмаса, теге тәкә һич кузгалмый.

Ачуы урынына тәмам житте,
Бик ныклап сөзешергә сүз беркетте;
Көзгедә карап торган дошманына
Куәт белән текәр өчен артка чикте.

Тәкәнең көчлелеген инде кара!
Сөзәм дип, зур көзгегә таба бара;
Аягүрә баса биреп сөзгән иде —
Зур көзге булды шундук пара-пара.

Тәкә сөзде, матур көзге тәмам ватды,
Теге тәкә югалды, бу ялгыз калды;
Көзгенең хуҗасы, бу эшне күргәч,
Тәкәнең мөгезеннән тотып алды.

Хуҗа әйтә: „Бу тәкәне кем чыгарган?
Монда килеп зыян итте, көзге ватты;
Көзге хакын түләп алсын хуҗасы“, дип,
Тәкәне туп-туры частька[3] озатты.

[1] Мотлака — һичшиксез, шөбһәсез.
[2] Лазым булды — тиеш булды.
[3] Частька — полициягә.

АТ БЕЛӘН ЭТ

Кыздыра кояш җир өстен,
Көн бүген чиксез эссе;
Шул вакыт сабан сөрәдер
Ялгыз атлы бер кеше.

Тирләгән ат, өстенә
Черки, кигәвен йончыта,
Ат хуҗасы көн эсселек-
тән һаман да ут йота.

Хәл җыярга туктаганда,
Ат янына эт килә —
Башта рәтләп сүз дә кушмый,
Елмаеп аттан көлә.

„Ник көләсең?“ — дип сорый ат,
Эт шунда җавап биреп, —
Ди: „Көләмен, и бичара ат,
Синең хәлеңне күреп.

Ни йөрергә мондый эссе
Чакта соң сабан сөреп?
Булмыймы, минем кебек,
Кырда сиңа да тик йөреп.

Ямь-яшел җирне карайтып,
Тот та җирне сөр имеш!..
Сүз дә әйтмәс, көлмәс идем,
Булса бер файдалы эш“.

Эткә ат җавап бирә:
„Сүзең урынлы, бик дөрес,
Эт күзе белән караган
Чакта бу файдасыз эш.

Көзгәрәк күрсәң иде
Бу җирдә нәрсә үскәнен,
Һәммәбезне туйдыра торган
Игеннең пешкәнен.

Әйтмәс идең: эсседә
Ни эшләп йөрисез монда? дип,
Көлмәс идең эшнең аслын
Белмичә авыз җәеп".

1914

САНДУГАЧЛАР

Бер бакчада үскән иде төрле агачлар,
Ал, кызыл чәчкә белән аралашлар.

Моның кеби яхшы урын булмас дия,
Очып килеп утырды күп сандугачлар.

Яфраклы ботакларга кунганнан соң,
Һәрберсе башка төрле сүзне башлар.

Матур үскән агачларга гашыйк булып,
Чәчәкләрдән башка җиргә карамаслар.

Берсенә икенчесе салган колак,
Сайрашып утырдылар болар озак.

Боларга карчыганың күзе төшеп,
Тотар өчен һәр тарафтан корды тозак.

Уйлады, хәйлә белән тотар өчен,
Сарыф кылды ошбу юлда бу бар көчен,

Боларның гафләтләрен форсат белеп[1],
Шатланды, тотып алып йотар өчен.

Сандугачлар һәркаюсы кырып тамак,
Эшләре, файдасы юк, гел мактамак.

Сандугачлар гафләт илән утырганда,
Карчыга тотар өчен салды тырнак.

Бик тиз генә башлыкларын тотып алды,
Калганнары курка-күрка һәп[2] таралды.

---

[1] Гафләтләрен форсат белеп — ваемсызлыкларыннан файдаланып.

[2] Һәп — тиз үк.

Карчыга, бичараны ашап беткәч,
Башкасыны тотар өчен күзне салды.

Сандугачлар карчыганы онытканнар,
Сайрашып утыралар дәхи анлар[1].

Карчыга икенче рәт һөҗүм итеп,
Таратты ничә җиргә түгеп каннар.

Бара торгач, сандугачлар калды азга,
Йөз тотты бичаралар инкыйразга[2],

Хыянәтсез саф калепле[3] сандугачлар,
Карчыгага азык булды бөтен язга.

Һичберсе котылмады карчыгадан,
Үз хәленнән бичаралар үзе надан.

1907

---

[1] Анлар — алар.
[2] Инкыйразга — бетүгә.
[3] Саф калепле — керсез күңелле.

ИШӘК

Бар икән бер кешенең ялгыз ишәк,
Башына бу кешенең төште исәп.
Шәһәргә барып кайту уе белән
Чыгып китте ишәгенә нәрсә төяп.

Җәйге көн, өсләренә кояш төшеп,
Баралар юл буенча янып-пешеп;
Хуҗаның теле корып авызы кипкәч,
Уйлады ял итүне саф су эчеп.

Ишәкнең дә сусавы тәмам җитте,
Бер адым алга атларга хәле бетте;
Ишәкнең сусаганын хуҗа сизеп,
Агым суга сугарырга алып китте.

Чылтырап агып яткан суны тапты,
Ишәкнең тезгененнән суга тартты,
Суга бармый, ишәк артка таба тарта,
Тартыша торгач, ишәк җиргә ятты.

Хуҗасы, алып барыр өчен суга,
Ишәкне торгызырга ора, суга;
Суйса да ишәк алга таба бармый,
Кереште аяк терәп тартышырга.

Ишәк уйлый: бу мине эчерергә,
Дигән булып уйлый суга төшерергә,
Төшереп мине суда үтерергә,
Шулай булгач, агым суга ник керергә?

Тарткан саен ишәк һаман артка чикте,
„Эчерми куймаймын“ дип, хуҗа үчекте,
Көчәнеп чын көч белән тарта торгач,
Өзелде тезген, хуҗа суга төште.

Дөньяда ишәк төсле кешеләр бар,
Карышыр, һәлак булма, тор дигәндә,
Аларны файдалы эшкә өндәсәң дә:
„Һәлак итмәк була безне“, диләр алар.

1916

КАРА ЕЛАН БЕЛӘН БАКАЛАР ПАТШАСЫ

Бервакыт кара елан бик картайды:
Арыкланды, ике күзе сукырайды.
Күз күрмәгәч, ау ауларга хәле килми,
Ачыгып беркөнне хәлдән тайды.

Ачлыкка бәрәр чара кыйлмак булып,
Бакасы күп күл буена китте шуып.
Кайгырган рәвештә тора шунда,
Булмасмы, дип ничек тә бер хәйлә корып.

Бер бака, күреп диде, иеп башын:
„И елан! Ник бу чаклы кайгырасың?“
Диде елан: „Мин кайгырмый кем кайгырсын?
Һәрвакыт бака иде минем ашым.

Ә, инде... бака ашау булды хәрам,
Болай булгач, мин ни эшлим, кайда барам?“

Бу сүзне ишеткәч тә бака китте,
Елан хәлен патшасына хәбәр итте.
Шул сәгать бакаларның патшасы
Сикерә-сикерә елан янына килеп җитте.

Патша сорый килү белән: „Нихәл, елан?“
Елан әйтте: „Инде миңа калмады сан:
„Бакаларның патшасына ат бул син“ дип
Бәддога кыйлды миңа бер зур ишан.

Догасы кабул булган икән... белдем.
Риза булып инде менә сиңа килдем.
Инде мине ни эшләтсәң дә ихтырың,
Юлыңа үз-үземне һиба кыйлдым“.

Патша елан атлануны шәрәф белде,
Хуш күреп ул еланны шунда ук менде.
Уйламаган җирдән бу эш тарыганга,
Шатланды, патша рәхәтләнде, көлде.

Инде елан ашау кирәклекне аңлата.
Патша бирә һәр көн аңа ике бака.
Шулай итеп бакаларның патшасыны
Алдаштырып, рәхәтләнеп ашап ята.

Патша да үз-үзенчә гаять эре,
Еланны кирәк чакта менеп йөри.
Кызыгып уенчыкка, халкын сатып
Алданган нәкъ бу көнге фас әмире[1].

1912

---

[1] **Фас әмире** — Марокко патшасы.

ҮГЕЗ БЕЛӘН БҮРЕ

Симез, таза, зур бер үгез ялгыз үзе
Урманга якын җирдә ашап йөри.
Ачыгып ау эзләгән ялгыз бүре
Урман буйлап барган чакта моны күрде.

„Эзләгәнем табылды“, — дип килеп җитте,
Үгез искәрмәгән чакта һөҗүм итте.
Хәлсез бүре, симез үгез арасында
Җан-фәрман белән канлы сугыш китте.

Бүре килә, үгез кыйла мөдәфәга,
Бүрене сөзә, һаман читкә кага.
Үгез, бүре һәр икесе яраланып,
Тәннәреннән шыпыр-шыпыр каннар ага.

Күп сугышып һәр икесе яралангач,
Бүре урманга кереп китте гаҗиз калгач.
„Тик йөргәндә үгез мине кыйнады“, — дип,
Аюга гарыз кылды аптырагач.

Кыйсас[1] таләп кыйла бүре теге үгездән,
Мазлумсынып яшь агызып ике күздән.
Шул сәгать аю төлкене җибәрде,
Үгез монда килеп җитсен диеп тиздән.

Буйсынып, суд җиренә килде үгез,
Моддәгый[2] белән бергә торды тигез.
Хакимлек көрсисенә менеп алып,
Ачуланган төсле аю башлады сүз:

„Бар идеме бу бүредә берәр үчең?
Шулай золым кыйлалармы бар дип көчем!

---

[1] Кыйсас — канга каршы кан белән җәза бирү.
[2] Моддәгый — дәгъвачы.

Сөзгәнсең, тәмам эштән чыгаргансың.
Зур җәзага сәбәптер бу кыйлган эшең.

Әйтәсе сүзең булса, әйт шушында,
Гадел хөкем урынныдыр безнең монда".
Аюның карашыннан үгез куркып,
Җавап бирде үз ягыннан бу да шунда:

„Йөри идем кырда ашап ялгыз үзем,
Тик торганда бүре килеп итте һөҗүм.
Мөдәфәга кыйлдым, башка гөнаһым юк.
Әй хаким, кыйл гаделлек белән хөкем".

Бүре әйтә: „Бирим эшнең асылын ачып,
Файда юк тугрылыктан читкә качып.
Бу үгезне бик дус күреп, якын барып,
Уйнамак булган идем кочаклашып.

Кан басты шунда аның ике күзен,
Сабырлыкта тота алмады үгез үзен.
„Уеннан уймак чыгар" дигән кебек,
Җенле кеше рәвешендә итте һөҗүм".

Һәрберсенең сүзен аю бетте тыңлап,
Хөкемгә керешә инде аю чынлап;
„Тик йөргән бер мазлумга тигәнсең син,
Әй залим, усаллыкның җәзасын тап!

Беләсеңме кастан һөҗүм шәригатьтә,
Йөридер үтерү белән бер рәттә.
Әлбәттә син явызга кыйсас лазым,
Калсын бу эш башкаларга гыйбрәткә!"

Булдымы, булмадымы хөкем тигез,
Үлемгә мәхкум булды мазлум үгез:
Аю, бүре бергәләшеп ашадылар,
Үгез мазлум диеп һичкем әйтмәде сүз.

Бу низагы тәмам булды менә шулай:
Хөкем булды үгезгә авыр, бүрегә уңай,
Гаепсезне гаепле итеп чыгаручы
Хакимнәрдән безне сакла, үзең ходай!

1912

ЭТ БЕЛӘН КУЯН

Гаҗәп түгел, дөнья булгач, һәр эш була,
Булган эштән гыйбрәт алу тиеш була,
Булып килгән күп гадәтнең хилафынча,
Бервакыт эт куянга бик дус була.

Җан кебек күрә болар берсен-берсе:
Куянны эт саклап кала, килсә кеше.
Эт куянның дошманына дошман булып,
Дуслары булса, дуслык күрсәтүче.

Ышанды чын күңелдән куян эткә,
Эт яныннан аерылып китми читкә,
Дус булып бераз вакыт торганнан соң,
Әллә ни эшләп этнең күңеле китте иткә.

Ит дигән саен күзгә куян төшә,
Булса да тыштан дуслык әүвәлгечә:
Йөгерешеп, күмәкләшеп уйнаганда,
Эт күңеле һаман иткә таба күчә.

Эт йөрде бераз заман шулай чыдап,
Куянга куя вәгъзан кызынкырап;
Беркөнне эт куянга һич сәбәпсез
Ачуланган төсле йөри кырын карап.

Бервакыт эт ырылдап һич сәбәпсез,
Куянга диде: „Булдың син әдәпсез,
Маза бирми уйныйсың да сикерәсең,
Ашарга хәзерләми йөреп гамьсез“.

Аңламый куян шунда: „Ни эш бу?“ ди,
Эт куянга: „Жаваплашма, тукта, чү!“ ди;
Куян тагын бер сүз әйтмәк булган иде,
Эт шунда бугазыннан барып буды.

Эт шунда ук тәмам ашап бетте итне,
Авызларын ялый-ялый кайтып китте;
(Эт этлеген кылмый калмас) дигән кебек,
Эт этлеген итү берлә эш тә бетте.

1914

КӘҖӘ БЕЛӘН ТӨЛКЕ

Һич исәпсез сусаганнар бервакыт төлке, кәҗә;
Бер эчем дә су табылмый, белмиләр нишләргә дә.

Эзли торгач, иске, ташланган коены таптылар,
Бик тирәнме, суы бармы?— дип, коега бактылар.

Бик тирән түгел, суы бар, булды бит, диләр, теләк;
Инде соң нишләргә безгә?— Су алырга юк чиләк.

Төлке (бер хәйлә беләндер) сикереп төшә дә су эчә;
Төлке артыннан кәҗә дә дөп итеп сикереп төшә.

Һәр икәүсе суга кандылар, кирәкми инде су;
Су белән эш бетми бит, мөмкин түгел моннан чыгу.

Төлке әйтте: „Әй кәҗә! Аягүрә бас син әлек;
Мин чыгарырмын сине үзем әлек сикереп менеп“.

Кәҗә сүзсез басты, төлке өстенә сикереп менә;
Кәҗә өстеннән сикерде якты дөнья өстенә.

„Инде, дус, мине чыгар“,— дип, тилмереп кәҗә көтә;
Төлке: „Әй, ахмак кәҗә!“,— ди дә кое яныннан китә.

МӘЙМҮН БЕЛӘН КҮЗЛЕКЛӘР

Кайдандыр өч-дүрт күзлек мәймүн тапты,
Бер-икесен койрыгына тезеп такты;
Күзлекләрнең берсен искәп[1], берсен ялый,
Берәвесен баш очына куеп ятты.

Файда юк искәсә дә, яласа да,
Кирәк кай җиренә куеп караса да;
Мәймүнгә күзлекләр һич файда итмәде,
Адәмнәргә бу күзлекләр яраса да.

Диде мәймүн: „Файда юктыр бу күзлектән,
Мәҗнүндер[2] пыяладан файда көткән;
Начар күзгә күзлек яхшы диләр иде,
Бигрәк тә ялганчы икән моны әйткән“.

Сикереп урыныннан мәймүн[3] торды,
Күзлекләрне барын җиргә олактырды;
Ташлау белән, ташка төшеп ватылдылар,
Шулай итеп күзлекләрнең барын кырды.

---

[1] Искәп — иснәп.
[2] Мәҗнүн — юләр.
[3] Мәймүн — маймыл.

АЛМАЗ ТАШЫ

Ялан вәхши көн иткән бер заманда,
Бер алмаз ташы яткан шул яланда,

Чын алмаз ташы кадерен белми анлар,
Бу алмазны болар һич алмаганнар.

Кадерсез ятканын алмаз да белгән,
Бу эшкә кайгырып, чиксез үкенгән.

Үкенгән берлә ни файда аңарга?
Түгел мөмкин моңа хәйлә табарга.

Менә беркөн моны бер вәхши алган:
Нигә соң бу? дигән дә суга салган.

Наданнар һич синең кадерең белә алмас,
Кара ташлар янында син — бер алмаз.

Алар сине шул алмаздай итәрләр,
Туры килсә басып, яньчеп китәрләр.

Кара таш кадәре булмастыр базарың,
Ишетмәсләр синең һич аһ-зарың.

1910

ҖАНВАРЛАРГА КИЛГӘН ҮЛӘТ

Хайваннар арасына үләт керде,
Бер ходай аларга бәла бирде.
Тиз көндә ошбу үләт күп таралып,
Хисапсыз күп хайваннарны үтерде.

Бу үләттән хайваннарның коты очты,
Торалар тәүбә кылып, бик куркышып,
Яланда, йортта, кырда, урман, тауда
Бер хайван кала алмады моннан посып.

Усаллыкны ташладылар барча хайван,
Сорыйлар тынычлыкны бер ходайдан,
Кан түгеп, золым кылып торганнары
Түкмәделәр ошбу көндә бер тамчы кан.

Көн саен руза тоталар бүреләр,
Сарыкларга тимәенчә тик йөриләр.
Төлкеләр тавыкларны бер дә бумый,
Ходайга тәүбә кылыйк инде, диләр.

Арслан тик ятмады, чыгарды чар[1]:
„Килсеннәр монда!—диде,—барча җанвар“.
Җанварлар арслан янына җыелгачтан,
Сүз башлап әйтте: „Сезгә бераз сүз бар.

Менә ничек яман эштән оялмадык,
Һичвакытта нәфесебезне тыя алмадык:
Гөнаһыбыз шомлыгыннан үләт килеп,
Кырылды арабыздан бик күп халык.

---

[1] Чар — фәрман, боерык.

Бурычлы берәр чара табарга без,
Бер хөкем чыгарамын, баш тартмагыз:
Кем дә кемнең гөнаһысы артык булса,
Шул кеше корбан булсын! Ни дисез сез?

Үткән заманда да мондый эшләр булган,
Кылганнар шул вакытта берсен корбан,
Бездә дә гөнаһысы күп булган кеше
Халык өчен ошбу юлда агызсын кан.

Җибәрде безгә ходай зур казасын,
Бер кеше корбан кылсын газиз башын,
Һәр кеше үзе кылган гөнаһларын
Икърар итсен ошбу җирдә, алдамасын.

Әйтим инде мин сезгә тугры сүзем!
Гөнаһлы бәндәләрнең берсе үзем,
Үз гомеремдә күп хайванның канын эчтем,
Уф алла, инде миңа бирсен түзем.

Укымадым гомер буе һичбер намаз,
Руза тотканым юк, мин бер явыз.
Иң юаш сарыкны да ашап йөргәч,
Башка сүзгә ничек барсын инде авыз".

Аннан соң сүз сөйләргә төлке торды,
Арсланга ярамсынып[1] сүзен борды:
„Әй хәзрәт, гөнаһыгыз гөнаһ түгел.
Сезнең бу гөнаһны кемнәр зур, ди?

Гөнаһ түгел мондый эшләр, бары һөнәр,
Сез ашаган хайваннарның бары юләр,
Гөнаһ дип ач тору мөмкин түгел,
Алай торсаң, һәрбер кеше ачтан үләр.

Сез ашаган куйларга да зур мәртәбә.
Фида булсын сезнең өчен бөтен шәһәр,
„Адәмне ашау гөнаһтыр" дигән сүздән
Бу ни дигән сүз бу?—дип һәркем көләр".

---

[1] Ярамсынып — ярарга тырышып.

Һәрбер ерткыч берәм-берәм сөйләп чыкты
Үзенең башыннан үткән усаллыкны.
Боларның эшен һичкем яман дими,
Бәлки берәр яхшылыкка хәмел кылды[1].

Болардан соң урыныннан торып үгез,
Күзеннән яшен түгеп, башлады сүз:
„Һич кешегә мин хыянәт кылмый идем,
Аздырды шайтан залим мине дә бер.

Нәкъ биш ел тулды минем шул эшемә,
Кайгырам әле дә шул эш төшсә исемә;
Ачлык елны ашарга беткәннән соң,
Бурыч сорап, ялындым мин һәр кешегә.

Бурычка һичбер печән таба алмадым,
Шуннан соң сабыр кылып тора алмадым:
Бер кешенең печәненнән рөхсәтсез
Бер уч кына печәнен мин урладым“.

Кычкырдылар шул сәгатьтә үк аю, бүре:
„Я ходай! Бу нинди гөнаһ эш эшләп йөри.
Тик торганда рөхсәтсез печән урлап,
Пычратты явыз үгез барчабызны.

Печән урлап йөри икән ходай орган.
Гөнаһысы шомлыгыннан безне кырган.
Башкалар да гыйбрәт алсын бу үгездән,
Чалыйк без бу явызны итеп корбан“.

Кабул итте һәрбере ошбу сүзне:
Чалдылар корбан кылып бу үгезне.
„Гөнаһтан җаны-тәне пакьләнсен“ дип,
Үгезне янган утка да салдылар.
Печән түгел, кешеләрне ашаганнар —
Усаллар ошбу эштән сау калдылар.

1913

---

[1] Хәмел кылды — юрады.

ХИКӘЯЛӘР

КЫР КАЗЫ

I

Безнең авылдан ике генә чакрым чамасында, җиргә төшкән ай кебек түгәрәк, көмеш тәңкә кебек ялтырап ята торган Ак күл дигән бик зур күл бар иде. Күлнең иңе 4—5 чакрым чамасында булганлыктан, аның бер ягыннан икенче ягында булган нәрсәләр күзгә чак-чак кына күренәләр иде.

Җәй көннәрендә, күлнең тирә-ягы бөтенләй дип әйтерлек яшел үләннәр һәм төрле игеннәр белән уратылып алынганлыктан, күлдән ерак түгел тау башыннан караганда, бу күл яшел хәтфә палас өстендә яткан түгәрәк көзге кебек ялтырап ята иде.

Май ае керү белән, күлнең тирә-ягында кешеләр кайнаша башлыйлар... Монда тирә-яктагы авыллардан, хозур кылып[1] ятыр өчен, әллә ничаклы халык җыйналып, шунда уйнап-көлеп көн үткәрәләр...

Кич булса, күлнең кайбер урыннарында, өелеп-өелеп үскән камышлар арасында, төрле су кошлары, төрле тавышлар белән кычкырып, чутылдашып, тирә-якны яңгыратып торалар.

Күлнең тирә-ягы җәй буенча шулай җанлы, күңелле булып торса да, көз якынлашып, салкын җилләр исә башлау белән, күл бу җанлылыгын югалта, әллә нинди моңсу бер хәлгә керә; кыр үрдәкләре һәм башка кошлар өер-өер булып җылы якка китәләр. Кояш нуры астында ялтырап, күл өстен бөҗраландырып уйный торган балыклар да, сикеренүләреннән туктап, аска төшәләр. Бу вакытта инде күл тирәсендә кешеләрне күреп булмый. Алар да монда килми башлыйлар.

Бу вакытта Ак күл буе төн ягыннан көн ягына таба — җылы якка күчеп бара торган кыр казларының

[1] Хозур кылып — күңел ачып.

туктап хәл җыеп, тамак туйдырып, хозур кылып китә торган урыннары булып әверелә. Бу вакытта, һәр көн, өер-өер кыр казлары күлгә төшеп, хәл җыеп, юынып, тагын да болыт кебек һавага күтәрелеп, кыйбла ягына очып китәләр. Аларның „кыйгак!.. кыйгак!..“ дип какылдашкан, бер-берсе белән сөйләшкән тавышлары Ак күл буена ямь һәм җан биреп тора.

II

Мин шушы аулак күл буена, һәр көн дип әйтерлек, ат эзләп яки башка берәр эш белән барам. Анда һәр көн дөньяның бер читеннән икенче читенә бара торган кыр казларының тезелешеп килеп, кунарга төшүләрен карап торам һәм, аларның матур тавышларын тыңлап, аларны читтән карап, төрле уйларга чумам.

Менә иң элек бик ерактан, җиз таска көмеш бал кашыгы белән суккан кебек кенә, „кыйгак... кыйгак...“ дип берәм-берәм генә кычкырган тавыш ишетелә. Бу вакытта күзгә кебек ялтырап торган күктә бернәрсә дә күренми. Мин, кулымны җәеп маңгаема куеп, башымны югары күтәреп, тавыш ишетелгән якка карый башлыйм. Барган саен тавышлар якынрак һәм ачыграк ишетеләләр.

„Күлгә җитәбез... күлгә җитәбез... төшәргә әзерләнегез!..“ дип, алдан башлап килгән кәрван башлыгы кычкыра торгандыр инде...

Менә бервакытта, һавада җилгә каршы тотылган ефәк тасма кебек, бер ягы озынрак, икенче ягы кыскарак, каралҗым бер нәрсә пәйда була.

Бу ефәк тасма кебек нәрсә, баштарак җилбердәп кенә күренсә дә, бара торгач ап-ачык күренә. Менә болар — бик ерактан — төньягындагы тундралардан кыйбла ягына китеп бара торган кыр казларының кәрваны...

Болар күлгә якынайган саен, тавышлары арта. Алар тәртип белән генә түбәнәя башлыйлар. Менә узып кителәр инде дигән вакытта гына, кире уратылып, күлнең бер як читенә килеп төшәләр.

Алар, күл буена килеп төшү белән, ерактан килеп талган канатларын, чуалган йоннарын борыннары белән рәтлиләр, кагыналар, су эчеп, үз араларында нәрсәдер сөйләшәләр.

Алар кичтән, мин авылга кайтып киткән вакытта, күл буенда калган булсалар да, иртәнчәк баруда алардан җилләр искән була. Алар, иртә үк торып, җылы якка карап очып киткән булалар.

— Их, шулар кебек, канатың булып, ерак җирләргә очып китсәң иде!..— дим мин. Аларның шулай дөнья күреп йөрүләренә кызыгам, шул кыр казлары кебек, гелән җәй булып торган урыннарда гына йөрисе килә, алардан аерылып калуыма эчем поша...

Бүген аларның икенче, өченче кәрваннары килә, иртәгә алар да китәләр...

III

Беркөн, иртә үк торып, кояш чыккан вакытта, атларны эзләргә чыккан идем. Юлда Гариф малае очрап:

— Сезнең атлар Ак күл буенда йөриләр,— дигәч, туп-туры Ак күл буена киттем. Үләннәр, җир өстендәге камыллар чык белән капланган иде. Чык ярып, күл буена барып җиттем. Чынлап та, безнең атлар күл буенда, эшләрен искә дә төшерми, яшел курпы[1] ашап йөриләр иде. Мин баргач, башларын да күтәреп карамадылар.

Мин күлнең матурлыгына карый башлыйм. Тын гына яткан көзге кебек күлнең өстенә яңа чыгып килгән кояшның нуры төшеп, күл аркылы алтын бөртекләре сибеп ясаган күпер кебек ялтырап торган юл салынган иде. Күлнең бер як читендәрәк балыкчылар, ишкәкләре белән суны шапырдатып, әрле-бирле йөриләр — кичтән салып куйган нәрәтәләрен карыйлар...

Мин, күл буенда өелеп үскән камышлар янына барып, тирә-якка карана башладым. Шул вакытта — „кыйгак!.. кыйгак!..“ дигән, ялгыз гына каз тавышын ишеткәч, аптырап киттем. Күл буенда да, һавада да казлар төркеме юк. Бу нинди каз тавышы?.. Бу кайда булырга кирәк?— дип, колак салып, тыңлый башладым. Тавыш бик якын, үзем янында торган камыш арасында гына.

Бу нинди эш!..

Камышларны ике якка ярып тубыкка чаклы суга кердем. Ни күзем белән күрим: камыш арасында, бер

---

[1] Печән чабып алгач, яңадан үскән үләннәргә курпы диләр. *М. Гафури искәрмәсе.*

канаты белән генә талпынып, бер кыр казы очарга азаплана, ләкин булдыра алмый, туктый... йөгерәм дисә, камышларга эләгеп кала.

Ул, мине күргәч, куркуыннан бар көчен сарыф итеп, талпына башлады. Ләкин һәммәсе бушка!.. Күп тә азапланмый, мин аны тотып алдым.

Ул, куркуыннан исән канатын кагып, минем кулымнан ычкынырга тырыша. Мине үзенә дошман дип уйлагандыр инде!

Бу каз, мотлака[1], кичә бу күл буена иптәшләре белән хәл җыярга төшеп, шул чакта аңа берәр аучының ядрәсе тигәндер дә, шуннан качып, камыш арасына кергәндер һәм, бер канаты сынганлыктан, үзенең сөекле иптәшләре белән очып китә алмый, алардан аерылып, шушы камыш арасында калгандыр, дигән уйга төштем.

Бу вакытта аның иптәшләре, туганнары, диңгез кебек матур һавада очып, кояш нуры астында, рәттән тезелешеп, каңгылдашып, җылы якка китеп бара торганнардыр. Әллә алар да моны исләренә төшерә торганнардыр... Бу мескен каз, монда күзләрен мөлдерәтеп, иптәшләренең ерак җирләргә очып китүләрен карап калгандыр...

Мин, шулай уйлап, аны бик кызганып, өйгә алып кайтмакчы булып, сынган канатын авыртмаслык итеп тоттым. Башта ул, минем кулымнан ычкынмакчы булып, талпынып карады, булдыра алмагач туктады. Тик мин аның башын сыйпарга әйтсәм генә, ул башын яшерергә тырыша иде.

Кулыма казны тотып, атларны җитәкләп, төш алдыннан гына өйгә кайтып кердем.

Озак йөрүем өчен өйдәгеләр ачулана башлаганнар иде дә, кулымдагы казны күргәч, ачуланмадылар. Әти бер дә уйлап тормый:

— Бу нәрсәне интектереп тотканчы суярга кирәк, барыбер эшкә кермәс, — дип, казны суярга кушты.

Әтинең бу сүзләренә минем йөрәгем калтырап китте. Мин суюга каршы төштем: — Горбәттә[2] адашып калган, гарип мөсафир[3] кунакны тот та суй, имеш!.. Бу ни дигән сүз? Мин аны асрыйм! — дидем.

---

[1] Мотлака — һичшиксез.

[2] Горбәттә — чит илдә, чит җирдә.

[3] Гарип мөсафир — мескен юлчы.

Минем яшьле күз белән әйткән бу сүземнән соң әти дә мескен казны кызганды һәм:

— Ярый, алай булса, асрап кара, — диде.

Мин шатлыгымнан нишләргә белмәдем. Кыр казын шунда ук йорт кошлары өчен ясалган ояга ябып куйдым. Табага су белән икмәк салып, кадерле кунагымның алдына китереп куйдым. Ләкин аның ашау кайгысы юк иде. Ул, бик кайгылы рәвештә, бер як почмакка сыгынып, тик кенә тора иде. Кичкә чаклы казым тирәсендә әйләнеп йөрсәм дә, аның ашаганын күрмәдем. Солы белән тары сибеп карадым, аларны да ашарга батырчылык итә алмады.

Кояш баер алдыннан, су буенда йөргән бер көтү йорт казлары, какылдашып, бик күп эш бетергән кебек, ашарга сорап кайтып керделәр. Аларның тавышларын ишеткәч, кыр казы дәртләнеп, „кыйгак!“ дип кычкырып җибәрде. Ахры, ул аларны үзенең иптәшләре дип белгәндер. Аның тавышын ишетү белән, безнең кызыл күзле, озын муенлы усал ата казыбыз, канатларын кагып, өзлексез кычкырып, кыр казы торган ояга таба йөгерде. Моның артыннан башка казлар да, әллә нинди зур бер вакыйга булган кебек, дөнья куптарып кычкырыша башладылар. Минем кунак казым боларның бу чаклы тәртипсез кычкырышуларыннан курыкты булса кирәк: бер почмакка сыенды.

Ата каз шул чаклы кызды, әгәр дә ихтыяр бирелгән булса, теге гарип мөсафирны талап үтерәчәгендә шик тә юк иде.

Боларның һәммәсе дә каз җенесеннән була торып та, бер-берсенә бу чаклы дошман булуларына исем китте. Ләкин, болар бара торгач дуслашырлар әле дип, күңелемне юаттым. Шунда да кызыл күзле тәкәббер ата казга бик нык ачуым килде.

— Чит кеше дип, шул чаклы ямьсез кылану, шулай әдәпсезлек итү ярый торган эшме соң инде? Үзең шул хәлгә төшсәң, нишләр идең? — дип уйладым...

Кунагым — кыр казының күңелен табар өчен, теге йорт казларын икенче якка куалап җибәрдем. Йорт казлары, ул урынга баргач та, тиз генә тынычлана алмадылар. Ата каз, муенын сузып, үзенең гайрәте белән мактанган кебек, кычкырып, канатларын кагып куйды. Башка казлар, аның батырлыгы алдында баш игән кебек булып, аңа карап, какылдашып куйдылар.

Мин дә эчемнән: „Көчсезләрне рәнҗетмәгез. Алай ярамый ул, мин аны якл армын!“ дип уйлап өйгә кереп киттем.

IV

Мин бүген төндә, гарип кунагымны уйлап, рәтле йоклый алмадым. Бигрәк тә аның монда ялгыз калуын, иптәшләреннән аерылу хәсрәтен күрүен уйлап кайгырдым.

Аның иптәшләре хәзер моннан бик еракта, тагын да шундый бер матур күл буенда, күмәкләшеп хәл җыя торганнардыр. Бу мескен монда ялгыз башы тора. Гомерендә күрмәгән урында яши... Шуның өстенә, аны төрле дошманнардан саклау мәсьүлияте[1] дә бөтенләй минем өстемдә булганга күрә, аңа килгән аз гына күңелсезлек тә минем эчемне пошырачак иде.

Бүген гадәттән иртәрәк тордым. Мин торып тышка чыкканда, йорт казлары, ашарга сорап, келәт тирәсендә кычкырып, дөньяны куптаралар иде. Мин чыгу белән, алар мине сырып алдылар. Ләкин мин, аларга әйләнеп тә карамый, үземнең кунагым янына йөгердем.

Мин барганда, ул үзенең шушы тар урында күп көннәр буенча мөсафирлыкта калачагын белгән кебек, ояга ияләшеп киткәнсымак күренә иде. Мине күргәч, башта тайчынса да, бераз торгач, өйрәнә башлаган кебек күренә башлады. Мин кичтән салган азыкларның беразын ашап, суны да бераз эчкән иде. Моны күргәч, мин бик шатландым; шунда ук табадагы суны алмаштырдым һәм янадан солы белән тары китереп салдым.

Кунагым, башта мин салган азыкларны тартынып кына ашый торган булса да, көннәр үтү белән, акрынлап өйрәнә, салган азыкны шунда ук ашарга керешә башлады. Шуның белән бергә ул үзе дә мине үзенә якын күргән кебек була, борынгы кебек, мине күрү белән, читкә тайчынмый иде. Чынлап та, аның хәсрәтен уртаклашкан, аның бөтен серенә төшенгән тик мин генә идем. Башка кешеләргә аның барлыгы белән юклыгы, исәнлеге белән сырхавы барыбер иде.

Шулай итеп, безнең көннәр күңелле уза башлады. Ул миңа яхшы ук ияләшеп китте. Мин бу эштән бик шатландым.

---

[1] Мәсьүлияте — җаваплылыгы.

Эшләр шулай ару гына барган чакта, күңелсезлек тә булып алды. Беркөн шулай үзем мәктәпкә киткән идем. Кайтып керсәм, ни күзем белән күрим! Минем мөсафирны кунак өеннән кемдер чыгарган, ата каз аны пыр туздырып куып йөри... Ул, мескен, кая керергә белми... Бу эшне күргәч, кунагымны кызгануымнан ике күзем яшь белән тулды. Кулымдагы китапларны тиз генә бер җиргә куеп, кулыма таяк алып, ата казның башына берне кундырып алганымны белми дә калдым. Шулай итеп кадерле кунагымны дошман кулыннан чак коткарып алдым. Оясына ябып, ашарга-эчәргә куйдым. Ул, мескен, шушы күңелсез вакыйгадан соң бераз вакытка чаклы боегып торды. Үзенең чит җирдә ялгыз калганын искә төшерде булса кирәк. Тик бара торгач кына тагын борынгыча тора башлады.

V

Кыш керер алдында, казның сынган канаты яхшы ук төзәлде. Сирәкләп булса да, канатын күтәреп, аркасына сала башлады. Күрәсең, канат сөяге бөтенләй эштән чыкмагандыр... Бөтенләй сынган булса, бу рәвешле төзәлә алмас иде.

Казның бу рәвешле сәламәтләнгәнен күргәч, бик вә бик шатландым. Бервакыт очып йөрерлек бер хәлгә килер әле дип уйлый башладым.

Кунагым һәрвакыт тар урында торып күңелсезләнә торгандыр дип, көндезләрен үз карамагым астында гына агач бакчасына алып кереп йөретә идем. Ул бакчага керсә, иркен тын алган кебек була, рәхәтләнеп китә, һавага карап, очарга әйткән кебек дәртләнеп куя. Күрәсең, ул әле һаман үзенең иркен һавада иптәшләре белән очып йөргәнен онытмый, аларны исеннән чыгара алмый торгандыр...

Безнең бу эшебез кар яуганчы шулай барды. Кар яугач, мал өендә кунагым өчен аерым, үзе генә торырлык урын ясадым. Иртән сабакка киткәнче, төштән соң сабактан кайткач, аның алдына солы, тары кебек азыклар салып, су биреп, кунак итә торган идем. Мин аны шулай кыш буенча тәрбия кылдым, кунак иттем.

Аның канаты бөтенләй төзәлде. Ул кайвакытта, ишек алдында казларның кычкырганын ишетсә, башын ныклап күтәрә, дәртләнеп китеп үзе дә кыйгаклап җибәрә һәм канатларын күтәреп кагынып куя иде. Шун-

нан мин аның һаман да үзенең туганнарын, иптәшләрен сагынганлыгын сизә идем...

Озын, күңелсез кыш үтте. Карлар эреп, сулар ага башлады. Җир йөзе кояш нурына манчылды. Җылы якка киткән кошлар безнең илгә килә башладылар. Менә беркөн, мин, иртән торуга:

— Сыерчык килгән дә! — дигән сүзне ишеттем. Шунда ук урынымнан торып, тәрәзәгә карадым.

Чынлап та, иртәнге кояшка каршы, өй янындагы сыерчык оясы өстендәге чыбыкка бер пар сыерчык кунган. Алар канатларын кагып, талпына-талпына сайрыйлар иде. Безне бик сагынып килгәннәр алар. Дәртләре, шатлыклары эчләренә сыймый, шулай күңелләнеп сайрыйлар.

Көннәр барган саен матурланды. Кырларда карлар бетеп, кара җир өсте яшәрә башлады. Сулар ярларына сыймый агалар. Көз көне җылы якка киткән кошлар, безнең авыл өстеннән үтеп, төн ягына үтәләр. Хәзер минем кунагым булган кыр казы бигрәк дәртләнә башлады. Ул үзе монда йөрсә дә, күңеле әллә кайларда кебек булып кычкыра, шулай итеп үзенең иптәшләрен көткән кебек була иде.

Менә беркөнне иртәнчәк бик югарыда, еракта:

— „Кыйгак... кыйгак!...“ — дигән, кыр казларының тавышлары ишетелә башлады.

Мин, кулымны маңгаема куеп, аяз күккә карадым. Чынлап та, төшлек ягыннан, бик югарыдан, ефәк тасма кебек җилфердәп, кыр казлары төн ягына таба үтеп баралар иде.

Шуларның „кыйгак... кыйгак!..“ дигән тавышларын ишетү белән, минем кунагым булган кыр казы үзе дә:

— „Кыйгак... кыйгак!..“ дип кычкырып җибәрде һәм, дәртләнеп китеп, канатларын кага һәм бик җитезлек белән әрле-бирле йөрергә керешге. Бу вакытка чаклы аның һичбер болай ук дәртләнгәне юк иде. Мин аның бу чаклы дәртләнүенә һәм шатлануына аптырап карап тордым.

Шул вакытта аның дәртләнүе тагын да артты. Теге, һавадагы кыр казлары безнең авыл турысыннан үтеп барганда, ул, артык уйлап та тормый, йөгереп, алга табан бераз барды да югары күтәрелеп оча да башлады һәм, теге кыр казларына таба карап, очып та китте. Мин гаҗәпләнеп карап тордым да калдым.

Ул, күздән югалганчы, бик моңлы иттереп, „кыйгак... кыйгак!..“ дип кычкырды. Аның бу кычкыруы миңа иң соңгы сәлам һәм минем белән исәнләшүе иде. Мин аның тарлыкта, кеше кулы астында яши алмавына, киң дөньяны артык күрүенә хәйран калдым. Ул, шулай итеп, үткән ел аерылып калган иптәшләренә барып кушылды.

Мин бу гарип кунагымны, көз булган саен, искә төшерәм, аны сагынам. Ул миннән мәңге аерылса да, мин аны оныта алмыйм.

Бәлки ул да мине шулай искә төшереп куя торгандыр...

ЯҢА УРАК

I

Үткән ел тары утавында мин зур кешеләр белән беррәттән утадым. Хәтта әни: „Яшь кешенең биле авыртмый шул, менә безнең бил тиз авырта“, — ди торган иде.

Печән җыйган чакта да аларга булышлык иттем. Тик алар кебек, печән күтәрәмен алар җиткергән җиргә алып барып җитә алмый идем. Андый чакта абзый яки әни ярдәмләшеп ташлый иде.

Урак өстендә алар белән бергә урак урырга теләсәм дә, турыдан-туры уракчы булып китә алмадым. Чөнки бер яктан зур уракчыларга чәй кайнатам. Шуның өстенә кечкенә сеңелемне карыйм. Тик шушы ике төрле эштән бушаган чакларда гына, әниләр янына барып, аларның буш торган уракларын алып, берничә көлтә урып ташлыйм. Минем әле учмаларым зур булмый. Саламнарны тигез тотып, чуалтмый гына ура алмыйм. Шулай да әкренләп өйрәнеп барам. Әти белән әни миңа карап:

— Кара син аны!.. Хәзер өйрәнеп бара, киләсе елга үзенә урак алып бирербез. Шулай итеп безнең тагын бер эш кулы артыр, — диләр иде.

Аларның шул сүзләреннән соң минем күңелем үсеп китә. Мин тагын да шәбрәк-тазарак урырга, артта башаклар калдырмаска тырышам. Шулай да әле минем баш бармаклар тиз тала. Учмаларны тигез алып барып булмый. Мин алда зур эшче булуны уйлап артык шәп киттем, ахры.

— Кара, балам, кулыңны кисеп куйма, — диделәр.

Аларның сүзләре дөрес булып чыкты. Мин чәнчә бармагымның әчетеп, бертөрле авыртуның йөрәккә барып бәрелгәнен сизеп, кулымдагы учманы җиргә ташладым. Чынлап та, чәнчә бармагымның бер ягы киселгән, тырнакның да бер як читен кыеп алган иде.

— Әйттем мин, балам, сиңа, кисәрсең дип! — диде әни. Һәм шунда ук җирдән кара балчык алып канаган урынга сипте. Яулыгының бер читен ертып алып, чәнчә бармакны урап, бәйләп куйды.

— Урак урырга өйрәнгәндә бармак кисүләр була инде ул, — диделәр. Шуннан артык сүз әйтүче дә булмады.

— Урак урганда кул кисүләр була инде ул...

II

Быел мин эшкә үткән елга караганда да ныклап катыштым. Сабан сөргәндә, утау утаганда, печән җыйганда зур кешеләр рәтеннән тырыштым. Кайчакта арыган кебек булсам да, сер белдертми, эшләүне генә белә идем. Минем арыганымны сизгән кешеләр:

— Яшь кеше арып торамыни! — диләр. Аларның шул сүзләреннән соң мин тагын да хәлләнеп, җанланып китәм.

Урак вакыты җитеп килә. Быел игеннәр бик шәп: арыш басуы арасыннан киткән юлдан барганда, җигүле атның дугасы чак-чак күренеп кала. Тарыларның кыяклары камыш кебек киң, кара кучкыл булып торалар. Солы, бодай, арпа кебек каты ашлыклар, әле яңа баш чыгарып килсәләр дә, кеше биленә җитәләр.

Кибән куеп кайтканда, әти, игеннәргә карап:

— Игеннәрнең бу елгы кебек шәп булганы бик сирәк. Теге ачлык елдан соң, Вәли туган елны, иген бик уңган иде. Быел аннан да шәп. Боз сугып-фәлән итеп китмәсә, ашлыкларны кая куярга белмәсләр. Үзебезнең арышны урып бетергәч, тары өлгергәнче, кешеләргә урак урып, өс-башны бөтәйтеп алырбыз... Самовар да карарбыз... — дип сүз башлый. Аның бу сүзләрен әни йөпләп алып китә:

— Өс-башы тагын бер хәл. Кечкенәрәк булса да сыер алып кала алсак яхшы булыр, балалар сөткә туярлар, үзебез иркенләп калыр идек, — ди.

Әти аның бер сүзен дә читкә какмый:

— Исән булсак, карарбыз әле. Тик менә игеннәр генә исән-сау кулга керсеннәр, — ди.

Мин эчемнән шатланам,— „миңа берәр бишмәт алсалар, нинди күңелле булыр иде...“ дип, кызыл кергезин бишмәтемне күз алдыма китерәм.

Әти минем уемны белгән кебек:

— Менә быел Вәли дә урыр инде, бер кул артыр, үзенә бик матур яңа бишмәт тектерербез,— ди.

Апа үзенә шәл өмет итә.

Шулай итеп, без авылга кайтып җиткәнне белми дә калабыз.

Мин басу капкасын ачарга төшкәндә дә, өйгә кайткач, ат тугарганда да, ат тышарга барганда да: „Кайчан урак җитәр, кайчан безнең дә кешеләрнеке кебек сыерыбыз булыр, миңа кайчан кергезин бишмәт тектерерләр...“ дип уйлап йөримен.

Кайвакытта, төш җитәр алдында, күк йөзендә болытлар чыга башлыйлар. Бу аерым болыт кисәкләре бик тиз арада күбәеп, зураеп, бер-берсенә кушылалар, кояшны каплап алалар. Озак та үтми, әллә кайда, еракта, гөлдер-р-р-р! иттереп, күк күкрәгән тавыш ишетелеп китә. Төшлек ягында, бик озын утлы чыбыркы болгап алган кебек булып, яшен күренеп кала. Аз-маз гына җил чыга, агач яфраклары шаулап китәләр.

Менә шундый чакта әти дә, әни дә куркуга төшәләр.

— Ай-һай, бик шәп яңгыр чыкты! Төш мизгелендәге болытлар бозлы була торганнар иде; боз явып, игеннәрне һәлак итеп кенә китмәсә ярар иде! — дип кайгырыша башлыйлар.

Чынлап та, әллә кайсы бер елны, шулай игеннәр пеште, инде урабыз дип торган вакытта гына, каты боз явып, арыш басуын бөтенләй кара җир ясап киткән икән.

— Бу ел да шулай булмаса гына ярар иде!..— диләр.

Болытлар, катлы-катлы булып, бөтен күк йөзен басып, килеп җитәләр. Эре яңгыр бөртекләре сабап яварга керешәләр. Бер сәгать эчендә чокыр-чакырлар су белән тулалар. Яңгыр бозсыз була. Зур болытлар зыян-зарар итми үтеп китәләр. Куркыныч минутлар үтә, кояш, ялтырап чыгып, бөтен җирне нур белән каплый. Кешеләрнең шатлыклары эчләренә сыймый:

— Игеннәргә файдасы гына булсын инде!..

— Басуда боз яумадымы икән?..

— Юк, анда яуса, монда да төшкәләр иде,— диләр.

Яңгырдан соң әти басу карарга барып кайтты. Ул бер учма арыш та алып кайткан иде. Арыш үзе буйга озын, үзе бик башлы. Әти бик шат:

— Анда бозның әсәре дә юк, яңгыр бик шәп яуган. Арышлар пешәргә житешкәннәр, алдагы базар артыннан уракка төшәрбез инде, насыйп булса, — ди.

III

Әти, базарга чаклы ук, иске уракларны тешәтеп куйган иде. Базар көнне тагын бер яңа урак алып кайтты. Мин, бу яшел саплы матур уракны күрү белән:

— Бу урак миңа булсын, — дидем.

Апам яңа уракны үзенә алмакчы булган иде дә, бара торгач, ул да миңа бирергә риза булды.

— Минем үткән елгы, өйрәнгән урагым бар, сиңа булсын инде, — диде. Шуннан соң мин шатланып, яңа урагымны кайта-кайта карап, башка ураклар янына куйдым. Монда торганда да минем яңа урагым әллә кайдан ялтырап, аерым матур булып күренә. Мин инде, иртәгә басуга барып, уракка төшүне генә көтә идем.

Көткән көн житте. Без бүген бик иртә торып, хәзерләнеп басуга киттек. Башка кешеләр дә уракка төшкәләгәннәр икән: анда-монда югары күтәрелгән учмалар күренеп кала. Кайбер жирләрнең башында көлтәләр утыртып та куйганнар.

Без дә үзебезнең жир башына барып життек. Әти белән без атны тугарып, арканлап куйганчы, апам, жирнең башына барып, урырга керешеп тә китте.

— Безнең Сәлимә бик жиңел куллы, ул башласын, — ди әни, үзе беләгенә беләксә кия.

Уракларны тотып, без дә апа янына бардык. Әти, жир өстенә карап:

— Ай-һай, бик яхшы үскән!.. Баш калдырмый гына урыгыз. Кара син, Вәли, ашыгып кулынны кисеп куйма, чуалтмый, яхшы урып өйрән, — диде дә, уң кулына урагын тотып, бер уч чамасы арыш кисеп алып, көлтә бавы ясап, жиргә салып куйды да, урып алып китте. Аның учмасы алга таба тәгәрәтеп кенә бара. Аның яныннан әни ура башлады. Мин апа белән әни уртасыннан юл алдым.

— Көлтә бавыңны нәзек ясама, өзелерлек булмасын, — диделәр миңа. Мин, алай-болай көлтә бавы ясап, бер-ике учма да салып өлгертмәдем, апа өченче көлтәсен бәйләп, жиргә дың иттереп утыртып та куйды. Әти дә икенче бау ясады. Әни дә көлтәсен бәйләп ташлады.

— Көлтәсе нинди авыр, башы бик шәп шул, арбасыннан ун-унике пот чыгар,—ди эти.

Безнең янәшәгә Хәким бабайлар килеп уракка төштеләр. Җир өсте тагын да җанланып китте.

Хәким бабай миңа карап:

— Вәли дә ура башлаган икән, бик яхшы, шулай кирәк,— ди.

Мин беренче көлтәне тутырып бәйләдем. Әти, көлтәне карап: „Ныграк бәйлә, көлтәләрне зуррак яса“,— диде. Чынлап та, минем беренче көлтәм бик зурдан түгел иде.

Җир өсте көлтәләр белән чуарлана башлады. Мин дә әкренләп урагымның рәтенә төшендем. Башта ул җайсызраксымак иде, хәзер бик җиңел йөри башлады.

Бүген мин төшкә чаклы егермеләп кенә көлтә урдым. Шулай да әниләр карап торып:

— Кара син аны, бик яхшы ура бит, бара торгач, өйрәнер әле,— диделәр.

Чынлап та, мин ике-өч көн эчендә урак урырга ару гына өйрәндем. Көлтәләрем зур да, ныклы да була башлады һәм артта башаклар да калдырмаска тырыштым. Шулай итеп, мин, яңа урагым белән, башкалар артыннан калышмый урырга өйрәнеп киттем.

IV

Үзебезнең арышны урып беткәч тә, эти байларга урак урырга булып, шуларның җиренә киттек. Әти бу ел эш хакы яхшы дип шатлана һәм ике сүзнең берсендә:

— Эш вакытында күбрәк эшләп калырга кирәк, соңыннан рәхәт торырбыз,— ди.

Хәзер без, караңгы таңнан башлап, кичке караңгыга чаклы урабыз. Икенче көнне без ялланып урган бай безнең урган җирләрне карарга килде. Тарантаска җигелгән атын җир башына тугарып куйды.

Ул, җир өстенә керү белән, камыллар арасыннан башаклар алып, шуларны тотып, безнең якка килә башлады. Әти аның каршысына чыгып сәлам бирде. Ләкин бай абзый әтинең сәламен алыр-алмас:

— Галиәхмәт, каранкырап, яхшырак урырга кирәк иде. Башаклар бик күп калган бит,— дип, кулындагы арыш башларын күрсәтте.

Әти алай-болай итеп:

— Яхшы урырга тырышабыз инде, Сәлим агай, алай гына калыр инде,—ди. Бай үз сүзендә торып:

— Калмаска кирәк ул, эшләгәч, яхшы эшләргә тиеш! — дип, көлтәләрне карый башлады.

Бәхетсезлеккә каршы, ул, нәкъ мин бәйләгән көлтәләрне кулына алып:

— Менә көлтәләр дә бик начар бәйләнгәннәр, алай ярамый ул, энем!— дип, безнең эштән чи таба башлады һәм миңа карап:

— Бу бәләкәй малай ничек урсын!.. Бала-чагадан урдыртып, игенне әрәм-шәрәм итмәскә кирәк!— ди.

Аның бу сүзе туп-туры миңа килеп бәрелде. Мин шунда каушап, кызарып киттем.

„Имеш, мин начар урам имеш!.. Имеш, мин эш эшләми, тик торыйм икән!“— Сәлим байның бу сүзләренә каршы әти башта матурлап җавап бирде. Ләкин ул күп тылкый башлагач, әти дә бик бирешеп тормады:

— Инде, Сәлим абзый, бездән дә хәйләсез эшләгән кеше булмас. Алай бик күп тылкыйсың икән, хәзер без синнән башка җирдән дә урак табарбыз, дөньяда бер син генә түгел! — дип үзе бәйләнә башлады.

Шуннан соң гына Сәлим бай үзе йомшап китте:

— Галиәхмәт, алай кызма әле. Мин башаклар калмасын дип кенә әйтәм, әйдә ура бирегез. Яхшырак булсын дим,— ди.

Шул сүзләрдән соң ул әти белән башка хакта бераз сөйләшеп, исәнләшеп китте. Без тагын урырга тотындык.

Әти аны җиңеп калуына шатланып китте.

— Алай бик күп сөйләсәң, мин дә нишләргә белермен. Малаең бик тиз йомшады!— ди. Аның бу сүзләренә әни дә кушылды:

— Хәзер эш муеннан... Тик эшләп кенә өлгер... Өченче көн генә Әхмәт бай хатыны: сез бик яхшы урасыз, бу ел да безгә бераз урыгыз әле, дип, үземә әйтте,— ди. Әти, аның сүзенә өстәп:

— Шулай булмый ни!.. Кичә Николай: әйдә безгә барыгыз, дисәтинәсенә сигез тәңкә бирәм, өстәвенә бер пот он, чирек чәй, бер кадак шикәр арттырам, дип торды,— ди.

Мин эшнең иркен икәнен, болай булса, бу ел бик күп акча табып, сыер да, яңа күлмәкләр дә, миңа бишмәт тә алырбыз дип уйладым.

Әни тагын да сүз башлап:

— Бу ел да эшләп калмагач ярыймы соң... Бу ел безнең кебек ярлы-ябагайларның аз булса да аякка басып тора торган еллары,— диде. Бу сүздән соң без һәммәбез дә, уракларыбызны тагын да ныграк тотып, дәрт белән ура башладык.

Хәзер минем яңа урагым тагын да үткерләнеп киткән кебек булды. Учмаларны зур алып, көлтәләрне ныклап бәйләргә өйрәнеп киттем.

Эчемнән: бәләкәй булса да, бер сыер алуны, барыбызга да яңа күлмәкләр тектерүне, миңа кызыл кергезин бишмәт сырдыруны уйлый идем.

— Ах, яңа бишмәт киеп мәктәпкә йөрсәм!— дим...

Әти белән әни һәм апа бигрәк дәртләнеп уралар. Җир өстендә өзлексез „ыжжит-ыжжит“ дигән тавыш чыгып тора.

Күрәсең, алар да шулай яңа күлмәкләр, сыер һәм бишмәт алуны уйлый торганнардыр.

ЯЛЧЫ

Ул вакытта мин кечкенә бала идем. Без ул чакта каланың уртасында, Кәбиров дигән байларның ат сарайлары белән янәшә салынган кечкенә генә бер өйләрендә тора идек. Бу кечкенә өйнең ике ягы таш сарай булып, арт ягы бик биек таш коймага терәлеп салынганга күрә, якты керү өчен, ишек алдына караган ике генә тәрәзәсе бар иде. Өйнең эчендә җәелдереп салынган бер мич, эре такталардан ясалган озын сәке һәм ишек янында яз көне бозаулар яба торган челтәрле читлексымак бер нәрсәдән башка рәтле әйбер юк иде.

Бу вакытта минем әти шушы байларда ат карап, кучер булып, ишек алларын себереп хезмәт итә, байларның вак-төяк йомышларына йөри; әни шул байларның ашларын пешерә, керләрен юа, сыерларын сава, башка шундый кара эшләрен эшли иде. Аларның икәвесе дә таңнан алып кара төнгә чаклы шул эшләреннән бушый алмаганга күрә, мин өйдә кечкенә сеңелемне карап, ялгыз утыра идем. Без иртәнге йокыдан торганда, алар әллә кайчан байлар эшенә чыгып киткән булалар. Тик төш вакытында гына чәй эчәргә бер кереп чыгалар иде. Анда да күп вакытта байларның берәрсе, тәрәзә кагып: „Чыгыгыз әле, эш бар!“ — дип чакыра да, алар, ясаган чәйләрен дә эчеп бетерә алмыйча, йөгереп чыгып китә торганнар иде. Кич булса, алар без йокыга киткәч кенә кайталар иде. Мин аларның өйгә кереп чишенеп ятуларын йокы аралаш кына сизә торган идем. Кайвакытта әти йокларга яткач, байның асравы кереп: „Әхмүш абзый! Тиз генә торып ат җик, абзый кунакларны илтеп ташларга куша, кара атны җиксен, ди“,— дип, йомыш кушып, уятып чыгып китә иде. Әти мондый вакытта карганып:

— Алар анда төн буе ашап-эчеп утырсыннар, син монда төн йокысы йокламый утыр да, ат җигеп озата

бар!— дип, авырсынып кына, камытларын күтәреп, чыгып китә иде.

Кайвакытта әти бик күңелсез була торган иде. Мин аның ни өчен бу чаклы күңелсез булуын аңлый алмый идем. Тик мондый вакытта алар байларны сөйлиләр: „Байларга нишләсәң дә ярап булмас инде!"— дип зарлаканалар иде.

Әни беркөнне кич белән өйгә керде дә пыш-пыш елый башлады. Аның елаган тавышын ишеткәч, минем йокыларым ачылып китте. Аның елаганын бик озак тыңлап яттым. Ул бик озак елады да: „Сине сөттән ак, судан пакь көе пычраталар, бу каһәр суккырларга хезмәт итеп йөргәнче, үлгәнең артык",— дип сөйләнә башлады. Нәкъ шул вакытта әти кайтып керде. Ул да, ни өчендер, күңелсез иде. Мин эчемнән: „Ни дә булса, берәр эш булгандыр,"—дип уйладым. Әти кергәч, бераз вакыт сөйләшми утырды да, соңра юаш кына уфлап:

— Кем алды икән соң аны?.. Күпме диләр, ун сум диләрме?— дип сорады. Әни, бик борчылып, үкси-үкси: „Кем алсын?.. Үзләренең ут күз Габдуллалары күз алдымда алып чыгып китте; үз күзем белән күрдем: ун сумлык кәгазь акча иде. Мин шуны әйткәч, теге мичкәсе: „Алмас, алмас! Үзең урлыйсың да, безнең шул балага ябасың, урлап ашамаса, аның ашарына юкмыни?" дип, теңкәмә тиде",— дип тагы елый башлады. Әнинең шул сүзеннән соң, әти кыза төште: „Ходайның ризыгы бер монда гына түгелдер, чыгарга кирәк; алдан алган акчаны түләп бетерсәм, бер көн дә тормас идем, һәм тормам да, шуңарчы сабыр итәргә кирәк инде", — дип, әнине юата башлады. Алар бу хакта бик озак сөйләштеләр. Мин, аларның сүзләрен тыңлап ята торгач, йоклап киткәнмен.

Икенче көнне мин тәрәзәдән карап утыра идем. Әти ишек алларын себереп йөри иде. Бай абзый ат белән әллә кайдан кайтып төште дә, әти янына килеп, нәрсәгәдер ачулана башлады. Ләкин аңа каршы әти бер сүз дә әйтми иде. Бай абзый әтине сукте-сукте дә иң соңыннан: „Болай начар йөрсәң, юлың әнә тора, чык та кит, күземә күренмә: хезмәт итәсең икән, яхшы хезмәт ит!.."—дип, капканы күрсәтте дә җиргә төкереп китә башлады. Әти аның артыннан гына: „Ходайның ризыгы бер синдә генә түгелдер әле..."—дип, бер-ике сүз әйтергә теләгән иде, бай абзый артына әйләнеп:

„Хәерче башың белән җаваплашып торасың, шайтан нәрсә!“ — дип җикерде дә, башка бер сүз дә әйтми, кереп китте. Ул кереп киткәч, әти, себерке сабына күкрәген терәп, бик озак тик торды. Әтинең шул хәлен күргәч, минем ике күземнән яшьләрем тәгәрәп төште.

Бай юлда китеп барганда, дилбегәсе өзелеп, аты икенче якка борылып, арбасы ава язган да, өйгә кайткач, ат җиккәндә, шуны карап җикмәдең дип ачуланган икән...

Бу эштән соң әти өйгә кереп, тагын да зарланып утырды. Бәхетсезлеккә каршы, әни шул көнне, кулыннан төшереп, бер тәлинкә ваткан икән. Байның хатыны шуның өчен ачуланган. Ул да өйгә кереп зарланды.

Шулай итеп, безнең өйдә һәркөн бер эш хакында байлардан зарлану булып тора иде. Кайвакытта шулар хакында зарланышып утыра торгач, нишләптер үз араларында ызгыш чыгып китә торган иде. Мондый вакытта әти усалланып китә, ләкин әни бераз каршы сөйләп караса да, булдыра алмагач, әрнеп елый башлый иде.

Ашау ягы күп булмаса да, арыш икмәгенә ач тормый идек. Кайвакытта әни байлардан калган ит һәм бәлеш кисәкләрен алып кереп, безгә ашата иде. Шул гадәте буенча, беркөнне әни, төштән соң, бер таба бәлеш кисәкләре алып кереп, чәй янына куйды. Чәй янына әти дә кергән иде. Без бик шәпләп чәй эчәргә утырдык. Бәлеш кисәкләре бик тәмле булып, майлары агып тора иде. Без ашарга утыргач кына, байның хатыны — Фатиха абыстай бик ачуланып керде дә, туптуры безнең сәке янына килеп, ашъяулык өстендәге таба белән бәлешне күтәреп алып чыга башлады. Чыккан вакытта: „Убырлар! Бер әйбер калыр хәл юк, ач кернә балаларына кертә дә тыгындыра, кертә дә тыгындыра, синең гөпкорсак балаларың туймас!..“ дип сөйләнеп чыгып китте. Без караштык та калдык. Ул бәлешне, алып чыгу белән, ишек алдындагы этләргә түкте дә, табасын алып кереп китте. Бу хәлне күргәч, әти дә, әни дә, бер сүз әйтми, бер-берсенә карашып тордылар. Байтак торгач, әти:

— Сорамый алып чыккан идеңмени?.. Алай итү кирәкмәс иде. Аның холкын беләсең бит: берәр нәрсәгә ачуы килсә, бездән үчен ала, — диде. Әни кыза-

рып китте. Ике күзеннән яшьләре тәгәрәп төште. Калтыравыклы тавыш белән:

— Әй, илаһем! Бәндәңне бәндә иттең. Көн-төн эт кебек булып эшләп йөрисең. Ул синең күз нуры кебек газиз балаларыңнан калдык бәлеш кисәкләрен кызганып, алдыңнан тартып алып, чыгарып этләргә түгә,— диде. Әти артык ачуланмый:

— Аның шул гадәтен белгәч, сорамый алмаска кирәк иде. Беләсең бит: ул калган ашларын этләргә чыгарып түксә дә, кешедән кызгана. Ул этләрен бездән артык күрә,— диде.

Әни тагы да кыза төште:

— Юк инде, юк! Адәм баласын эт чаклы да күрми торган кешеләр булыр икән!.. Ул бәлешләр әрәм булып бозылганга күрә генә алып чыккан идем. Барыбер алар соңыннан этләргә ташлана бит! Әллә алар шул бәлеш катыларын ашыйлар дип беләсеңме?.. Ул бу арада нәрсәдән ачу алырга белми йөри; иренең ачуын бездән ала,— диде. Шуннан соң бай абзый хакында әллә нәрсәләр сөйләделәр. Мин аларын аңламадым.

Мин шул ишек алдында үзем белгәннән бирле торсам да, аларның өйләренә кергәнем юк иде. Тик ашханәгә, әни аш пешереп торган җиргә кереп чыга идем. Ләкин әни берәр турам ит бирә дә, мине тиз генә чыгарып җибәрә һәм „монда кергәнеңне абыстаң күрмәсен“ ди торган иде. Беркөнне мин тагы да әни янына кердем. Мин кергәндә, әни әллә кая киткән икән. Тик аларның минем белән бер яшьтәш Габдуллалары баш зурлыгында бер туп тотып, шунда тора иде. Мин аның зур тубын күргәч, бик кызыктым да, чыгып китмичә карап тордым. Шул вакыт Габдулла: „Минем бик матур атым бар, әйдә әле сиңа күрсәтим“,— дип, мине икенче бүлмәгә чакырды. Мин: „Юк, кермим, әни ачулана“,— дидем. Ләкин ул минем сүзгә карамый, әйдә дә әйдә дигәч, кызыктым да, аның артыннан кердем, кергәч тә ишек төбенә туктадым. Ул мине тагын алга чакырды. Мин куркып торсам да, ул бик көчләгәч, аның белән тагы бер бүлмәгә барып кердек. Анда нәкъ тере кебек, ләкин кечкенә гәүдәле кара ат колакларын торгызып, авызын ачынкырап, ишеккә таба карап тора иде. Аны күргәч, минем исем китте. Җанлыдыр бу дип уйладым. Житмәсә

тагы, өстендә ияре дә бар иде. Габдулла, аның янына бару белән, бер дә курыкмый өстенә менде дә, атны юрттырган кебек, селкенә башлады. Мин аны, хәйран калып, карап тордым. Габдулла тиз генә атыннан төште дә, кызып китеп, башка уенчыкларын да күрсәтергә кереште. Ләкин шул вакытта бүлмәнең ишеге ачылып китте. Кергән кеше — Фатиха абыстай иде. Ул мине күрү белән агарынды. Мин куркуымнан нишләргә белми ишеккә таба китә башладым.

— Бу ни эш! Син монда нигә кердең? Тиз чык, бетең коеп йөрмә... Бара торгач, башка менеп таптый башладылар инде! — диде дә кулымнан тотып, ишектән чыгарып җибәрде. Мин ашханәдән чыгып киткәндә, ул һаман әллә ниләр сөйләнә иде. Мин Габдулланың атына кызыгып, өйдәге башка нәрсәләрне рәтләп карый да алмадым. Ләкин өй эче бигрәк матур күренде. Матур булса да, анда тору, ни өчендер, бик кыен төсле булды. Бүлмәләр салкын кебек иде. Зур көзге мине йотар кебек булып акаеп тора, зур гөлләр авып китәр кебек күренәләр. Ишекнең ике ягыннан салынып төшкән яшел чаршауларның аръягында әллә нәрсә, куркыныч әйберләр бардырсымак күренде. Мин, үзебезнең өйгә кайтып кергәч, иркенләп киттем. Өстемнән бик авыр йөк төшкән кебек булды. Тик үземнең кечкенә генә булса да атым булмавы өчен эчем пошты. Байларның өйләренә керү моның белән генә бетсә, бик шәп буласы иде. Ләкин эш болай гына бетмәде.

Озак та үтми, әни килеп керде дә: „Ник аларның өйләренә сорамый кердең? Анда сиңа нәрсә бар иде?!“ дип ачулана башлады. Әни дә шул сүзне әйткәч, мин чынлап та үземдә гаеп дип уйладым. Бу эштән соң, мин ишек алдына чыгарга да курка башладым. Чөнки мин чыгу белән, берәрсе күрер дә, теге өйгә керүем өчен ачуланыр дип уйлый идем.

Шулай өйдә бик күп чыдап утырдым. Ләкин бара торгач, чыдый алмый башладым. Җәйнең матур көне мине тышка чыгарга чакырып торган кебек булып, күзләремне камаштырып тора иде. Беркөнне сеңелем йоклады. Ул йоклагач, мин йөгереп чыктым, бакча янына бардым. Бакчаның койма буенда үскән агачлары чәчкә атканнар, аларның матур зәңгәр чәчкәләре рәшәткәдән салынып, чук-чук булып, күзне кызык-

тырып торалар иде. Мин шуларга кызыгып, карап торган вакытта, Габдулла чыкты да, минем яныма килеп, мине мыскыл итеп күләргә кереште. Аның янында үзенең ике эте дә бар иде. Ул мине төртеп җиргә екты. Шуннан соң этләрен өсләтеп, минем өскә җибәрде. Алар минем чабуымнан тартып йөртә башладылар. Берсе бүрегемне тешләп алып китте. Габдулла үзе, көлеп, этләрен котыртып, читтән карап тора иде. Мин куркуымнан елый башладым. Минем тавышны әти ишетеп йөгереп килде дә этләрне куып җибәрде. Шунда Габдулла, мине елаудан туктатыр өчен, теге чәчкәләрдән бераз өзеп миңа бирде дә, үзе каядыр китте. Мин бакча янында чәчкәләрне тотып калдым. Шул вакытта бай абзый кайтып керде. Минем кулымдагы чәчкәләрне күреп: „Ник монда чәчкәләр өзеп йөрисең, мошенник малай!" — дип, колагымны борып, куып җибәрде. Шунда йөргән әтигә карап: „Син моннан соң бу кечкенә карагыңны ишек алдына чыгарып йөртәсе булма, ботын сугып сындырырмын!" — дип кычкырды. Аңа каршы әти бер-ике сүз әйтмәкче булган иде, бай тагы да ачулана төшеп:

— Беркөн булды беркөн шул малай өйгә кереп йөргән. Бүген чәчкәләрне өзә. Син әле шул карагыңны яклашасың. Болай булса, түзәр хәл калмады инде!.. — дип тезеп алып китте. Мин өйгә кереп киткәндә, ул һаман нәрсәдер сөйләнә иде.

Бай чыгып киткәч, әти, артымнан кереп: „Син, малай, һәрвакыт шундый эшкә сәбәпче буласың!" — дип, чикәмә сугып җибәрде. Әни дә өйгә кергәч: „Китәргә, моннан чыгарга кирәк",—дип, әйберләрне җыя башладылар. Шунда бай әтине чакырып чыгарды. Ул әллә кайда йөреп кайтты да, тагы да чыкмаска булды. Шушы кычкырыштан соң мине бакча янына чыгармадылар. Бик кызыгып китсәм инде, үзебезнең тәрәзә төбенә генә чыгып утыра торган идем.

Шушы байның өендә без тагын күпме торганбыздыр, анысын ачык белмим. Тик бервакыт әти авырый башлап, саргаеп түшәккә егылгач, байлар әтигә күчеп китәргә кушканнар. Шул вакытта күчеп китүебезне бер дә онытмыйм. Байлар чыгарга кушканнан соң, әни һәркөн иртән торгач та чыгып китә, көн буе фатир эзләп йөреп кайта иде. Күп йөри торгач, беркөн каланың читеннән фатир табып кайтты. Ул үзе яныл-

пешеп беткән иде. Ул әллә кайдан ике тәгәрмәчле кул арба да алып кайткан иде. Иң элек шул арбага яшел сандык белән ике мендәрне салып тартып алып китте. Бу вакытта әти урыныннан тора алмый, күкрәген тотып, еш-еш йөткерә иде. Әни бераздан соң кайтып, калган нәрсәләрне төпчи башлады. Шул вакытта Фатиха абыстай килеп, әнинең кулындагы иске паласны тартып алды: „Киткән бер килмешәккә әйбер биреп җибәрергә монда Әндри казнасы бар дип белдеңме әллә? Бездә кешегә биреп җибәрер өчен җыйган мал юк“,—дип ачуланырга керешге. Аңа каршы әни бер дә ачуланмый гына: „Абыстай! Шушы нәрсәне генә бир инде, биш ел хезмәт иткән кешегә бер иске палас күп булмас; ирем авырганда, астына җәеп яткырырга бернәрсә дә юк бит!“ —дип сорап караса да, Фатиха абыстай якын да килмәде.

Шушы вакытта әти күкрәген тотып йөткерде дә карлыккан тавышы белән: „Кирәкмәс, сорама, ходай биргән итләрем беткәнче, такта өстендә ятырмын әле!“ —дип, күзләрен сөртте. Башка бер сүз дә әйтми, башын түбән салды. Тик әни генә кыза төшеп: „Безнең кебек синең дә көнең шул иске паласка калсын, кадалып кит!..“ —дип сөйләнеп калды.

Әни өченче рәт урап килгәндә, әти өйнең ишек алдына чыгып утырган иде. Ул җәяү барырга тырышып караса да, булдыра алмады, гыжлый башлады. Шуннан соң әни аны теге ике тәгәрмәчле кул арбасына утыртып тарта башлады. Кул арбасына утырырга сеңелем дә кызыккан иде дә, урын булмагач, аны мин җитәкләп алып киттем. Капкадан чыккан вакытта әти:

—Шушы йортта, ат сарайлары янында, үлеп калмасам ярар иде дип ходайдан сорый торган идем. Аллага шөкер, теләгем кабул булды, инде үлсәм дә үкенмим,—диде. Әни бер сүз дә әйтмәде.

Бай хатыны асраулары һәм балалары белән пыяла ишекне ачып, шуннан карап калдылар. Аның Габдулласы: „Әхмәй нинди шәп ат җиккән, ике аяклы ат!“—дип көлде. Абыстай: „Ат кадерен белмәгән кешеләргә шулай кирәк, безнең кадерне белмәделәр, менә бездән башка торып карасыннар әле“, —дип калды.

Ул вакытта әти дә, әни дә бер сүз дә әйтмәделәр. Урамга чыккач, миңа әллә нинди киңлек сизелде. Караңгылыктан бик матур яктылыкка чыккан кебек

булдым, тик әнине кызганып кына бераз борчыла идем. Чөнки ул әти утырган арбаны бик көч белән тарта, тигезсез урыннарда, тарта алмаган ат кебек тукталып, әрле-бирле кузгала, бераз барган саен хәл җыя иде.

Без яңа фатирга караңгы төшкәч барып кердек. Караңгы булганга күрә, мин өйнең эчен артык күрә алмадым. Өй бик тыныч, тик әти генә бертуктаусыз ыңгыраша, еш-еш ютәлли иде. Ләкин мин монда килгәч, караңгылык өчен дә, әтинең ютәлләве өчен дә артык кайгырмадым. Бәлки, теге йорттан чыгып китүне һәм иректә уйнавымны уйлап шатлана гына идем.

Бу эшләргә күп еллар үтте. Ләкин мин һаман шул урамнан үткәндә, шул каһәрле, күз яшьле йортка карарга җирәнәм. Аның матурлыгы эчендә әллә нинди котычыргыч ямьсезлек күрәм.

БЕЗНЕҢ ӘЙБЕРЛӘРНЕ САТКАНДА

I

Әтинең: „Җыю акчасы түләсе, недоимка бирәсе бар...“—дип зарланулары әле дә күз алдымда тора.

Ул ике сүзнең берсендә: „Сатарга әйбер дә юк ичмасам!.. Байлар түләделәр дә бетерделәр. Аларның җирләре күп, маллары бар. Шулай булса да, җыю акчасын безнең белән бертигез түлиләр. Аларга җиңел ул, менә безгә авыр!..“ —дип хәсрәтләнә иде.

Мин җыю акчасының, недоимканың нәрсә икәнен белмәгәнгә күрә: „Бездән нәрсә өчен акча сорыйлар икән?.. Безнең әтинең бер тиен дә акчасы юк бит!.. Ул мескенне нигә болай интектерәләр икән?..“ —дип уйлый торган идем.

Безнең өйдә болай әллә нинди артык нәрсәләр юк, мин белгәннән бирле бертөсле торган алача тышлы түшәк белән йоннары коелып тора торган бер ястык, ике кечкенә мендәр, иске чүпрәктән суккан бер палас һәм бер бик иске сандык белән әллә ничә җиреннән ямаган бер самовар бар. Өй эчендә шулардан башка күзгә күренерлек башка рәтле бер әйбер дә юк.

—Әгәр дә әтинең акчасы булса, ул безне как сәкедә яткырмас, берәр киез алган булыр иде.

Менә безнең күлмәк йөз җиреннән ямаулы, әни, һәркөн дип әйтерлек, безне мич башына мендереп утырта да, күлмәкләребезне салдырып алып, ертыксүтекләрен ямарга керешә. Үзе сөйләнеп:

—Ямаулык та юк, ичмасам!—дип, теге иске сандыкны ачып, андагы иске-поскы чүпрәкләрне актара, аннан берәр ямаулык табып, эшкә керешә, соңра тагы зарланып:

—Күлмәкләре изрәп беткән... җеп тотарлык җирләре дә калмаган!—дип әрни.

Әгәр дә әтинең акчасы булса, ул безне мондый

ямаулы һәм төрле төскә әйләнгән иске күлмәкләр белән йөртмәс иде.

Әнинең үз өстендә дә һаман бертөсле иске күлмәк. Ул мескен, үзенең күлмәген юган чакта, этинең чикмәнен киеп юа; чөнки алмаштырып торырга башка күлмәге юк. Үзе, кеше-кара килеп кермәсен өчен, безгә карап торырга куша: чит кеше килеп кергәндә, тиз генә мич артына кереп, шунда яшеренеп тора.

Әгәр дә этинең сатар нәрсәсе булса, шуны сатып, энигә яңа күлмәк алган булыр иде.

Күршедәге иркен тормышлы кешеләр күп вакытта итле аш пешерәләр. Ит салып пешергән ашның тәмле исләре танауга бәрелгәндә, без нишләргә белмибез. Ит һәм шулпа ашыйсы килә. Әни: „Бер ай булды инде, итле шулпа ашаганыбыз юк!..“ — дип зарланып куя.

Әгәр дә этинең акчасы булса — ул безгә ит салып пешергән тәмле шулпа ашатыр иде.

Этинең аска җәяргә киез алуда да, безгә яңа күлмәкләр алуда да һәм ит алып тәмле шулпа ашатуда да кайгысы юк. Ул һаман:

— Җыю акчасы, недоимка түләсе бар... Әйберләрне сатарлар инде?! — дип, иза чигә, нишләргә белми хәсрәтләнә.

Мин: „Безнең нәрсәне нигә сатсыннар? Самовар һәркөн үзебезгә кирәк. Иске түшәк белән ястык, мендәрләрне салып ятабыз. Аларны сатсалар, без ничек торырбыз?..“ — дип уйлыйм. „Аннан соң, бу әйберләрне кем алсын!“ — дим. Ләкин эти һаман кайгыра да кайгыра:

— Әйберләрне сатарлар инде! — ди. Ләкин мин бу әйберләрне кемнәр саталар, кайда алып китәләр — шуны һичбер күз алдыма китерә алмыйм. „Булмас, сатмаслар әле...“ — дим.

II

Этинең куркып йөрүе һәм: „Әйберләрне сатарлар инде!..“ — дигән сүзе дөрес булып чыкты: беркөнне безнең урамда ут чыккан кебек ашыгыч кузгалыш башланды. Сатар әйберләре булмаган һәм башка урыннан акча таба алмый, җыюларын, недоимкаларын түли алмаган ярлылар, самовар, казан, түшәк, ястык кебек, күз өстендә каш төсле күргән нәрсәләрен яшерергә керештеләр. Бу эшләр башта без малайларга кызык

төсле күренде. Без, башлаган уеннарыбызны ташлап, әйберләрен кайда куярга белми, җан тирләре чыгып, аптырап йөргән кешеләрне карап тордык. Бераздан соң мин үзебезнең өйгә кайтып кердем. Күп тә үтми әти дә кайтты һәм:

— Безгә дә килеп җитәрләр инде, нишләргә? — дип, башын тотып, сәкегә утырды. Әшнең бу дәрәҗәгә җиткәнен күргәч, әни дә куркып китте. Әтинең янына килеп, бик зур сер әйткән кебек, әкертен генә:

— Син, әллә түшәк белән ястыкны яшерәбезме? Алып китәрләр бит! — диде. Моңа каршы әти:

— Моңарчы алдашканым юк. Моннан соң да алдашмам, үз нәрсәмне үзем яшермәм инде. Алсалар алырлар да китәрләр... Шуның белән чәчрәп китсеннәр, аларга каберең якын булмасын. Алар йөрәк каныңны сыгып алырлар, — дип, әйберләрне яшермәскә булды.

Мин курку катыш кызык белән тагын урамга чыктым. Бездән өч-дүрт өй аша берничә җигүле ат һәм ул атлар янында байтак күп кешеләр торалар иде. Без, берничә малай, ул арбалар янына бардык. Бу арбаларга тышлары караеп, сүрүләре күренеп, йоннары чыгып торган түшәк-ястыклар, урталары саргылт булып, икенче төскә кергән берничә киез, кирпеч белән агартылганга шомарып беткән һәм төпләренә таба берничә урыннан кара кургаш белән ямалган самоварлар, төрле зурлыктагы казаннар ничек туры килде — шулай салынганнар иде. Күренешкә кызганыч булган бу әйберләрнең ияләре үзләре ул нәрсәләргә карап тилмереп торалар һәм кайгырып зарланышалар иде.

Без барып, әз генә торгач та, Хәбир абзыйларның самовары белән яңа гына куптарып алган казаннарын алып чыктылар да, теге нәрсәләр өстенә ыргыттылар. Бу әйберләрне алып чыгучылар: күкрәгенә медаль таккан Сәләхи староста белән бер кылычлы кеше һәм берничә десятский иде.

Хәбир абзый, әйберләре артыннан чыгып, теге кылычлы кешегә һәм Сәләхи старостага карап:

— Мин ничек түлим? Мин ярты душ җир көтәм. Ә әнә... кешеләр өчәр-дүртәр душ җир билиләр... Минем бер кәҗәм белән шул самоварымнан, казанымнан башка нәрсәм бар?.. Кыш алган бурыч өчен, җәй буе кешегә эшләп гомер үтә,— дип кызулана башлаган иде, аны староста бик кыска тотты һәм, ачуланып:

— Әле жыюыңны түләмәгән җитмәгән, ншшу әллә нәрсәләр сөйләп җаваплашып торган буласың... Башкаларны жыю түләмәскә котыртасың, кибәк баш,— дип җикерде дә, теге кылычлы кешегә карап, русча тел белән, әллә нәрсәләр сөйләргә кереште...

Бу вакытта шунда җыелып торган кешеләр, куркышып киткән кебек булып, читкәрәк тайчалып, авыз эчләреннән генә мыгырдашып куйдылар. Теге кылычлы кеше, Хәбир абзыйга карап, берничә сүз әйтте. Хәбир абзый да аңа каршы русчалатып җавап бирде. Мин аның: „Я солдат, земля нет“,—дигән сүзләрен генә искә алып калдым. Шулай әз генә җаваплашкач та, теге кылычлы кеше, десятскийларны чакырып, берничә сүз әйткән иде, алар шунда ук Хәбир абзыйны кайдадыр алып китәргә тели башладылар. Хәбир абзый аларга карышып, артка тартыла башлады. Шунда теге кылычлы кеше, кылычын кулына алып, нәрсәдер әйтеп акырды. Шуннан соң Хәбир абзый карышмыйча тегеләрнең уртасында китте. Хәбир абзыйның хатыны белән балалары бер Хәбир абзыйга, бер самовар белән казаннарына карап елашып калдылар.

Без, малайлар, Хәбир абзыйның, шундый зур кешедән дә курыкмый, каршы сөйләшүенә гаҗәпкә калдык. Бер зуррак малай: „Ул бит солдатта йөреп, дөнья күреп кайткан, шуның өчен курыкмый“,— диде.

Хәбир абзыйларның әйберләрен алганнан соң, бер йорт ташлап, безгә ике йорт аша булган Сәрби әбиләр турысына туктап, Сәрби әбиләргә кереп киттеләр. Анда озак та тормый, аның ястыгы белән киезен алып чыктылар. Сәрби әби үзенең самоварын яшереп өлгергән күрәсең, старостаның сүзеннән шулай аңлашылды.

Сәрби әби, староста артыннан чыгып:

— Сәләхи балам, киезем белән ястыгымны калдырып китегез инде... Бер-ике көннән соң кәҗәмне сатып, җыю акчасын түләрмен,—дип караган иде, аның сүзен тыңламадылар.

— Бу әйберләр базар җитми сатылмыйлар. Шунда кәҗәңне сатарсың да, әйберләреңне түләп алырсың,— дип, кузгалып киттеләр...

Безгә бер генә йорт аша булган Морат бабайларга туктап та тормадылар. Морат бабай бик бай булганга

күрә, ул җыю акчасын күптән түләп бетергән күрәсең. Ул үзе, кулларын бишмәт кесәсенә тыгып, капка төбендә тора иде. Аның яныннан үткәндә, Сәләхи староста да, теге кылычлы кеше дә, аның янында туктап, күрешеп, көлә-көлә сөйләшеп, тагын күрешеп киттеләр.

Аннан узып, безнең белән ут күршесе булган Гыйният бабайларга кергәннәр иде, ул өен бикләп, үзе әллә кайда киткән дә барган икән. Шуның өчен аның капкасыннан бик ачуланып чыктылар. Йозак ватып, кеше өенә керергә ярамый икән; сүзләреннән шулай беленде.

Чират безгә җитте.

Әти, бик зур гаепле кеше кебек булып, куркып кына, йөзләре агарынып, аларга каршы чыкты. Аның шулай куркып, кунак каршы алган кебек, хөрмәтләп каршы алуына карамастан, Сәләхи староста, сәлам дә бирми, ачулы рәвештә:

— Я, Хисмәт, акча әзерләдеңме?.. Тизрәк биреп җибәр, эш бик тыгыз...— дип сүз башлады.

Әти, мескен, әйбер урлап тотылган кеше кебек куркып, ык-мык итте; нәрсә әйтергә белми, алай-болай селкенде, сакалын сыйпап алды, соңра калтыравыклы тавыш белән:

— Әзерли алмадым шул, Сәләхи абзый. Шушы арада булыр да бит... Әле берәрсеннән берәр дисәтинә урак алмакчы булып торам. Кайда, үзең бирмисеңме?.. Иң элек сиңа урып бирер идем,— дип, сүз башлаган иде дә, Сәләхи староста, аның сүзләре беткәнен дә көтми, яман рәвештә ачуланып китте.

— Җыюны вакытында түләмисез дә, ишшу үзең биреп тор әле дип, акча сорап, кешегә салынасыз... Әллә миндә Әндри казнасы бар дип беләсезме?..— дип, әтине яндырып тирги башлады.

Әти, тагын да курка төшеп, гафу үтенгәнсымак:

— Юклык, Сәләхи абзый, юклык... Шушы арада табып бирермен... Зинһар әйберләремне саттырмый торсагыз ла...— дип, чак-чак әйтә алды. Ләкин әтинең тилмереп әйткән бу сүзләре аның ачуын гына китерде булса кирәк. Ул:

— Акча табарсың да, әйберләреңне түләп алырсың, борынрак хәстәрен күрәләр аның,— дип әйтте дә, кылычлы кешене ияртеп, безнең өйгә кереп китте. Без,

малайлар, тәрәзәдән карап тордык: алар, өйгә кереп, әрле-бирле карандылар да, башка рәтле әйберләр күренмәгәч, түшәк белән самоварны алып чыктылар. Бер-ике минут эчендә безнең түшәк белән самовар арбадагы башка нәрсәләр өстенә ыргытылдылар. Миңа бу әйберләр бик кызганыч булып күренделәр. Алар җансыз булсалар да, бездән киткәнгә кайгыргансымак булып торалар иде... Әйберләр артыннан карап калган әтинең күзендә яшь күренмәсә дә, әнинең күзендә яшь бөртекләре ялтырый иде.

III

Җыю акчасы җыючылар безнең очтан китеп, урамда тавыш-тын басылгачтын, өйгә кердем. Өйдә түшәк белән самовар юклыгы әллә кайдан күзгә бәрелеп тора, өйнең бер ягы китек калган кебек күренә иде.

Әти сүзсез генә, идәнгә карап, җилкәсен кашый, әни үзеннән-үзе:

— Үзем белән биргә килгән түшәгем иде... Әни мәрхүмнең төсе итеп кенә тота идем; акча табып, түләп алып кына булса ярар иде...— дип сөйләнә, үзе калган ястыкны кабартып, рәтләп куйган булып, түшәкнең буш калган урынын капламакчы була иде.

Әти, бик озак уйлап утыргач:

— Син юкка кайгырма инде, базарга чаклы берәрсеннән урак урырга акча алып, түләрбез. Акча түләгәч, түшәкне дә, самоварны да бирерләр,— дигән булса да, ул бу эшнең барып чыгуына үзе дә ышанмаган кебек тора иде.

Самовар юклыкның авырлыгы бик тиз беленде. Төшке чәйне эчәр вакыт җиткәч, күрше Морат бабайлардан самовар сорап караган идек тә, алар:

— Самоварлар үзебездән бушамыйлар. Хәзер утауга киткән көнлекчеләр кайталар,— дип кенә җавап бирделәр.

Әни самовар юклыкка аптырап тормады:

— Аларга көнең төшсә, шулай булыр инде... Өч самоварлары бар, шуларның берәвесен чәй эчкәнче биреп торсалар, ашалыр дип курыкканнардыр,— дип сөйләнгәннән соң, казан астына ут ягып җибәрде

һәм мәтрүшкә салып кайнатты да безгә чәй эчерә башлады.

Алда чыжлап торган самовар булмагач, чәй эчү күңелсезрәк булса да, безгә артык сизелмәде. Тик әти генә:

— Самовар белән чәй эчүгә җитми шул. Казан тәме — тимер тәме чыккан,— дип, казаннан чәй эчүгә ризасызлыгын белдерде.

Шул вакытта безгә Сәрби әби кереп, үзенең хәленнән зарлана башлады:

— Мине карар өчен льгот алып калган Салихым заводка эшкә киткән җирендә югалды. Бер елдан бирле хәбәр-хәтере юк. Фәттахны солдатка алдылар, ичмасам, аны да кайтармыйлар. Аннан да сигез айдан бирле хат юк. Әллә үле, әллә тере...— дип зарланып, елап алды. Соңра әтигә карап:

— Хисмәт балам, минем бер кешем дә юк бит, син базар көнне минем кәҗәмне сатып кына бир инде. Әллә өч тәңкәгә алырлар... Түшәгем белән киезем юк хакка китмәсеннәр инде. Карт көнемдә как сәкедә ятар хәлем юк,— диде.

Сәрби әбинең тамак туйдырып торган бердәнбер кәҗәсен сатуына әтиләр дә кайгырыштылар. Аның башка табар җире һәм байлардан урак урырга алырга көче булмаганга күрә, кәҗәсен сатмый әмәле дә юк иде.

Шулай итеп, безнең урамдагы ярлы кешеләр бүген бик зур хәсрәткә төштеләр. Һәркем үзенә иң кирәк булган әйберләре киткәнгә кайгырып, ничек булса да җыю акчасын түләп, әйберләрен кайтарып алырга акча табу юлын кайгыртырга керештеләр.

Безнең әти дә берничә кешегә барып, акча эзләп кайтты. Ләкин ул акча сорап барган кешеләрнең кайберсе өйдә булмаганга, кайберәүләре муллаларны ашка җыеп, аш үткәрүдән бушамаганга, кайберәүләре урдырасы җирләрен әллә кайчан биреп беткәнгә күрә, бер тиен дә акча таба алмый кайтты. Ул мескен бер җиргә барып кайтып, бераз уйланып утыра да, тагын чыгып китә, тагын кайта, тагын чыгып китә иде.

Без шулай самоварсыз, түшәксез беренче көнне үткәрдек. Бүген безнең өйдә бик күңелсез. Бүген кич пешерелгән балтырган өйрәсе дә көндәге кебек тәмле булып күренмәде.

IV

Базар көн житте. Әти һаман, акча табып, самовар белән түшәкне кайтарып ала алганы юк иде. Без һаман мәтрүшкә чәчкәсен казанда кайнатып, чәй урынына шуны эчеп килдек.

Базар көнне бик иртә торырга туры килде. Без чәй эчеп утырганда, кәҗәсен бакырта-бакырта житәкләп, Сәрби әби килеп житте. Ул үзе хәлдән тайган, үзе:

— Көтүдән калганга, иптәшләреннән аерылганга күрә бакыра мескен кәҗәм... Кемгә генә туры килер инде, сөте бик куе иде... Вак-төяк сыерга да биргесез иде... Үземнең балам кебек күреп асрый идем,— дип сөйләнә иде. Бу вакытта аның үзенең күзендә дә, кәҗәсенең күзендә дә яшьләр мөлдерәп торалар. Мин: „Ахры кәҗәсе дә Сәрби әбидән аерыласын беләторгандыр, шуңа күрә бакырадыр, шуның өчен күзләре яшьләнгән кебек торадыр“, дип уйладым.

Әти аннан-моннан гына чәй эчте дә, кәҗәне житәкләп, миңа артыннан куып барырга кушты.

Кәҗәне алып китә башлагач, ул дүрт аягын алга таба терәп тартыла башлады. Мин аңа сугарга да кызгана идем.

Кәҗәсенең шулай карышуын күргәч, Сәрби әбинең күңеле йомшап китте бугай, ул кәҗәсенең аркасыннан кагып:

— Хайванкай, бар, бар... Бер дә сатмас идем дә, саттыралар бит... Мескенкәемне үз балам төсле күрә торган идем дә, китә инде... Сау бул инде...— дип, күзләрендәге яшен сөртте.

Кәҗә болай гына барырлык булмагач, минем кулга чыбык биреп, шуның белән ныклап куарга куштылар. Эш болайга киткәч, кәҗә дә карышмый алга китте. Ул уңга яки сулга тартылып китәргә әйтә, үзе бакыра үзе артка карый һәм Сәрби әбигә: „Нигә мине болар кулына биреп жибәрәсен? Нигә мине куасың?.. Син элек болай түгел идең бит?..“ дигән кебек була иде. Шулай итеп, без базарга таба киттек. Сәрби әби, елый-елый, кәҗәсенең артыннан карап калды...

V

Бу базар ярлыларның җыю өчен сатарга дип китерелгән түшәк-ястыклары, самовар, казан һәм киез кебек әйберләре белән тулган иде. Кәҗәләр дә бик күп.

Без дә, Сәрби әбинең кәҗәсен шундагы кәҗәләр рәтенә китереп куеп, алучы көтәргә кирәштек. Ләкин алырга теләүчеләр бер дә күренмиләр. Кәҗәләрнең бәһалары бик төшкән.

Бу күп әйберләр арасында безнең самовар да мескен булып утыра, түшәкне ничек туры килде—шулай ташлаганнар, бер башы сүтелеп, йоннары чыккан. Мин аларны күргәч кызганып киттем.

Әни бит ул түшәкне һәркөн иртән кагып, кабартып, һәйбәтләп куя торган иде. Самоварны да чәй эчеп беткән саен кагып, көлләрен сөртеп куя һәм бик еш, ачы катыкка кирпеч тузаннары салып, шуның белән агартып, ялт иттереп куя торган иде.

Сәрби әбинең кәҗәсенә кемдер берәү сум сиксән тиен хак биреп китте. Әти:

— Кәҗә бик шәп, үзе буаз, аның бит тиресе дә бер тәңкә тора,—дип сөйләнеп калды.

Безнең самоварга ике тәңкә генә бирәләр, түшәкне караучы да юк. Әйберләрнең ияләре күзләрен мөлдерәтеп, нәрсәләренә карап торалар.

Хәбир абзыйны, түрәләргә каршы сүз әйткән өчен, ике көн ябып яткырганнан соң, бүген чыгарганнар икән; ул каяндыр акча табып, җыюын шунда ук түләп, казаны белән самоварын кайтарып алып, кайтып китте.

Ул киткән чакта, Сәләхи староста:

— Энем, моннан соң телеңне кыска тот. Алай бик белемле булып китәргә ярамый. Артыңны уйлап сөйләргә кирәк. Ярый әле мин әйтеп чыгарттым...—дип, төрле сүзләр әйтеп калды. Ләкин Хәбир абзый аңар каршы бер сүз дә әйтмәде, курыкты, күрәсең...

Шул ук әйберләр тирәсендә безнең авылның һәм күрше авылларның бай һәм иген күп чәчә торган кешеләре печән чабу, урак урдыру өчен алдан акча бирергә сатулашалар. Печән чабарга көнлек хакы 40 тиен, урак урырга дисәтинәсенә ике тәңкә акча һәм бер пот арыш оны биреп ваклашалар иде.

Байтак кешеләр, нишләргә белми, шул хакка күнеп, акча алдылар да, җыюларын түләп, самовар кебек кайбер иң кирәк нәрсәләрен алып киттеләр. Җәйге озын көннең төш вакыты җитеп килүгә карамастан, әле һаман безнең түшәк белән самоварны да һәм Сәрби әбинең кәҗәсен дә килешеп алучы булмады.

Əти, күтеп-күтеп аптырагач, кәҗәне минем кулга биреп, үзе әллә кайда китеп, бик озак югалып торды.

Кәҗәләр дә бик усал бит, тик торганда берсе-берсе белән сөзешергә телиләр, яки арбалардан, яшел ефәк кебек, яңа гына чабылып китерелгән печәннәргә омтылалар. Кәҗәне тыеп торам дип, беләкләрем талып бетте.

Əти, бик озак йөргәннән соң гына, минем янга килеп:

— Балам, син көтеп тор, мин хәзер түшәкне түләп алыйм әле, — дип теге Сәләхи старосталар янына барып, әллә нәрсәләр сөйләшкәннән соң, түшәкне күтәреп алып килеп, минем янга куйды. Күрәсең, аның самоварны да түләп алырга акчасы җитмәгәндер...

Сәрби әбинең кәҗәсенә ике тәңкәдән дә артык бирүче булмагач, әти мине, Сәрби әбидән ул хакка сатарга ярыймы, юкмы дип белеп килергә кушып, өйгә кайтарып җибәрде. Әлбәттә, мин шунда ук өйгә кайтып, Сәрби әбидән шулай сатарга ярыймы дип сорадым. Сәрби әби, бераз уйланып торганнан соң, бер дә арттыручы булмаса, җыю акчасын түләп, һич булмаса, түшәкне генә булса да алып кайтырга кушты, үзе:

— Күргәннәре-күрмәгәннәре шул булсын,— дип, бик сукранып калды.

Мин тиз генә кире базарга барып, Сәрби әбинең сүзләрен әтигә әйттем. Əти, бик озак сатулашып, бик нык кыркышканнан соң гына, кәҗәне ике сум егерме биш тиен көмешкә сатып җибәрде һәм, ике тәңкә акча түләп, Сәрби әбинең түшәген алды. Киезне, җитмәгән акчасы өчен дип, бирми калдырдылар.

Безнең самоварны әллә кайсы авылның бер кешесе өч тәңкәгә сатып алып китте. Аны күргәч, әти бик күңелсез генә:

— Әйдә, балам, кайтыйк инде, самоварны алып булмады ахрысы, ул китте... Менә урак ургач, яңа самовар алырбыз әле,— дип, кайтырга уйлады. Аның бу сүзләре миңа да артык күңелсез булды. Əти шунда ук түшәкләрне бер кешенең арбасына салып, үзебезнең өйгә кайтып киттек. Безнең әллә кайчаннан бирле күзебез өйрәнеп беткән самоварыбыз әллә кайсы авыл кешесенең кулында китте.

Әни белән Сәрби әби без кайтканны көтеп торалар икән: алар самовар белән киезнең калуына кайгырсалар да, түшәкләрнең кайтуына бераз гына шатланган сымак булдылар. Бигрәк тә әни үзе белән бергә кил-

гән, карт әнинең төсе булган түшәкнең кайтуына шатланды... Шунда ук сүтелгән җирләрен тегеп, тузаннарын кагып, көндә тора торган урынына илтеп куйды.

Без самоварсыз калгач, бөтен эш казанга теләлеп калды. Әни чәйне дә шунда кайната, кичкә таба кысыр ашны да шунда пешерә, кер юганда суны да шунда җылыта, кыскасы: казан белән бөтен эшне башкара башлады.

Без, бара торгач, самоварсыз торырга өйрәнеп киткән кебек булдык. Тик кайвакытта әни генә самоварсыз торуның уңайсызлыгыннан зарлана, аңа каршы әти:

— Менә, алдан алган уракларны урып бетерсәк, тагын да ялланып, урак урырбыз да, шуннан соң самовар алырбыз,— дип, аны юата торган иде. Бераздан соң самовар алырбыз, дигән уй белән без үзебезнең әллә ничә ел бергә гомер иткән самоварыбызны истән чыгардык. Ләкин Сәрби әби үзенең озын сакаллы ала кәҗәсен тиз генә исеннән чыгара алмады. Ул ике сүзнең берсендә, сөтсез чәй эчеп, йөрәге өзелеп бетүдән зарлана һәм: „Кәҗәм кәҗә генә түгел иде, вактөяк сыерга биргесез иде... Үзем үлгәнче онытмам...“— дип, һәрвакыт сагына иде. Без, үзебезнең самоварыбыздан бигрәк, аның кәҗәсен һәм Сәрби әбинең үзен кызгана идек...

Без бәләкәй чакларда булып үткән бу кызганыч күренешләр искә төшкәндә, әле дә мин аларны кызганып китәм.

Мескен Сәрби әбинең актык кәҗәсен сатулары, әтиләрнең җыю акчасын түләр өчен шул чаклы авырлык күрүләре әле дә күз алдымда тора. Ул заманда ярлылар шулай авыр торалар иде шул.

Ул вакытта кешеләрнең җирләренә, килерләренә карап налог салмыйлар иде.

Ул вакытта җирләрне хәзерге кебек тигезләп бүлмиләр иде. Ул чакта байлар, кесәләренә кулларын тыгып, ярлыларның шулай авырлык күрүләренә көлеп карап торалар иде.

Ул заманда ярлыларга да бертигез налог килә, алар аны түли алмыйлар, шуның өчен аларның актык кәҗәләрен, салып ята торган мендәрләрен, чәй эчә торган самоварларын, балтырган өйрәсе пешерә торган казаннарын куптарып алып сата торганнар иде.

Чөнки ул вакытта совет власте түгел иде.

ХӘЗЕР АНСАТ УЛ — ЭЛЕК КЫЕН ИДЕ

ГАЛИ АБЗЫЙ

Гали абзый хәзер 50 яшькә житеп бара, аның чәчләре яртылаш агарган, аркасы бөкрәя башлаган, күз төпләре жыерчыкланып, бөрелеп тора. Күзләре начарлана башлаганга күрә, соңгы елларда күзлек кия башлаган. Аны күрү белән, үз гомерендә бик күп эшләгәнлеге күренеп тора. Ул шулай картая төшсә дә бик шат. Иртәнге сәгать тугыздан алып, төштән соң сәгать дүрткә чаклы аны эш урынында күрәсең. Ул шул жиде сәгать эш вакытының бер генә минутын да бушка үткәрми. Аның эшне авырсынып, зарланып сөйләгәнен ишеткән кеше юк. Ул үзенең һәммә эшләрен пөхтә һәм тәртип белән алып бара. Үзенең өендә дә күп вакытын берәр эш белән үткәрә. Аның өенә барсаң, я укып утырганын, яисә ишек алдында берәр эш эшләп йөргәнен күрәсең.

Ул үзенә килгән кешеләрне ачык йөз белән каршы ала. Аз гына утыру белән, апага карап (без аның хатынын „апа“ дип йөртәбез):

— Я, Әсма, кунакларга самовар куйдыңмы? Чәйләп жибәрергә кирәк, — ди. Без: „Юкка мәшәкатьләнмәгез, чәй эчәр вакыт түгел әле“, — дисәк, Гали абзый:

— Нәрсәсе мәшәкать аның? Исән-сау кешегә „мәшәкать“ дип, ялкауланып торырга ярамый ул, — ди.

Аның шул сүзеннән соң озак вакыт үтми, өстәлгә чәй хәзерләнеп өлгергән була.

Менә шунда Гали абзый тагын да ачылып китә. Безнең арада сүз башлана: монда уку эшләре, хәзерге яшьләр тормышы, совет эшләренең барышы, хәтта чит илләрнең безгә карашы кебек мәсьәләләр һәммәсе дә сөйләнә.

Гали абзый хәзерге яшьләр тормышы, уку хакында бигрәк ихлас сөйли. Ул сүзен:

— Хәзер бик ансат ул, элек бик кыен иде, — дип башлап китә. Без аңа:

— Элек ничек кыен иде, хәзер нигә ансат? — дигән сөальне бирәбез. Менә шунда Гали абзый:

— Хәзер ник ансат булмасын? Хәзер бит эшче-крестьян балаларына юл ачык. Әгәр дә тырыш, уңган буласың икән, теләгән мәктәпне бетереп чыгарга, әллә кайда югары үрләргә мөмкин. Тик тырышырга гына кирәк. Элекке заманда ярлы эшче-крестьян балаларының башларына сугып, алга барган юлларыннан тукталар иде. Кайда ул хәзерге кебек теләгән мәктәпкә укырга керә алу?.. Хәтта хәзер бер тиенгә ярамый торган „дини мәктәпләр“гә керү дә ярлы балалары өчен читен иде. Безнең кебек ярлыларга анда да сан юк, без анда да бусага янында, идән уртасында, бай балаларының аяк астында таптала һәм шуларга чәй кайнатып, аш пешереп тамак туйдыра торган идек.

Хәзер бит эшче-крестьян балалары менә дигән мәктәпләрдә түләүсез, әзерне ашап укыйлар. Шуның өстенә аң-белем ала торган урыннарга барып йөри алалар. Кайда ул безнең заманда моның кебек җиңеллекләр...

Гали абзый шуннан соң безгә үзенең яшь вакытын сөйләп китә. Аның яшьлек тормышын сөйләгәндә, чынлап та, борынгы вакыттагы эшче-крестьян балаларының, бигрәк тә ятимнәренең, хәле бик авыр булганын күрәсең.

„Элек бик кыен иде; хәзер бик ансат ул“ дигән сүзнең мәгънәсен яхшы аңлар өчен, Гали абзыйның яшь вакытта күргәннәрен укысак, бик яхшы белербез.

ГАЛИНЕҢ ЯШЬ ВАКЫТЫ

Гали абзый үзенең авылдагы тормышын болай сөйли:

„Мин унике яшемдә чакта әти дә, әни дә үлеп, үксез, ятим булып калдым. Дөрес, мин, әти белән әни исән чакта да, йорт һәм кыр эшләренә катнашып эшли башлаган идем инде. Ләкин алар исән чагында, миңа боларны эшләү күңелле генә иде. Чөнки алар миңа көчем җитә торган эшләрне генә кушалар, аз гына арыганымны белсәләр, хәл җыярга ирек бирәләр һәм ашау-эчү ягын да кысмыйлар иде. Тамак тук, күңел күтәренке булгач, эш эшләү дә күңелле була тор-

ган иде. Шуның өстенә, балачакта, зур кешеләр кебек, эшләп кенә торып булмый, кайвакытта уйнасы да килеп китә. Менә шундый вакытта алар миңа үзем теләгән иптәшләрем белән күңел теләгән матур уеннарны уйнарга да ирек бирә торганнар иде. Шуңа күрә дә, алар исән чакта, минем гомерем артык күңелсез үтмәде. Тик ул вакытта укуның рәте юк иде, белем алуның юллары бикле иде. Ләкин кечкенә чакта укуның рәте юклыгын белерлек, аның өчен кайгырырлык аң юк иде әле.

Дөресен әйткәндә, минем тормышның авыр вакыты әти белән әни үлгәч башланды. Алар үлгәч, мин абзый белән җиңги кулында калдым. Алар кулына калгач, минем тормыш менә ничек булып китте.

Мин алар тәрбиясенә калу белән, алар миңа чит һәм артык бер кеше кебек итеп карый башладылар.

Мин аларның кушкан эшләренең берсен дә калдырмый эшлим. Ләкин шулай да аларга ярап булмый. Уен дигән нәрсәне хәзер бөтенләй башымнан чыгарып ташладым. Бала күңеле уен теләсә дә, хәзер ул теләк миннән бөтенләй алынган иде. Шулай беркөнне үземнең иптәшләремнең чокыр туп уйнауларына кызыктым. Алар мине үзләре белән бергә уйнарга чакырдылар. Мин инде өйдәге эшләремне дә бетергән кебек булганга күрә, алар белән уйнарга керештем. Уен бик күңелле иде. Ләкин бу шатлык күпкә бармады: җиңги мине чакырып алып, иң элек чикәгә берне бирде дә, соңыннан капкадан эчкә кертеп, артымнан тибеп җибәрде. Мин тәгәрәп китеп, йөзтүбән барып төштем. Эш моның белән генә бетсә, тагын бер хәл булыр иде. Ләкин алай гына бетмәде; абзый кайткач, мине әләкләп, тагын да бер-икене бирдерде, һәм һәр икәвесе:

— Моннан соң чыгып, уйнап йөрисе булма... Ишетсен колагың, әгәр дә тыңламыйсың икән, бездән шәфкать көтмә, — дип минем моннан соң уйнавыма чик куйдылар. Шуннан соң мин уйнаудан бөтенләй өмет өзеп, балаларның уйнаганнарын читтән генә боегып карап тора торган булып калдым.

Җәй көне мин кояш белән бергә тора торган идем. Минем эш, кояш чыккан вакытта, такыр басудагы атны алып кайту белән башлана иде.

Шулай, мин иртә үк торам да, күзне тырнап ачу белән, кулга йөгән алып, кырга йөгерәм. Кайвакытта

атның тышавы төшеп, бик ерак киткән була. Аны көчкә генә эзләп табам, ләкин ул тиз генә тоттырмый; аны куа-куа җаным чыга яза. Ул мине күрү белән читкә чаба, мин әллә кайлардан урап, аның каршысына чыгам. Шулай итеп мең бәла белән атны куып алып кайтам. Шул чаклы азап белән йөреп кайткач, алар икәүләп:

— Ник шул чаклы озак йөрдең? Ялкау. Син үрдәк оясы эзләп йөргәнсеңдер! —дип тиргиләр, әйтмәгән сүзләрен калдырмыйлар. Мин аларга каршы сүз әйтергә куркам. Сәкенең бер як читенә утырып, алардан калган суык чәйне эчеп, тамак ялгап алам да, шуннан соң кырга эшкә китәбез.

Бу ел без күршеләр белән сабандаш булган идек. Безнең бер ат, аларның өч ат. Көйсез агач сабанны шул дүрт ат көчкә генә тарталар. Ул вакытта хәзерге кебек ике ат белән җип-җиңел йөри торган матур тимер сабаннар юк иде әле.

Миңа ат башында йөрергә туры килде. Атларны пар-пар иттереп очлап җигәбез. Мин төпкә җигелгән ике атның берсенә атланам, алдагы ике атның дилбегәләрен муенга эләм, үзем менгән атның тезгене, алдагы атларның дилбегәләре кулда була. Атлар арык һәм чаман булмасалар, эшләр яхшы булыр иде. Ләкин күрше Гайфулла абзыйның аты бик ялкау, Хәйри бабайның бер аты бик чаман, икенче аты артык кызу булганга күрә, эш бик авырга китте.

Боларның берсе артык кызу тарта, икенчеләре урыннарыннан кузгалмый торалар. Аларның шулай төрлечә тартулары аркасында, сабан буразнадан чыгып китә дә, чи кала. Моның бәласе минем өскә төшә.

— Малай йомшак, атларны тигез куа белми, — дип, мине тиргиләр. Бигрәк тә җир башына чыкканда һәм кергәндә кыен; монда атлар буразнадан тигез чыгып, тигез кермиләр, шундый вакытта Хәйри бабай:

— Ай, пешмәгән нәрсә, җитлекми туган, — дип кычкыра. Шулай берничә рәт ачулары килгәннән соң, абзый миңа арттан карлау[1] белән җибәрә. Бер рәт шулай карлау арка үзәгемә тиеп, санымны катырды, мин алга бөгелдем дә төштем, тын алып та булмый, елап та булмый. Шунда Гайфулла абзый мине яклады:

[1] Төрәнгә ябышкан балчыкларны төшерә торган калак. *М. Г.*

— Син, дуамал кыланып, баланы үтереп куярсың бит, дурак, — дип, абзыйга ачуланып та куйды. Ул көнне минем аркага карлау тагын эләкмәсә дә, шул ук карлау икенче көннәрне тагын да эләкте.

Тары чәчәргә чирәм сөргәндә, эш тагын да авырлашты. Бер яктан, сабан килешми һәм, минут саен агач чөйләре сынып яки чыгып китеп, сабан ватыла; икенче яктан, атлар тарта алмый, бер-берсенә карашып, тик торалар. Яисә берсе тарткан вакытта икенчеләре тартмый калып, аптырашып торалар. Валеклар өзелә. Шуннан тагын миңа авырлык килеп төшә:

— Атларны тигез тарттыра белмисең. Тигез куалар аны, — дип, атлар да күрәселәрен күрәләр инде: Гарифулла абзый үзенең атын тугарып алып кыйнады. Аның ат башына сугуына минем күзләремнән яшь атылып чыкты. Мескен атны карлау белән сугып, күзен чыгара язды. Ике көн буенча атның күзеннән яшь агып йөрде. Шуннан соң ул ат авырлык күрүдә минем иптәшем кебек булып китте. Мин аны кызгана идем, ул да мине кызганган кебек күренә иде".

Гали абзыйның бу сүзләрне сөйләгәндә, хәзер дә күзендә яшьләр күренгән кебек иде. Ул, бик озын сулап:

— Их, хәзерге кебек, җирне ярып йөргән матур тимер сабаннар булган булса. Их, хәзерге төсле, тракторлар белән җир сөргән булсак, — дип, бераз уйлап торды һәм тагын сүз башлады.

— Күләм арасында һәм иртә-кич атларны карау да күбрәк минем өскә төшә иде.

„Шулай итеп, мин, сабан бетергәнче, тартай кебек арыкландым. Чәчләр җитте. Өс-баш бетте. Куллар катты. Битләр ярылып күгәрде. Сабан беткәндә, мин адәм танымаслык бер төскә кердем.

Печән вакытлары да бик җиңел булмады. Чүмәлә тарттырганда, ат башында мин йөри идем. Карышкан кебек, безнең чабын бик түмгәкле, тигезсез иде. Чүмәләләрне кибән куя торган җиргә тарттырганда, чүмәлә ауса яки торып калса, тагын мин гаепле булам. Абзый йөгереп килеп, мине бәреп җибәрә, тиргәнеп, карганып, чүмәләне рәтләп, юлга төшереп җибәрә.

Шулай кыр эшен эшләп өйгә кайткач та хәл җыярга ирек булса, бик авыр булмас иде. Ләкин миңа, өйгә кайткач та, хәл җыярга туры килми; кайту бе-

лән бозау карарга, сыерга су эчерергә кирәк. Аларны эшләп бетерүгә, җиңги үзенең елак баласын карарга куша.

Чүпрәк белән шикәрле икмәк имезеп, ботка ашатып, эче бозылып беткән бу бала елаудан бушамый. Аның елавын да миннән күрәләр. Җиңги эшен бетереп, баласын минем кулдан тартып ала да, мине этеп җибәреп:

— Кит моннан, хәерсез нәрсә. Син аны карамас өчен юрамалый чеметеп елатасың да, үзе елый дисең. Ятим бала асрасаң, авызың-борының кан булыр, ятим бозау асрасаң, авызың-борының май булыр, — дип, мине үзенең бозавыннан да түбән күрә. Мин аның шундый нахак һәм ачы сүзләрен ишеткән чакта, әрнеп китәм. Ике күземә яшьләр килеп тыгыла. Ул шулай елаганымны күргәч, кызгану урынына тагын да ачырак сүзләр белән тирги:

— Елаган була бит әле. Шайтанның күз яшенә кем ышансын... Бар, моннан чыгып кит... — Аркага берне кундырып, куып чыгарып җибәрә.

Мин иске чикмәнемне алып, үзебезнең печәнлек башына менеп, шунда ялгызым гына йокларга уйлыйм. Баш астына бүрегемне салам, аска печән түшим, өстемә чикмәнемне ябынам. Яту белән дә бик озак вакытлар күзгә йокы керми. Әллә нәрсәләр уйлап бетәм, тик башлар әйләнеп беткәч кенә, йоклап китәм. Иртән тагын:

— Тор!.. Моңарчы ни эшләп ятасың? — дигән ачулы тавышка уянам.

Көннәр шулай ачу астында, ачлы-туклы һаман эш белән үтәләр.

Кече атна көннәрендә башкалар күкәй буятып, уйнап йөриләр. Миңа ул да тими. Җиңги, минем ачуымны китерер өчен, үзенең кечкенә балаларына икешәр күкәй буяп бирә; аларга кызыгып караганымны күреп:

— Әллә җиткән башың белән балалар кебек буяулы күкәй белән уйнамакчы буласыңмы? — дип, тагын ачулана.

Мин боларның барысына да өйрәндем, үземне генә ялгыз вакытымда тиргәвенә күнектем. Ләкин аның күрше хатыннары арасында мине хурлавы бигрәк кыен була торган иде. Ул мине эштән чыгарып яманлый һәм:

— Шушы нәрсәдән кайчан котылырсың, бернәрсә урынында тормый, сөт өсте дисеңме, катык дисеңме, берсен дә калдырмый, — ди. Хәлбуки, мин алардан яшереп бер кисәк арыш икмәген дә алып капканым юк. Абзыйның да миннән котыласы килгән, һәрвакыт:

— Син, энем, бәла булдың инде! — дигән сүзен ишетәм. Шулай, мин монда, ятим булганнан соң, ике ел тордым. Мин шулай һаман торачак идем. Ләкин икенче елны күзгә каршы бөтенләй бер эш чыкты.

Ул эш менә болай булды.

Без көн буенча басуда тары бастырдык. Мин көн буенча ат куаладым, салам кагыштым, тары җилгәргәндә, себереп тордым, капчыкка тутырыштым. Шуны да әйтергә кирәк: ул заманда, хәзерге кебек, ашлык суга һәм җилгәрә торган машиналарның берсе дә юк иде. Ашлыкны ат белән бастыралар, яки кешеләр чабагач белән сугалар, соңыннан җилгә җилгәрәләр. Шуның өчен дүрт-биш арба ашлыкны берничә ат белән берничә кеше көн буе эшли.

Кояш баеган вакытта, басудан кайттык. Мин тамак ялгау белән, абзый атны куна алып барырга кушты. Киткән чакта:

— Иртәгә, кояш чыгуга кайтып җит! — дип әйтә калды.

Мин өйдән чыгып киткәндә, караңгы төшә башлаган иде инде. Мин малайларның кайда барганнарын белә идем, шуларны эзләп киттем.

Мин алар була дип уйлаган җиргә барып җиткәнче, караңгы төшеп җитте. Күкне каплап алган болыт бу караңгылыкны тагын да арттырды. Бик караңгы булганга күрә, мин малайларны таба алмадым. Аларны эзләп йөри торгач, үземнең нинди җирдә йөргәнемне дә белми башладым, адаштым. Аз гына барам да, авызга кулны куеп:

— Әхмәт, сез кайда?!.

— Малайлар!.. — дип сузып-сузып кычкырам. Ләкин һичбер тавыш ишетелми... юк. Үзем курка да башладым. Хәзер инде кайда барырга да белмим. Авылның кайсы якта икәнен дә ялгыштым. Шуның өстенә көн буе тары бастырып арыган һәм ачыккан ат минут саен җирдәге үләннәргә омтыла, башын тартып алыр хәл юк. Тирә якта әллә нинди карачкылар күренәләр. Барсаң, я берәр өем таллык була, яки бернәрсә дә булмый

чыга. Йөри торгач, бер кибән янына барып чыктым да, шунда кунарга уйлап, атны тышап, үзем кибәнне казып, печән астына кереп яттым.

Ничаклы арыган булсам да, күңелгә курку төшкәнгә күрә, күзгә йокы керми иде. Атның кырт-кырт ашавыннан һәм сирәкләп пошкыруыннан башка, бер тавыш та юк.

— Берәр бүре килеп чыкса, нишләрмен? — дим. Әллә нинди куркыныч бернәрсә килеп чыгар кебек була. Үзем калтыранам, күзләремне ныклап йомып карыйм, һаман йоклап булмый.

Шулай уйланып ята торгач йоклап киткәнмен.

Мин уянганда, кояш ике-өч таяк буе югары күтәрелгән иде. Абзыйның:

— Иртән, кояш чыгуга, кайтып җит! — дигән сүзе искә төшеп калтыранып киттем. Йөгәнне тиз генә кулга алып, атны эзләргә керештем.

Мин кунган җир сабан ашлыгы басуына бик якын булган икән.

— Атым берәр кешенең ашлыгын ашап, көлтәләрен туздырып бетермәгән булса гына ярар иде! — дигән уй белән ары йөгердем, бире йөгердем, ат юк!..

Басуга барып керсәм, нинди күз белән күрим: безнең туры ат урыс Кәрим дигән кешенең тары җиренә кереп, аның бер шәйшесе[1] янында тора. Шәйшесенең бер ягын актарып төшергән.

Минем кот очты, тыным бетте, калтырап киттем, күз алларым караңгыланды. Атымны тиз генә тотарга уйлап бардым, ләкин ат мине күрү белән, колакларын шомартып, икенче якка китте.

Тышавы төшкән икән!..

Мин атның каршысына төшәр өчен, икенче яктан урап йөгердем. Ул тагын артка чапты.

Мин шулай атны куып йөргәндә, минем бәхетсезлеккә каршы, урыс Кәрим килеп чыкмасынмы!

Ул, шәйше янына килеп, аның ишелеп төшүен һәм әллә ничаклы көлтәләрнең эштән чыгып җирдә чуалып ятуларын күрү белән, миңа карап кулын болгап:

— Качма, малай!.. Мин әллә кайдан күреп киләм, шәйшедәге тарыларны харап иткәнсең! — дип кычкырып, миңа карап йөгерә башлады.

---

[1] Шәйше — ботаклы агачлар өстенә очлайтып өйгән тары көлтәләре. *М. Г.*

Мин качарга да, качмаска да белми аптырап калдым: хата эшләгәч, качып йөрүнең файдасыз икәнен белеп, качмадым.

Кәрим карт минем янга килеп җитте дә, ямьсез, начар сүзләр әйтеп, уң як чикәгә чабып җибәрде; минем күзләремнән утлар күренде, мин бер якка авышып киттем. Шунда ук сул як чикәгә берне кундырды. Мин, башым әйләнеп, җиргә егылдым. Шунда ук куркуымнан елап җибәрдем. Ул һаман ачуланып:

— Әйдә тор, шельма малай! Атыңны тотып алыйк!— дип акырды. Мин, калтыранып, урынымнан тордым. Борыннан җылы бер нәрсә ага башлады, борын каный икән. Күзләрдән яшь, ике борын тишегеннән кан ага.

Кәрим карт, мине шул хәлдә күреп, кызганды булса кирәк, ул тавышын йомшартты һәм якын гына килеп:

— Әй малай, малай, көлтәләрне харап иттергәнсең бит!.. Алай йомшак булмыйлар аны,— дип юата башлады. Мин аның йомшак сүзләрен ишеткәч, үксеп елап җибәрдем.

Ул тагын сүз башлап:

— Елама — егет кеше еламый ул... абзыең көлтәләрне түләр, мин аны монда алып килермен,— диде. Мин аның: „Абзыең көлтәләрне түләр!“ — дигән сүзен ишетеп тагын да калтырап киттем:

— Мин харап иттергән көлтәләрне абзый түләр!..

Борын һаман каный иде. Камыллар арасыннан йомшак яшел яфраклар алып, борын тишекләренә тыктым. Шуннан соң гына кан тамчылары тукталды. Шунда ук тагын ат артыннан йөгердем. Ул тагын әллә кемнең җир өстенә барып бауга салган тары көлтәләрен ашарга керешкән иде инде.

Мин бер яктан, Кәрим карт икенче яктан барып, атны тотып алдык. Шул чакта авылның тагын ике кешесе безнең янга килделәр. Кәрим карт аларны алып килеп, җимерелгән шәйшене күрсәтеп, гуаһландырып[1] куйды һәм мине ияртеп, авылга — абзый янына алып кайта башлады.

Без шулай йөри торгач, кояш бик югары күтәрелде.

Без, авылга карап, бер җир буе да бармадык, каршыдан абзый килеп чыкты. Ул, мин кайтмагач, мине эзләп чыккан инде.

---

[1] Гуаһландырып — шаһит (свидетель) итеп.

Абзый безнең янга килеп җитәр-җитмәстән, Кәрим карт:

— Менә, Вәли, кара инде, сезнең ат бер шәйше тарыны харап иткән; шул балага ышанып, ат биреп җибәрәләрмени?— дип сүз башлады.

Электән дә миңа ачуланып, йөрәгенә чыдый алмый килгән абзыйның, Кәрим картның бу сүзләрен ишетү белән, күзләрен кан басты. Ул, миңа карап, эчендәге бөтен ачуын чыгарып:

— Шулай харап иттерденмени?!— дип җикерде.

Мин алдашуны яратмыйм, үлсәм дә эшнең дөресен әйтүне яратам һәм шуңа өйрәнгән идем. Монда да шулай, гәрчә үземә бик зур авырлык килерлек булса да, сүзнең дөресен әйтергә уйладым һәм бик куркып әкрен генә:

— Ашаган шул...— дидем.

Абзый, минем авыздан шул сүзнең чыгуын теләп һәм көтеп торган кебек әллә нишләп китте, артык сорашып та тормый яңакка уңлы-суңлы җибәрә башлады. Кәрим бабай ике арага төшеп, абзыйны тотмаса, ул мине истән язганчы кыйный иде, ләкин Кәрим бабай килеп аралады.

Мин хәзер елый да алмый идем. Борынга тыккан яфраклар бушагансыман булып китте. Авызга җып-җылы бер нәрсә килеп керде. Кулым белән сыйпап карагач, борын тишекләреннән гөрләп кан ага башлаганын белдем. Башымны түбән игәч, борыннан чырлап кан ага башлады.

Кәрим бабай белән абзый шул тары хакында сөйләшеп алга киттеләр. Абзый артка әйләнеп:

— Әйдә, дуңгыз малай, калма!— дип кычкырды. Мин алар артыннан барып җиттем. Шәйшенең бер ягы ишелеп ята иде. Эшнең чынлап та көткәннән артык булып чыгуын күргәч, абзый тагын минем өскә ташланды, тагын берне кундырып алды, тагын Кәрим бабай арага төште. Теге кешеләр дә безнең янга килделәр. Алар мине кан эчендә күреп кызгандылар булса кирәк, берсе:

— Шуның өчен баланы шулай кыйныйлармыни? Ул бала бит... Көз көнендә ат йөрүчән була ул,— дип, абзыйны юатырга керешә. Ләкин абзый һаман мине тиргн, сүгә иде.

— Кулың черегән нәрсә! Ат та тышый алмый, зарар

итә дә йөри, ялкау! — дип, тагын миңа омтылды. Мин кача башладым, ул, мине куа төшеп:

— Моннан соң күренмә күземә!.. Өйгә кайтып керәсе булма, мин сине исән калдыруыма ышана алмыйм! — дип кычкырып калды. Мин әрәмәлеккә карап йөгердем. Алар:

— Бер арба булыр!

— Юк, бер арба булмас!

— Юк, булыр!

— Менә бу пүнәтәйләр нәрсә әйтерләр бит?

— Я, Әхмәт, син әйт! — дип кычкырышып калдылар. Мин әрәмәлек арасына кереп киттем.

Әрәмәлек арасына кергәч, бераз тын алдым.

Минем баш чатный, колак шаулый, күз алдым караңгыланып тора, алга барырлык хәл юк иде. Шулай да, абзый эзләп килер дә тагын кыйнар дип уйлап, әрәмәлекнең эченә таба кереп киттем. Бик куе агачлар арасына кереп, яңа коелган сары яфраклар өстенә яттым да елый башладым.

Бераздан соң җиңеләйгән кебек булдым. Һичбер барыр җирем, батар күлем булмаса да, шул өйгә кайтып кермәү, икенче төрле әйткәндә, абзыйның мине бөтенләй кууы, миңа ирек һәм рәхәтлек биргән кебек булды.

Бу көн — көзгә таба була торган җылы һәм матур көннәрнең берсе иде. Миннән ерак түгел кечкенә күл буенда кыр үрдәкләре бак-бак кычкыралар иде.

— Алар да шулай, мин абзыйдан курыккан кебек, аучылардан куркалармы икән? — дип уйладым.

Ерактан торналар кычкырган тавыш килде. Алар татарча сигезле цифр кебек булып тезелешеп, бик югарыдан көн ягына карап баралар иде.

— Хәзер көз көне шул, алар безнең мондагы салкын кыштан качып, җылы матур якларга баралар. Их, шулар кебек ирекле рәвештә үзең теләгән җирләргә китеп, чит илләрне күреп йөрсәң иде, — дип уйладым.

Бара торгач, минем борын зураеп киткән кебек булды. Аның тишекләренә тыккан яфракларга кан оешып каткан икән. Баш авыртуы бераз басылып, колак яңгыравы беткәч, күл буена бит юарга киттем.

Күл тонык, терекөмеш кебек салмак, дулкынсыз, көзге кебек булып ята. Күптән бирле көзгегә караганым юк иде. Күл буена барып утыру белән, суда үзем-

неӊ йөзне күрдем. Үземнән үзем куркып киттем: бит өсләренә кырып алырлык туфрак ябышкан, ике күздән аккан яшьләр бит өстендәге каткан туфракларны ярып түбән төшкән эзләр беленеп тора. Борыннан аккан кан белән авыз тирәләре кызарып тора, борын, чынлап та, шешеп зурайган, башым берничә җирдән күбеп чыккан.

Ах, мине шушы рәвештә әти белән әни күрсәләр, алар һуштан язарлар иде.

Ике борын тишегендәге яфракларны тартып чыгардым. Алар кан аралаш катканнар иде. Иплән кенә борын һәм авыз тирәләрендәге каткан каннарны һәм биттәге туфракларны юдым. Бераз кеше төсенә кергәннән соӊ, агач арасындагы аклан җиргә чыгып, көндезге җылы кояшка карап яттым; бераз яткач, шунда, кояш җылысында, йоклап киткәнмен.

Мин уянганда, кояш түбән төшкән, аныӊ җылылыгы азайган һәм төн ягыннан салкын җил исеп, кисәк-кисәк, зур-зур кара болытларны куып китерә башлаган иде.

Мин кичә дә рәтләп ашамаганга һәм бүген бернәрсә кабып та карамаганга күрә, үземдә бик нык ачыгу сиздем.

Их, берәр телем арыш икмәге булса, нинди шәп булыр иде... Юк бит! Яз көнендә, кырда йөргәндә, ичмасам, карын ачып китсә, кakы, көпшә, кәҗә сакалы, кымызлык кебек төрле үсемлекләр ашап, тамак ялгап җибәреп була иде, хәзер алар да юк бит!

Агач башларында сирәк-сирәк кенә шомыртлар калган икән, шуларны чүпли башладым. Алар белән генә туярлык булмагач, баланнар да капкалап йөрдем. Ләкин болар белән генә минем эчем эзләнүдән туктамады.

Кояш түбән төште. Күк йөзендәге эре соргылт, кара болытлар, берсенә-берсе кушылып, күк битен каплап алдылар. Җил салкынаеп, чикмән ертыкларыннан өрә башлады. Минем башка „Хәзер миӊа кайда барырга?“ дигән уй төште.

Җәй көне, кыска төн заманы булса, менә шушы матур агачлар астында, кошлар сайраганын тыӊлап йоклар идем,—дип җәйге җылы озын көннәрне сагындым.

Монда торып эш чыкмас дип, агач арасыннан кырга чыктым. Авылга кайта торган юл белән авыл кешеләре эштән кайтып баралар.

Әнә Насыйр бабай үзенең ике улы белән нәрсәдер сөйләп кайтып бара. Болар кибән киртәләргә барган булсалар кирәк.

Менә ике арба белән Рәфыйк абзыйларның уллары, кызлары һәм киленнәре кайтып баралар. Йөкләре авырлыктан, арбалары салмак тавыш белән шыгырдап бара. Болар тары бастырып кайтып баралар инде. Мин, аларга карап, кызыгып калдым.

Юлда йөрүчеләр күренми башлагач, караңгы төшәр алдыннан, авылга карап чыктым. Ләкин минем аяклар бик ялкау атлыйлар; чөнки башта „анда кайтып, кемгә керәм, кайда кунам?“ дигән уй кайный.

Шулай алга атлар-атламас барганда, мин барган юлның уң ягындагы әрәмәлек эченнән Фәхри бабай килеп чыкты. Аның билендәге балтасына караганда, агач кисәргә баруы беленеп тора иде.

Ул мине күрү белән:

— Балам, бу вакытта ялгызың кайдан кайтып киләсең?— дип, үзе сүз башлады. Мин, аның соравына каршы нинди җавап бирергә дә белми, аптырап калдым. Чынын әйтсәм, абзыйны яманлаган булырмын кебек тоелды, чынын әйтмәсәм, ялганлаган булам.

Фәхри бабай, минем җавап бирми, көрсенеп куйганымны күреп:

— Нигә җавап бирмисең, балам, әллә берәвесе җәбер иттеме? Синең җиңгәңне бик усал дип сөйлиләр,— дип, минем йөрәкнең иң авырткан җиренә басты. Мин дөресен сөйләүдән башка юл тапмадым. Кичәдән бирле баштан үткән эшләрне сөйләп бирдем.

Фәхри бабай минем сүзләрне бик яхшылап тыңлады да, мин сөйләп беткәч:

— Ах, сакаллы сабыйлар, бер ятим баланың күз яше белән уйныйлар. Көз көнендә игенгә мал төшү гаҗәп эшме соң ул! Әйтер идем инде үзләрен!— дип, минем өчен үзенең бик нык кайгырганлыгын белдерде.

Без авылга кергәндә, эңгер вакыты җиткән иде. Мин эчемнән качып кына үзебезнең печәнлек башына менеп йокларга, таң беленгәч, кешеләр тормас борын, тагын кырга чыгып китәргә уйлап бара идем.

Фәхри бабай, үзләренең йортлары турысына җиткәч:

— Әйдә, балам, безгә кер, бездә кунарсың, бер балага әллә нәрсә кирәкмәс, синең атаң белән анаң

мәрхүмнәрнең күп изгелекләрен күрдем,— дип, мине үзләренә алып керде. Өйгә керү белән, Галимә әбигә карап:

— Менә бер бала да алып кайттым әле. Ашың пештеме?— дип сүз башлады. Галимә әби мине күргәч, гаҗәпсенгәнсымак булып:

— Бәй, балам, сиңа нәрсә булды? Әллә абзыең куып җибәрдеме? Җиңгәң бик усал шул! — дигән сөальне бирде.

Мин нәрсә әйтергә дә белми торганда, Фәхри бабай, сүзгә катнашып:

— Бала ни эшләсен, алар инде бу балага күрсәтмәгән авырлыкны калдырмадылар. Әле кырда кайда барырга белми йөргәнен күреп, үзебезгә алып кайттым,— дип, Галимә әбигә мин сөйләгән сүзләрне сөйләп бирде.

Алар минем хакта бик күп сөйләшкәннән соң, мине туйдырып, җылы урын җәеп бирделәр.

Мин бүген тыныч һәм бик озак йоклаганмын. Иртән торуга баш сызлавы беткән булса да, башның кубенгән җирләре һаман шул көенчә торалар иде әле. Галимә әби иртә белән дә минем тамакны туйдырды; мин китәргә әйткәч:

— Юк, балам, китмә, хәзергә бездә тор әле: кирәк тапсалар, абзыең килеп алыр: болай кайтып керсәң, ул сине тагын кыйнар,— дигәч, аларда калырга булдым.

Фәхри бабайга булышлык итәргә теләгәч:

— Хәл җый, балам: алай эшли башласаң, үзенә эшләтер өчен юрамалый котыртып алып кайткан дип әйтерләр,— дип, мине эшләтмәде. Мин абзыйның килеп алуын көтә идем. Ләкин аның: „Ачыкса кайтыр әле, сыер да ашаган җиренә кайта, кайтмый икән, аның безгә кирәге юк!“ — дип сөйләп йөргәнен килеп әйттеләр. Абзыйның шул сүзләрен ишеткәч, мин анда кайтып зарар гына итүемне уйлап, бөтенләй кайтмаска карар бирдем. Шулай итеп, үземнең туган йортымнан 13 яшемдә бөтенләй аерылдым“.

ГАЛИ АБЗЫЙ МӘКТӘПТӘ

„Фәхри бабайлар үзләре дә иркен тормышлы кеше түгел. Гәрчә алар һаман да мине үзләрендә торырга кушсалар да, мин кеше өстендә торырга уңайсызлана

башладым. Хәзер көз дә җитте. Авыл мәктәпләрендә укыр вакытлар якынлашты. Үзебезнең авылда мәктәп булса да, алай укучылар күп булмый торган иде. Миңа инде укучылар күбрәк җыела торган бер мәдрәсәгә барып, анда хезмәт итеп укырга кирәк иде. Мин шул яктан уйлап, үзебезнең авылдан ун чакрымнар чамасындагы бер авыл мәдрәсәсенә барырга уйладым.

Бу уйны Фәхри бабайларга әйткәч, алар да мәслихәт күрделәр. Мин китәр вакыт җиткәч, Галимә әби оекка баш сабып бирде, күлмәкне юып ямады, тагын да бер иске күлмәк рәтләде. Фәхри бабай яңа башмакчабата ясап бирде.

Киткән вакытта, алар миңа бер атнага җитәрлек икмәк, бераз гына чәй, биш-алты шакмак шикәр, бераз тары ярмасы биреп, озатып калдылар.

Мин бу көнгә чаклы үзебезнең авылдан чыгып, ерак җиргә барып, озак торганым юк иде. Шуның өчен бу китү бик авыр тоелды. Авылдан чыгып киткәч тә, мин үзебезнең авылга әйләнеп карый-карый киттем.

Көн салкын гына булып, өстән кар төшкәләп торса да, йөгерә-йөгерә баргач, алай өшемәдем.

Кичкә таба теге авылга барып җитеп, мәчет янындагы мәдрәсәгә барып кердем. Монда кечкенәрәк берничә мәктәп йорты бар икән. Ләкин әле укырга килгән кешеләр бик күп түгел. Бер дә таныш-белеш булмаган җиргә башлап барып керү бик уңайсыз булды. Өс-башта да начар булгач, анда миңа кызыксынып, мыскыл иткән төсле каршы алдылар. Малайлар минем янга килеп:

— Син кайдан килдең? Сине кем китерде? Нигә җәяү килдең? — дип сорашырга керештеләр.

Бер зур кеше килеп:

— Укырга килдеңмени? Алай булса шунда торып тор әле, хәзрәт килгәч, рөхсәт алырсың, — дип, шунда бер почмакта көтеп торырга кушты.

Ахшамнан соң хәзрәт килде. Ул мине күргәч, кайдан килгәнемне, караучым барлыгын-юклыгын сорашты. Мин үземнең ятим малай икәнемне, караучым юклыгын сөйләдем.

Мулла, минем сүзләрне тыңлап беткәч: „Ярый, шунда торырсың инде“, — диде. Урын-фәлән күрсәтмәде.

Ул вакытта ятып укый торган мәдрәсәләрдә ата-аналары бай булган балаларга урын бирәләр, аларның берничәсе бер урында торалар иде.

Безнең кебек ятим яки ярлы крестьян малайларына урын бирү юк, безгә шул идән уртасында, мич буйларында ятарга туры килә-икән.

Без шундый берничә малай булдык. Мин берничә көн эчендә малайлар белән танышып алдым. Вахит исемле малай белән дуслашып киттем: аның да минем кебек атасы-анасы юк икән. Авылда җәй буе бер кешедә йөргән; көз булгач, бернәрсәсез көенчә, шушы мәдрәсәгә килеп кергән.

Тагын Сәлим дигән бер малай икенче ел инде шушы мәдрәсәдә тора икән. Бу ел җәй мулланың эшен эшләгән, малларын караган, көз җиткәч, тагын мәдрәсәгә кергән. Сәлим әле дә көндезләрен муллага барып, аның эшләрен эшләп, тамак туйдырып, кич кенә мәдрәсәгә кайта.

Без шулай, тәрбиячеләре булмаган малайлар, үзебез бер төркем булып яшибез. Безнең урын юк, кайда туры килде, шунда торабыз. Тәрәзә янында, асларына киез, паласлар җәеп утырган шәкертләргә читтән кызыгып карап торабыз.

Минем үзем белән алып барган азык бер атнадан соң бөтенләй бетте. Хәзер миңа я ач торырга, яисә берәр эш табарга кирәк иде. Ач торып булмый инде, эш табарга кирәк. Шул уй белән шундагы иркен тормышлы малайларга чәй кайнатып, аш пешереп торырга хезмәткә керәм. Хезмәт дигәч тә, акча алу дигән нәрсә юк. Тик аларның калган чәйләрен эчү, калган ашларын ашау хакына хезмәт итәргә туры килә. Шуның өчен аларның юына торган суларына чаклы китереп бирәсең. Шуларга хезмәт иткәннән калган вакытта укырга туры килә.

Мәдрәсәгә укучылар җыелып беттеләр. Шәкертләр күплектән мәдрәсә тыгызланды. Безнең кебек җәмәгать сәкесендә торучы ятим, тәрбиячесез малайлар да байтак булды.

Мондагы укуларның матур ягын түгел, ямьсез ягын сөйләп бетерерлек түгел. Монда фән дигән нәрсәнең исеме дә юк. Бөтен укыткан нәрсәләре — дин өйрәтә торган китаплар. Аннан соң безнең кебек ярлы кешеләргә укырга кушучы, рәтләп сабак бирүче дә юк.

Мулла абзый белән хәлфәләр, кем күбрәк хәер-сәдака бирсә, кайсы малайның атасы аларны кунакка күбрәк чакырсалар, шуларны яхшырак укыталар. Безнең кебек малайларга тик үзләре тырышу гына кала.

Ул вакытта иске мәдрәсәләрдә, хәзерге кебек, балаларны болай сыйныфларга[1] бүлеп укыту юк. Тик кайсыбер укучылар, үзләренең чамаларына карап, сабакташ булып кына укыйлар. Сабакташ булганда да, бай кешеләрнең балалары үз тиңнәре белән, безнең кебек тәрбиячеләре булмаган балалар үзләре кебек ярлы балалар белән сабакташ булалар.

Без Вахит белән икәү сабакташ булдык. Ләкин без ярлы булганга күрә, безне укытучы хәлфә безгә бик салкын карый торган булды. Башка малайларга көн саен сабак бирсә дә, безгә атнасына өч-дүрт рәт кенә сабак бирә торган иде. Анда да ул безгә юк кына эш өчен дә ачулана, сабакны әз генә белми торсак, чикәгә ялт иттереп чабып җибәрә иде. Без инде ярлы булгач, һәммәсенә дә чыдый торган булып киттек.

Сәлим рәтләп үзенең китабын тотып та карамый. Ул мәктәптә ятса да, мулланың өенә барып, аның эшләрен эшләп кайта. Шуңа күрә аңа укырга кушучы да, укымаган өчен ачуланучы да юк. Ул, тик йөреп, укучы шәкерт исемен алып тора.

Монда иң нык авырлык безнең кебек шәкертләргә төшә. Таң атмас борын торып, суга барырга кирәк. Аннан кайту белән, намазга куа башлыйлар. Монда иң авыры — шул намаз дигән нәрсә. Намазга барсаң, самовар куймый калырга кирәк; бармасаң, шунда ук сине намазга бармаучылар спискасына язалар.

Менә бервакыт казый, намаздан чыгу белән:

— Кайда, китерегез әле, кемнәр намазга бармаганнар? — дип кычкыра.

Аның шул сүзен ишетү белән, кизү намазга бармый калучылар спискасын китереп бирә.

1. Басыйр.
2. Гали.
3. Вахит.

Тагын әллә кемнәр...

Казый безне үзенең каршысына тезеп утыртып, намазга бармауның сәбәбен сорый башлый:

---

[1] Сыйныфларга — классларга.

— Басыйр, син ник иртәнге намазга бармадың?

Ул калтырый.

— Мин, ди, башым авыртып калдым,— ди. Хәйлә кора.

— Ярый... Ә син, Гали, нигә бармадың?

— Мин... мин самовар куеп калдым.

Минем җавапны ишетеп бетәр-бетмәс, казыйның күзләре янып, бите кызарып, ачулана башлый:

— Ят, ахмак!.. Син һәрвакыт шулай самовар куюны сылтау итеп, намаз калдырасың! — ди.

Казыйның алдына сузылып ятам да, аның сыек тал чыбыгы белән аркага чаж-чож сукканын көтәм.

Ул тагын:

— Чикмәнеңне салып ят! — дип акыра.

Чикмәнне салып, күлмәкчән көенчә ятам.

— Ә син, кыек күз, ник бармадың! — дип, Вахиттан сорый.

Ул мескен дә мин биргән җавапны бирә.

Казый аңа да шулай ачуланып, бишмәтен салып, сузылып ятарга куша.

Без башны идәнгә терәп, казыйның сукканын көтәбез. Намазга барган балалар, безне мыскыл итеп, безнең сугылганны карап торалар.

Казый, үзенең янында торган берничә чыбыкның арасыннан иң сыек, иң озынын сайлап алып, аягүрә баса төшеп, чын көче белән шап иттереп берне бирә дә:

— Икенче рәт намаздан калмассыңмы? — дип сорый.

— Калмам, калмам!— дип әйтеп бетүгә, тагын, шап...

Арка буйлап төшкән чыбык үзәккә үтә, күздән яшь тәгәрәп төшә. Кулларның аркага барганын сизми дә каласың. Казый тагын да ачуын чыгарып:

— Кулыңны ал! — дип кычкыра.

Шап!.. Өч булды, бетте.

— Бар, кит!.. Икенче рәт бинамаз булма! — дип, сине алдыннан куа. Бер кул белән арканы, икенче кул белән битне тотып, мич алдына китәм. Озак үтми, Вахит та минем янга килә, ул да минем кебек әрнеп елый.

— Басыйр башым авыртты дип әйтсә дә, аны сукмады. Ул бай шул, — ди. Шулай шул, ул — бай баласы...

Без бер-беребезнең аркаларыбызны карашабыз. Аркалар, кара янып, чабырып чыккан була.

Тегендә малайлар бездән көләләр. Без нәрсә әйтергә дә белми, бер-беребезгә карашып, байтак вакытлар шунда торабыз. Арканың әрнүе бераз басылгач, күз-

дәге яшьләр кибә төшкәч, тагын да борынгы кебек шунда йөрибез.

Шулай намаздан калу, шулай казый тарафыннан сугылу, шулай арканың буй-буй булып, кара янып чыгулары бик еш булып тора.

Бу ел озын кыш шул мәдрәсәнең җәмәгать сәкесендә, шул бай малайларына хезмәт итеп, шулай сугылып, шулай хурлык күреп үтте.

Вахит белән икәү „Гарәп сарфын“[1] укып чыктык...

Көннәр үтте. Тагын да яз килеп җитте.

Язга таба өстәге чикмән тузды. Күлмәкләр аерылып, караеп, җеп тотмаслык хәлгә килде.

Шәкертләр таралып беттеләр. Без, тәрбиячеләре булмаган бер төркем малайлар, адашкан үрдәк кебек шунда калдык.

Вахит шул авылның көтүчесенә малайлыкка керде. Сәлим үткән елгы кебек, мулланың эшен эшләргә китте. Мин мәчет күршесендәге Шакир карт дигән кешегә җәй буе эшләргә 5 сум акча һәм биш пот арышка ялланып, ялчы малай булып кердем.

Җәй буе, Шакир байның зур хезмәтчесе белән, аның сабанын сөрдем, кыр эшләрен эшләштем, игеннәр урыштым, көлтәләрен ташыштым, аларны сугыштым. Көз җиткәндә, минем ике битем кара-кучкыл булып карайган һәм ярылган, куллар эштән чыгып каткан, сөялләнгән иде.

Мине хәзер бу авылда „Шакир карт ялчысы“ дип йөртә башладылар. Мәктәпкә кергәндә дә минем бу кушаматым калмады. Анда да шулай „ялчы“ исемен тагып кердем.

Минем, авылдан чыгып киткәч, беренче елым шулай үтте. Икенче, өченче, дүртенче елларым да шулай караңгы тормыш эчендә үтәчәге мәгълүм инде.

Ул вакытта ярлы эшче-крестьян балаларының гомерләре шулай үтә иде. Анда аларга тормыш юк. Аңбелем бирә торган мәктәп ишекләре ябык иде. Хәзер бик ансат ул, элек кыен иде...“

Гали абзый үзенең яшь вакытын, анда күргән авырлыкларын шулай сөйли.

— Бу әле элекке вакытта яшьләр күргән авырлыкларның меңнән берсе, — дип сүзен бетерә.

---

[1] Гарәп сарфын — гарәп морфологиясен.

ЮГАЛГАН АКТЫРНАК

КЫЗЫЛ СЫЕР

Һәр көн иртән торып, башка сыерлар белән көтүгә китә торган кызыл сыер бүген абзарда ялгыз калып, моңаеп бакыра иде. Актырнак, аның иптәшләреннән аерылып ялгыз калганын күргәч, аптырап китте,—„әллә мескен авырыймы икән?“ дип, кызыл сыерның хәлен сорашмакчы булып, аның янына барды. Койрыгын бутап, күзләрен мимылдатып, дусларча гына кызыл сыерның алдына туктады.

Кызыл сыер Актырнакның яхшы уй белән килгәнен белмәде, күрәсең. Ул:

— Минем болай да эчем поша, мине борчып йөрмә әле!—дигән кебек, ачуланып, башын түбән төшерде дә, капыл гына күтәреп, мөгезе белән Актырнакны айкап җибәрде. Актырнак бер як читкә тайчанып калмаган булса, кызыл сыерның мөгезләре аның корсагына кереп китәчәкләр иде.

Кызыл сыерның бу эшенә Актырнак аптырап китте һәм:

— Сиңа яхшылык итсәң дә кадерен белмисең икән,—дип, аның яныннан китеп, келәт янына барып ятты. Ул анда барып яту белән, яңа үсеп килә торган, уңны-сулны аерып белмәгән балалары Актырнакның янына килеп, көрмәкләшеп уйнарга керештеләр.

Нәни балаларның керсез күңелләреннән уйнап йөрүләре, бер-берсе белән көрмәкләшеп көч сынашулары Актырнакның төшенке күңелен күтәреп җибәрде. Ул, әле генә күргән ямьсез күренешне онытып, аларның төрлечә уйнауларын карап, күңелле уйга батты.

Аның балалары бераз уйнадылар да, капыл гына йөгерешеп килеп, әниләрен имәргә керештеләр.

Актырнак балаларын имезеп яткан вакытта, йорт хуҗасы Насыйр өйдән чыкты. Аның сул кулында бармак юанлыгы озын гына җеп, уң кулында ялтырап торган үткен пычак бар иде. Насыйр артыннан кулына комган белән зур табак тоткан Хәсби җиңги күренде. Алар, өйдән чыгу белән, туп-туры абзарга таба карап киттеләр. Актырнак, аларның төрле әйберләр тотып абзарга таба карап китүләрен күргәч:

— Болар бу нәрсәләрне кая алып баралар икән?— дип уйлап алды да, тиз генә урыныннан торып, алар артыннан чапты. Актырнак яткан урыныннан бик ашыгып торганлыктан, имә торган балалары җирдә ятып калдылар.

Насыйр белән Хәсби абзарга барып керделәр, кызыл сыер янына карап киттеләр. Кызыл сыер, аларның туп-туры үзенә таба килүләрен күргәч, моңлы тавыш белән мөңрәп җибәрде. Ләкин аларның кулларындагы коралларны күргәч, шикләнгәнсымак артка чигенде.

Насыйр, бернәрсәгә дә карамый, кулындагы пычагын читәнгә кадап куйды да, уң кулы белән сыерның мөгезеннән барып тотты. Икенче кулындагы җепнең элмәкле башын сыерның бер аягына эләктереп алып, калган аякларын бер җиргә китереп бергә җыйды. Шуннан соң сыерны, егарга теләп, бер якка этәргә кереште.

Сыер, күзләрен акайтып, каршы торырга теләп караса да, булдыра алмады, дөп итеп кабыргасы белән бер якка егылды да мышнап тыпырчына башлады.

Актырнак, моннан элек тә мал суйганны карап торганы булганга күрә, хәзер эшнең нәрсәдә икәнен сизеп алды.

Ул кызыл сыерны, бер яктан, кызганса да, икенче яктан, „сыерга шулай кирәктер, алар шуның өчен яратылганнардыр“ дип уйлады. Үзенең тиздән җыпҗылы кан, яңа ит белән сыйланачагын исенә төшереп, шатланып куйды:

— Кешеләр үзләре кызганмагач, миңа нәрсәгә кызганып торырга соң әле?— дип, сабырсызлык белән эшнең соңын көтә башлады.

Сыер җиргә егылгач тыпырчынды, башын берничә рәт күтәреп җиргә бәрде. Соңыннан, каршы торырлык көче юклыгын сизеп, буйсынырга мәҗбүр булды.

Ул арада Насыйр теге үткен пычак белән сыерның бугазын ышкып та җибәрде. Сыерның бугазыннан гырылдаган ямьсез тавышлар чыгып, каннары акканнан соң, ул бөтенләй җансыз калды.

Сыерны икенче урынгарак сөйрәп алып, тунарга керешкәндә, Актырнак аның бугазыннан аккан каннарны ялап азаплана, үзе эченнән генә: „Әле генә исән торган сыер суелды да куйды. Әле дә үзем сыер булмыйча, эт булганмын!.. Безнең этләрнең тормышлары начаррак булса да, кешеләр ачуланган вакытларында безне кыйнасалар да, — ичмасам, болай аякларыбызны бәйләп суймыйлар!“ — дип, үзенең эт булуына шатланды. Сыерның бугазыннан аккан каннарны ялап беткәннән соң, аның туналган җиренә килеп, үзенә өлеш көтәргә кереште.

Сыерның тиресе туналып, түшкәсе бүленеп, кар базына төшерелгәнче, Актырнак берничә рәт сугылу белән бергә, әллә ничаклы вак-төяк нәрсәләр ашады. Ит исен сизеп килгән күрше эте Акбай белән берничә рәт талашып, әчелешле булып алды.

Хәсби җиңги сыерның эчәге-карыннарын, чиләкләргә тутырып, су буена юарга барганда, Актырнак та барды. Анда Хәсби җиңги тарафыннан:

— Ай, ач кернә, бирән нәрсә!.. Һичбер туясың юк икән! — дигән авыр сүзләрен ишетте. Шул арада аның башына берничә рәт көянтә дә менеп төште. Су буенда тагын берничә эт белән талашып алды. Шундый авырлыклар күрүгә карамастан, үзенең тамагы туюга шатланып, моңарчы күргән авырлыкларның һәммәсен дә онытты. Авыз тирәләрен ялый-ялый, өйгә кайтты да, келәт янына ятып, балаларын имезергә кереште.

Бераздан соң өйнең ачык тәрәзәсеннән тәмле аш исе чыгып, бөтен ишек алдына таралды. Бу тәмле ис Актырнакның күңелен тагын да күтәреп җибәрде: „Хәзер үземнең тамак тук булса да, балаларым да бу

тәмле аш калдыкларыннан авыз итәрләр дә рәхәтләнеп калырлар", дигән уйлар белән ята торгач, күзләре йомылып, тәмле генә йокыга китте.

Аның кечкенә балалары, имеп туйганнан соң, тагы да бер-берсе белән көрмәкләшеп уйнарга керештеләр. Алар әле артык уйлап торырга өйрәнмәгәнлектән, өйдән чыгып киләткә таба китеп бара торган песине дә үзләренә иптәш кебек якын күреп, аның белән уйнарга теләп, каршысына чыктылар. Ләкин киләткә бик зур эш белән китеп барган песи боларны үзенә тиң күрмәде. Көчекләр үзенә якынлашу белән, сырт йоннарын кабартып, тешләрен ыржайтып, мырылдап, үз юлына китте.

Актырнак, йокысыннан уянып, балаларының үзара бик татулык белән күңелле рәвештә уйнауларына карап, бик шатланды. „Балаларым бик яхшы гына үсеп, этләр рәтенә кереп баралар бит әле... Менә бераздан соң үз көннәрен үзләре күрә башларлар, мине имеп йөрүне ташларлар", дип күңелен юатты. Шуннан соң:

— Бу сыерның суелуы, бер яктан караганда, яхшы булды әле: аның ите беткәнче, һәр көн аш пешәр. Үзем һәр көн табак-савыт юган юынтык суларын эчеп, майлы сөякләрне кимереп, көрәеп калырмын. Сөтем күбәер, шуның аркасында балаларым да таза булып үсәрләр, үзләрен-үзләре карап, тамакларын туйдырырлык бер мәлгә килерләр...—дигән уйларны башыннан үткәрде.

ӘХМӘТ ХИСАП ЧЫГАРА...

Ачык тәрәзәдән Насыйрның:

— Я, син, ашыңны тизрәк өлгерт әле. Бүген юлга чыгып, бераз җир барып кунарга кирәк. Иртәгә калага иртәрәк керерлек булсын...—дигән сүзләрен ишеткәч, Актырнак аптырап китте: „Әле күптән түгел генә калага барып кайткан иде бит... Тагын нәрсәгә бара икән?.." дигән уйга төште.

Насыйрның:

— Базары туры килсә, итнең хакы яхшы булыр. Болай сыер бик көр булып чыкты, ите бик яхшы күренә. Сигез поттан да ким булмас, бәлки артык та булыр,—дип сөйләнгәнен ишеткәч, Актырнак күңелсезләнеп китте:

— Мин юкка гына шатланганмын икән. Сатарга суйганнар, имеш!.. Монда шул: башы-тоягы, эче-карыны, үпкә-бавыры кебек әйберләре генә калса калыр инде, — дип уйлап торганда, Әхмәт кырдан ат алып кайтты. Әхмәтнең кайтканын күргәч тә, югарыдагы уйларын онытып, гәүдәсен боргалап, койрыгын селкеп, аңа каршы барды.

Әхмәт атыннан төшеп, атны лапас астындагы арбага бәйләп, алдына печән салганчы, аның тирәсендә йөрде. Ул өйгә кереп киткәч, аның артыннан карап калды һәм, „шушы Әхмәт сүз тыңлаучан, үзе бик илгәзәк малай... Минем балаларым да Әхмәт кебек шулай сүз тыңлаучан, башкаларга илгәзәк булып кына үссәләр ярар!..“ дип, Әхмәткә сокланып куйды.

Әхмәт өйгә кереп, аз гына торгач та, әтисе Насыйр:

— Балам, каләм белән кәгазеңне алып, минем яныма утыр әле. Мин әйтеп торган әйберләрнең хисабын язып торырсың, — дигәч, Әхмәт, каләм белән дәфтәр алып, әтисе янына барып утырды.

Бу вакытта Актырнак, тәрәзә янына ятып, Әхмәтләрнең нәрсәләр хакында сөйләшүләрен тыңлый һәм балаларының уйнауларын күзләп тора иде...

Насыйр, бераз уйлап торганнан сон, Әхмәткә карап:

— Сыерның ите сигез пот булды, ди. Потын җиде сумнан саттык, ди. Я, шуны чыгар әле. Җиде сумнан сигез пот иткә күпме акча тия?

Әхмәт бераз гына уйлап торганнан соң:

$$7 \times 8 = 56$$ дип язды да,

— Сигез пот ит җиде тәңкәдән илле алты сум була, — диде.

Насыйр тагын сүз башлап:

— Ярый, илле алты сум булсын. Тиресе ун сум булса, эч маеның потын ун ике сум хисабыннан сатып, утыз кадак майга тугыз сум алсак, бу була — унтугыз сум. Илле алты сум белән унтугыз сумны бергә кушсак күпме була, — чыгар әле, — диде.

Әхмәт:

— Алты җирдә тугызны бергә кушсак була, була илле дүрт, — дип, авыз эченнән сөйләнә-сөйләнә, цифрлар сукты да, иң ахырда:

$$\begin{array}{r} +\begin{array}{r}56\\19\end{array} \\ \hline 75 \end{array}$$

рәвешенә китереп:

— Житмеш биш сум була, — диде.

Насыйр:

— Бик яхшы!.. Инде ала торган нәрсәләрне исәпләп карыйк. Мин әйтеп торыйм, яза бар. Тимер сабан булсын, ди, егерме алты сум. Бер стан арба тәгәрмәче унике сум. Я, болары күпме тора инде?

Әхмәт, авыз эченнән генә мыгырдап, төрле цифрлар суккач:

$$\begin{array}{r} +\begin{array}{r}26\\12\end{array} \\ \hline 38 \end{array}$$

рәвешендә язды да, әтисенә карап:

— Утыз сигез сум була, — дип җавап бирде.

Насыйр, бераз уйланып торганнан соң, Хәсби җиңгигә карап:

— Я, син, кил әле. Тагын нәрсәләр аласы бар? Берьюлы хисаплап, эшне бетереп куярга кирәк, — диде.

Хәсби җиңги, камыр басканда онга буялган кулларын алъяпкычына сөртә-сөртә, болар янына килеп утырды да:

— Үзеңә бер бишмәтлек алырсың. Миңа бер күлмәклек кирәк булыр. Бер дә әдәм арасына киеп чыгарлык күлмәгем калмады. Әхмәткә берәр итек алырга кирәк. Аннан соң ике-өч пар чынаяк алыр идең, чынаяклар бик беттеләр. Кеше-мазар килсә, күршеләргә йөгерергә туры килә. Аннан соң...— дип, тагы нәрсәләр әйтмәкче булган иде, Насыйр аның сүзен бүлеп:

— Тукта әле син. Бик күп тезеп алып киттең. Ала торган әйберләрнең исемнәрен берәмләп кенә әйт, болай бер дә очына чыгып булмый. Баш чуалып бетте. Я, Әхмәт, син яз әле. Бишмәтнең тышлыгына биш метр алсак, биш метр нәрсәң, метры җитмеш тиеннән күпме була?..

Әхмәт башын бер яккарак салып, кәгазьнең өстенә төрле цифрлар сукты да, шушы $5 \times 70 = 350$ рәвештә язып:

— Биш метр әйбер, метры житмеш тиеннән, өч сум илле тиен була, — диде.

Насыйр Хәсбигә карап:

— Бишмәтнең эчлегенә күпме кирәк булыр икән? — дип сораганнан соң, Хәсби:

— Биш метр мулы белән җитәр, — дигәч, Әхмәткә:

— Яз әле: биш метр эчлек, метры кырык тиеннән, күпме була?

Әхмәт төрле цифрлар сугып, иң ахырда 5×40=200 рәвешендә цифрлар язды да:

— Биш җирдә кырык тиен — ике сум була, — дип куйды.

Насыйр:

— Балам, син бик тиз чыгарып бирәсең. Бик ашыгыч язып ялгыш җибәрмә. Калага баргач, алган әйберләргә акча җитми тормасын! — дип, Әхмәтне кисәткәннән соң, Хәсбигә карап:

— Сиңа соң күлмәклекне нинди заттан алырмын икән? — дип сорады.

Хәсби азрак уйлап торды да:

— Нәгыйм хатыны метры илле биш тиеннән бик матур сатин күлмәклек алдырган. Миңа да шундый сатин күлмәк алсаң, чыдамлы булыр иде.

Насыйр икеләнгәнсымак:

— Хакы бик кыйммәт икән шул. Ничә аршин кирәк булыр соң, ялгыш әйттем — ничә метр?..

— Алты метр кирәк булыр инде, — диде Хәсби.

Насыйр ризалык күрсәтеп, Әхмәткә карап:

— Я, яз әле. Алты метр сатин илле биш тиеннән күпме була? — диде. Әхмәт югарыдагы рәвештә цифрлар язып беткәннән соң:

— Алты метр сатин, илле биш тиеннән, өч сум утыз тиен була, — диде.

Әхмәткә итек алу турысына килгәч, Насыйр:

— Итеккә ни эшләрбез икән соң, әнкәсе?.. Яңа итек алсак, бик яхшы булыр иде дә, хакы бик кыйммәт булыр инде, — дигән сүзләрне әйтеп, киңәшкә кереште.

Әхмәт, үзенә итек алу хакында сүз кузгалгач, шатланып китте. Ул бу киңәшкә үзе дә катышмый чыдый алмады. Яңа итек алырга үтенгәнсымак бер тавыш белән:

— Әти, бер алганда яңасын алыйк инде. Мин аны мәктәпкә сабакка барган чакларда гына кияр идем, — дигән сүзләрне әйтте.

Әнкәсе дә аның сүзен дөресләп:

— Яңа итек булса, мәктәпкә йөргәндә арурак булыр иде. Алган-алганда кала ул,— дип, үзенең яңа итек алу ягында булганлыгын белдерде.

Насыйр артык каршылык күрсәтмәде:

— Ярый, анда баргач карармын әле. Алты-җиде тәңкәләргә булса, яңа итек алырбыз. Шунда да элек толчоктан карап карарбыз. Кайчакта анда да яңага биргесез нәрсәләр очрап куя. Ярый, Әхмәтнең итеге булсын, ди, алты сум. Шуннан соң тагы нәрсә аласы бар әле?..

Хәсби оныткан нәрсәсен исенә төшергән кебек:

— Чынаяклар дигән идем бит! Бөтенләй истән чыккан,— диде.

Насыйр:

— Өч пар чынаяк бер сум илле тиен чамасы булыр инде. Шуларны җыеп бергә исәплә әле: барлыгы күпме була икән?

Әхмәт каләмен тагын очлап алды да барлыгын бергә кушарга керәште.

Сабан	26	сум	
Тәгәрмәчләр	12	„	
Бишмәт тышы	3	„	50 тиен
Эчлеге	2	„	
Әнигә күлмәк	3	„	30 тиен
Миңа итек	6	„	
Өч пар чынаяк . . .	1	„	50 тиен
Барлыгы була:	54	сум	30 тиен көмеш.

Насыйр: „Дөрес хисапладыңмы?.. Ялгыш булмасын!..“ дигәч, Әхмәт яңадан бер мәртәбә җыеп карады,— һаман да шулай чыкты.

Насыйр хәзер эшнең очына чыгарга якынлашкан кебек:

— Хәзер эш бетте инде. Баягы 75 сумнан шушы илле дүрт сум утыз тиенне алгач, күпме акчабыз кала? Шуны гына чыгар да, аш ашап, китү ягын карарбыз,— диде.

Әхмәт иң элек

$$-\begin{array}{r}75\\54\end{array}$$

дигән цифрларны сукты да астына бер сызык сызып:

— Биштән дүртне алсаң бер кала, — дип, берле цифрны сызык астына язды. Аннан соң, җидедән бишне алсаң ике кала дип, ул икеле цифрны да сызык астына язып куйды.

Аның хисабы болай булып чыкты:

$$\begin{array}{r} 75 \\ -\,54 \\ \hline 21 \end{array}$$

Шул рәвешле язып биргәч:

— Җитмеш биш сумнан илле дүрт сумны алгач, егерме бер тәңкә акча кала, — диде.

Насыйр:

— Утыз тиенне чигерү кыен түгел инде. Аның өчен мәшәкатьләнеп язып торма, балам, — дигәч, Әхмәт урыныннан торып китте.

Әхмәтнең хисапны болай тиз чыгаруын күргәч, Насыйр да, Хәсби дә шатландылар.

Насыйр үзенең шатлыгын эчендә саклый алмады. Әхмәткә карап:

— Менә рәхмәт, балам! Яздың да — чыгардың да бирдең. Язу-сызу белгәч рәхәт шул. Кара исәп белән исәпләп торсак, баш катып та бетәр иде, очына да чыга алмас идек. Укуның файдасы хәзер үк күренеп тора. Менә мин яшь чакта укый алмый калгач, шул сумаларның да исәбенә чыга алмый аптырап беттем, — дип, Әхмәтне мактап куйды. Үзенең укый алмый калганы өчен кайгырды.

Актырнак тышкы якта, тәрәзә астында яткан көенчә, боларның сүзләрен тыңлап караса да, чынлап төшенә алмады.

Аның өчен итнең ни хакка сатылуы да, җиде җирдә сигезнең илле алты булуының да, метр дигән сүзнең дә кирәге булмаганга күрә, ул артык тыңлап та тормый, балалары белән уйнарга керешеп китте.

Балалары аның муенына килеп асылыналар; ул аларга ачуланган булып, йомшак кына ырылдап, аларны тешләп алган була да, бер якка чабып китеп, тагы да әйләнеп килә; алар белән көрмәкләшеп, җиңелгән булып, җиргә егылып китә; алды аягы белән аларны кысып алып, бер якка аунатып җибәрә иде.

Ул шулай байтак уйнагач, „аш пешә торгандыр инде...“ дип уйлап, тагын да тәрәзә төбенә килеп ятты да, өй эчендәге кешеләрнең сөйләшүләрен тыңлый башлады...

АКТЫРНАК КАЛАГА БАРЫРГА УЙЛАДЫ

Өй эчендә һаман да, калага барып, ит-май һәм тирене сатып, аларның акчаларына югарыда хисапланган товарларны алу хакында сүз бара иде.

Иң соңыннан Насыйр, үзе алып барган әйберләрне сатып бетергәннән соң, төрле товарлар алып йөрүнең зур гына мәшәкатьле эш икәнен уйлап:

— Әнисе, мин Әхмәтне дә калага алып барсам, ничек булыр икән?.. Сатасы-аласы әйберләр бик күп. Үзем анда-монда йөргәндә, атны карап, алган нәрсәләрне саклап, күз-колак булыр өчен бер кеше кирәк булыр бит,— дип, Хәсби җиңги белән киңәш итәргә керешті.

Хәсби:

— Бик якшы булыр. Әхмәтне үзең белән алып бар. Берүк, әйберләрегезне югалта күрмәгез. Юлда кунганда-ниткәндә, итләрегезне яхшы саклагыз. Эт-мазар ашап, пычратып куймасын,— дип, үзенең исәбенә төшкән киңәшләрне тезеп алып китте.

Хәсбинең „юлда итләрегезне яхшы саклагыз, эт-мазар ашап куймасын...“ дигән сүзләрен тыңлап торган Актырнакның күңеленә моңарчы бер дә уйламаган бер исәп килеп төште. Ул шунда ук: „Мин соң нигә алар белән калага бармаска?.. Шул чаклы тәмле сыер итен әллә нинди этләр ашар дип куркып торганчы, үзем саклап барсам нәрсә була?.. Аннан соң, шул калага барган бер кешенең, „кала-кала!“ дип, авыз суы корый. Шушы сылтау белән каланы үз күзем белән күреп кайтырмын, бу үзе бер йөреп, дөнья күреп кайту булыр. Гомер үтеп бара. Үзем шушы яшькә җитеп, шәһәр җирен дә күргәнем юк. Мин калага барып йөреп кайтканчы, балаларым да әллә ни эшләмәсләр әле. Бер-ике көнгә генә имми дә торырлар. Аларны бөтенләй имчәк ташлатыр вакыт та җитеп килә. Әкренләп башка нәрсәләр дә ашап өйрәнсеннәр, аналарыннан аерым торырга да күнексеннәр...“ дигән уйга килде. Үзе дә, калага китә торган кешеләр кебек

дәртләнеп, әрле-бирле йөреп алганнан соң, балаларын яхшылап имезеп, ныклап туйдырып китүне уйлап, келәт астына барып ятты да балаларын имезергә керәште.

Әхмәт, үзенең калага барачагын белгәч, бигрәк шатланды. Атны солыга кушканда да, арба майлаганда да, калага баруның кызыгын, каланы күрүен, туры килсә, китап сата торган җирдән китап, дәфтәр, каләм кебек әйберләр алуын уйлап йөрде.

Насыйр арбага печән салып, аның өстенә торпыша куеп китәргә хәзерлек күрүгә керәште.

Хәсбинең ишек алдына чыгып:

— Аш өлгерде, я, сез хәзерләнеп бетәсезме инде?..— дип, Насыйр белән Әхмәтне аш ашарга чакыруы Актырнакны сискәндереп җибәрде: „Калага китәсе булгач, тагын да берәр нәрсә ашап, юлга чыгарга кирәк, югыйсә ерак юлда хәл бетәр...“ дигән уй белән урыныннан торып, тәрәзә янына барып утырды да, башын югары күтәреп, тәрәзәгә күзләрен төшерде.

Насыйр белән Әхмәт, эшләрен бетереп, аш ашарга кергәндә, Актырнак, үзенең дә калага барырга уйлап йөргәнен белдерергә теләгән кебек, койрыгын бутап, күзләрен майландырып, аларның артларыннан карап калды.

АКТЫРНАК КАЛАГА КИТТЕ

Ит белән майны кар базыннан алып өстен бәйләгәнче, ат җигелгәнче, Актырнак тәрәзәдән ташланган сөякләрне кимереп, балаларын тагын бер кат имезеп алды да арба тирәсендә йөрергә керәште.

Насыйрның:

— Бу нәрсәгә монда, аяк астында буталып, кешегә комачаулап йөри!— дип ачуланып аягы белән тибеп җибәрүенә карамастан, ул арба яныннан китмәде.

Насыйр белән Әхмәт, арбага утырып, капкадан чыгып киткәндә, Актырнак балалары белән исәнләшкән кебек булып, аларны искәде дә тиз генә чыгып, арба артыннан чапты.

Насыйр, Актырнакның үзләре артыннан килгәнен күргәч, атны туктатып, капка төбендә карап калган Хәсбигә карап:

— Әй, син! Актырнакны чакырып ал әле. Безнең арттан бармасын!—дигәч, Хәсби:

— Актырнак, маһ-маһ!—дип, аны чакырырга кереште. Актырнак, аның тавышын ишеткәч, бер генә рәт әйләнеп карады да, тагын да алга китте.

Актырнакның болай гына сүз тыңламавын күргәч, Насыйр, арбадан төшеп, чыбыркысын шартлатып, куарга кереште. Актырнак бераз шикләнен артка китсә дә, Насыйр арбага утырып, алга киту белән, ул тиз генә урамның икенче ягына чыкты да алар артыннан китте.

Актырнакның бер дә калырга исәбе юк икәнен белгәч, Насыйр:

— Я, барса барсын инде,—дип, аның калага баруына риза булдылар да, атны юырттырып, авылдан чыгып киттеләр.

Актырнак, хәзер үзенең калага баруына каршы төшүче булмаганын белгәч, шатланып, иркенләп китте. Авылдан чыгу белән, юлның әле бу ягына, әле теге ягына чыгып йөри башлады. Ул кайчагында искәнеп бара да, озын арыш арасына кереп урап килә. Кайвакытта алга китеп, бераз җир барганнан соң, Әхмәтләрне көтеп тора иде. Шул арада арба янына килеп, арбада утырып барган Әхмәткә карап, койрыгын бутап, „мин дә сезнең белән калага барам бит әле... Иллә соң кырда баруы күңелле икән!..“ дигән кебек, бераз җир бергә барганнан соң, тагын тайпылып, берәр якка кереп китә иде.

Кала юлы Әхмәткә дә күңелле булып күренде. Мондый матур урыннардан, күрмәгән җирләрдән бару аның күңелен ачып җибәрде. Ул, бер яктан, тирә-ягындагы матур күренешләрне карап бара, икенче яктан, калага баргач, авылда булмый торган төрле нәрсәләрне уйлап шатлана иде.

Насыйр, үз гомерендә бу юлдан бик күп йөреп, калага да бик күп барып, өйрәнеп беткәнгә күрә, ул хакта уйлап та карамый иде. Ул, калага баргач, кызыл сыерның ит, май һәм тиресен сатып беткәннән соң, өйдә исемнәре саналган әйберләрне алып кайтуын, яңа сабан белән сабан сөрүен уйлап, эш турысында төрле планнар корып бара иде.

Боларның һәрберсе, үзенә күрә бер уй уйлап, алга киттеләр.

Берничә басуны, тирән генә чокырлы елгаларны үткәннән соң, юл бер авылга барып керде. Болар авылның очына барып керү белән, иң элек зур бер кара эт боларга каршы өреп чыкты да, Актырнакны күргәч, үзен үзе белми, Актырнакның өстенә ташланмакчы булып килеп тә җитте. Актырнак, эшнең куркыныч икәнен сизеп, тиз генә арба янына килде. Теге этнең зык куптарып абалап өргәнен ишеткәч, аннан да, моннан да өреп чыккан этләр бер-ике минут эчендә Насыйрларның арбасын сырып алдылар.

Этләр артыннан әллә нинди тәрбиясез малайлар чыгып, Актырнакны талатыр өчен, этләрне өстерергә керештеләр. Актырнак куркуыннан койрыгын ике боты арасына тыгып, тешләрен ыржайтып, арба астына сыенды.

Насыйр атын туктатып, чыбыркысы белән этләрне куа башлагач, алар бигрәк тә кызып, Насыйрның өстенә ташланырдай булып котырынып киттеләр. Кайберәүләре атның алдына чыгып, аның башына карап өрергә, кайберәүләре арбаның икенче ягына чыгып, арба астына керергә омтыла башладылар.

Соң дәрәҗәдә кызып, күзенә ак-кара күренүдән үткән этләрнең берсе Актырнакны капыл гына арба астыннан кагып чыгарды да, арт санынннан тешләп тә алды. Шул арада Актырнак, дистәләгән этләр арасында калып, талана башлады. Ул башта бирелмәскә теләп, бер-икесенә каршы омтылып караса да, булдыра алмады, этләрнең аяк астында калды. Этләр аны бияләй кебек өзгәләп, аунатып таларга керештеләр.

Насыйр чыбыркы белән аркаларына сыпыра башлагач, кайберәүләре шыңшып китсәләр дә, кайберәүләре һаман „дошманнары“ яныннан китми талауларында дәвам иттеләр.

Әхмәт, арба өстендә утырган көенчә, Актырнакны кызгана, үзе төшәргә курка иде. Теге, эт өстерүче малайларның тик торганда Актырнакның талануына көлеп, шатланып торганнарын күргәч, Әхмәтнең ачуы килде.

Шул арада боларга якын гына бер ишек алдыннан кулына озын колга тоткан бер малай йөгереп чыкты да, ачулы тавыш белән:

— Акбай, Дүрткүз, Кучкар!— дип, теге этләрнең исемнәрен әйтеп, кулындагы колга белән кирәкләрен бирә башлады.

Бер яктан чыбыркы, икенче яктан колга белән бирә башлагач, этләрнең гайрәтләре сүнә төште. Алар берәм-берәм читкә кача башладылар. Актырнак, этләрдән араланып чыккач, гайрәтләнеп китте. Хәтта үзе аларга ташланырга чаклы барып җитеп, арттарак калган бер этнең арт ботыннан тешләп алды. Этләр таралып, һәркайсы үзләренең капка төпләренә барып, шунда өрергә, калган ачуларын шунда чыгарырга керештеләр. Кайберәүләре, әллә нинди бер зур эш бетергән кебек җир тырнап, алай-болай йөреп, өрүләрен сирәкләттеләр.

Этләр таралып беткәч, Актырнак, чуалган йоннарын ялап, сыртын кабартып, койрыгын күтәреп, арба янына килде. Ул, үзенең зур көрәштән исән-сау калганын белдерергә теләгән кебек, Әхмәткә карап, койрыгын селекте. Мондый зур һәм куркыныч эштән болай асат кына котылуы өчен шатланганын белдерде.

Болар бу урыннан кузгалып алга киткәндә, теге, этләрне колга белән суккалап куган малай, этләрне өстереп йөргән малайларга карап:

— Сез нигә алай эт талатып йөрисез?.. Үзегезнең берәрегезне шулай бер ун-унбиш малай берьюлы кыйнаса, яхшы булыр идеме?! Сезне мәктәптә шулай этләр талаштырып йөрергә өйрәтәләрмени?— дип, аларга ачуланып калды.

Әхмәт эченнән генә ул малайга рәхмәт укыды.

Мондагы этләрнең пыр туздырылганын күргәннән соң, урамның теге башында, Актырнакны таларга чират көтеп, алдан хәзерлек күреп торган этләрнең дә гайрәтләре басылды. Алар үзләренең капка төпләрендә торган көенчә генә өреп калдылар.

Мондый бер көтелмәгән күңелсезлеккә очрау Актырнак өчен бераз уңайсызлык булып күренсә дә, авылдан үтеп киткәч, ул тагын да иркенләп китте. Авылдан чыгып, азрак баргач та, шунда агып яткан елгадан чәпелдәтеп су эчеп алганнан соң, хәлләнеп алды. Әле генә күргән авырлыкларны онытып, юлның әле ул ягына, әле бу ягына чыгып, борынгыча нәрсәдер эзләгән кебек йөри башлады.

Хәзер Әхмәтләрнең юлы кечкенә бер елга буйлап бара иде.

Елганың уң ягында гелән бодай гына чәчелгән, сул ягында, җирне вак-вак кисәкләргә бүлгәләп, тары, бодай, борай, карабодай, солы кебек төрле ашлыкларны аралаш чәчкән басулар ята иде.

Уң як басудагы бодайлар, тезмә чәчү белән чәчелгәнгә күрә, рәттән тезелеп, су сибеп үстергән кебек, гөрләп үскәннәр һәм кояшка каршы кара-кучкыл булып утыралар. Төрле ашлыкларны аралаш чәчкән уң як басудагы игеннәр күптән яңгыр әсәре күрмәгән төсле пәҗегәннәр, асларындагы туфраклары күренеп тора; кайбер урыннары артык куе, кайбер җирләре бик сирәк булып, тагын берничә көн аяз булса, бөтенләй эштән чыга торган кебек торалар иде.

Әхмәт бу ике басудагы ашлыкларның чәчелүләре дә, үсүләре дә ике төрле булуларының сәбәпләрен аңлап җитмәгәнгә күрә, нәрсә әйтергә дә белми, аптырап бара иде.

Шул вакытта аның әтисе атны үз уңаена атлата башлады да, арбасыннан төшеп, яхшы үскән бодайлардан берничә сабак бодай йолкып алып, кире арбага утырды һәм, Әхмәткә карап:

— Күрәсеңме, балам: менә бу бодайлар нинди шәп үскәннәр. Һәммәсе дә бертигез булып баш кысканнар. Үзләре берәмләп утырткан төсле рәттән тезелеп утыралар. Болар инде аязга бирешүдән үткәннәр. Ә инде теге як басудагы игеннәр бөтенләй начар. Анда безнең авылдагы кебек бер басуга төрле ашлыклар чәчкәннәр. Аларның үсүләре дә безнең авыл басуындагы игеннәр кебек начар булып, әллә кайчаннан бирле яңгыр күрмәгән төсле пәҗеп, бүгеннән эштән чыгарга торалар. Эшләү белән эшләүнең арасында нинди зур аерма бар!..

Әхмәт әтисенең бу сүзләрен ишеткәч, бер генә төрле иген чәчкән басуны күрсәтеп:

— Бу басуның кешеләре ничек эшләгәннәр соң? Аларның игеннәре нигә болай үскән? — дип сораганын сизми дә калды.

Әтисе Әхмәткә карап:

— Менә бу бодай гына чәчелгән басу моннан өч ел элек Карамалы авылыннан күчеп утырган „Алга" исемендәге яңа авылның басуы. Алар, совет күрсәт-

кән юл белән колхоз ясап, басуларын совет кушканча эшләргә керешеп киттеләр. Алар басуларын бездәге кебек өч басуга түгел, берничәгә бүлгәннәр дә, бер басуга бер генә төрле ашлык чәчәләр. Аннан соң болар, җирләрен җан башына бүлеп тормый, үзләренең бөтен җирләрен бергә билиләр.

Җирне эшләгәндә дә, барысы бергә сөреп, бергә чәчәләр һәм, шулай гөрләп үскән игеннәре пешкәннән соң, машиналар белән урып, бергә сугалар.

Алар, чәчәр алдыннан чәчү орлыкларын машина белән тазартып, җирләрен трактор белән сөрәләр һәм шулай тезеп чәчә торган сеялка белән чәчәләр. Алар басуларын һәрвакыт тирес белән яңартып торалар. Шулай берләшеп, машиналар белән яхшылап эшләгәнгә күрә, аларның ашлыклары тигез һәм яхшы булып үсә. Көннәр аяз булып торса да, андый игеннәр кызуга тиз генә бирешмиләр.

Әнә күрәсеңме: аларның бодайлары ничек сузып салган тасмалар төсле рәттән тезелеп утыралар.

Әхмәт хәзер ике басудагы игеннәрнең ни өчен ике төрле үсүләренең сәбәбенә төшенде. Кыш көнендә, мәктәптә укыганда, колхоз һәм машиналар белән җир эшләү турында укытучы абзасы аларга бу турыда сөйләгән иде. Хәзер аның сөйләүләре Әхмәтнең күз алдына килде һәм әтисеннән:

— Нигә соң безнең авыллар да шулай күчеп утырып, бергә эшләмиләр? — дип сорады.

Әтисе аның соравын көтеп торган кебек:

— Күптән шулай итәргә кирәк иде инде. Безнең авылда бу эшкә каршы торучы кешеләр аркылы төшеп килделәр. Хәзер инде аларның каршы төшүләренә карамый, үзебез бер унбиш-егерме йорт бергә җыелабыз да күчеп шулай колхоз булып утырабыз. Өченче көн дә шул турыда киңәш булды.

Әхмәт: „Кемгә каршы төшәләр соң?..“ дип сорарга уйлаган чакта гына, алдан „тыр-тыр-тыр!..“ дип, туктаусыз тырылдап ишетелгән бер тавыш аның күңелен икенче якка борып җибәрде. Әхмәт алга караса, анда көймәле арба зурлыгындагы бер нәрсәнең елга буеннан сыртка таба әкрен генә менеп барганын күрде.

Әхмәт тракторның исемен ишеткән булса да, аның үзен күргәне юк иде. Шуның өчен, тракторны күрү

белән, аның йөрәге жу итеп китте. Шул вакыт аның әтисе тагын сүзгә башлап:

— *Әнә күрәсеңме тракторны?!. Трактор шул инде. „Алга“ колхозы арыш басуларын икенче рәт парларга керешкән инде.*

Әхмәт трактор ягыннан күзен дә алмый карап бара иде.

Трактор турысына җиткәч, Насыйр агай, атын туктатып, тракторның юлга таба әйләнеп төшкәнен күтәргә кереште. Ләкин трактор, бара-бара, юлдан бик ераклашты, үзе дә чак-чак кына күренә башлады. Әхмәт, тракторның бик еракка киткәнен күргәч:

— Боларның җир буйлары бик озын була икән! — дип гаҗәпләнеп әтисенә карады.

Насыйр агай:

— Алар бит, безнең авылдагы кебек, җирләрне ярты дисәтинә, чирек дисәтинәгә бүлеп тормый, берничә дисәтинәне берьюлы сөрәләр. Аларның җир буйлары ярты чакрым һәм аннан да озын була. Алар шуны, бертуктамый, рәттән сөрәләр дә сөрәләр.

— Кара әле син аларның сөрүләрен! Күрәсеңме: бер генә кул яссуы чаклы да җир калдырмаганнар. Аның өстенә нинди тирән сөргәннәр...

Алар җирнең яхшы сөрелүен карап, шул турыда сөйләшеп торган арада, трактор, сөрә торган җирнең теге як башына җитеп, кире әйләнде.

Трактор җирне актарып, бертуктаусыз сөреп килә, үзе һаман болай якынлаша иде. Трактор якынлашкан саен, Әхмәтнең кызыксынуы артты. Ул, Актырнакның койрык селкеп, үзенә таба килеп, иркәләнеп, аягына ышкынып китүен дә сизми калды.

Ат өркеп-нитеп китмәсен өчен, Насыйр агай, туры атның башыннан тотып, юлдан читкәрәк чыгарып, елга буендагы бер агачка бәйләп куйды.

Трактор килеп җитте, аның өстендә утырган яшь кенә егет аның әллә нинди бер җирен борган иде — трактор тып туктады.

Насыйр агай белән Әхмәт тракторның янына бардылар.

Аягына ныклы итек, башына кепка киеп, майланып беткән алъяпкыч бәйләгән кара күзлекле егет трактордан ыргып төште дә, күзлеген маңгаена куеп, болар белән исәнләшкәннән соң, ящик кебек бер җирне

ачып, савыт белән майны алды да тракторның төрле жирләрен майларга кереште.

Трактор үзе туктаса да, җанлы нәрсәләр кебек „тыт-тыт-тыт“ иткән тавышлар чыгара һәм астыннан төтеннәр бөркеп тора иде.

Әхмәтнең кызыксынуы чиктән узды. Ул теге егетнең трактор белән шулай батыр кылануларына, теләсә кайсы винтын борып, кара савыт зурлыгындагы тишекләрен ачып, май тамызуларына хәйран калып, күзен дә алмый карарга кереште.

Ул шулай карап торганда Насыйр агай йөртүче егеттән:

— Бу трактор белән көненә күпме җир сөреп була?—дип сораша башлады.

Теге егет кулындагы май савытын җиргә куеп, кулларын алъяпкычына сөртә-сөртә:

— Көненә өч дисәтинә җирне иркен сөрәм. Смена белән йөргәндә, артык та сөреп була да, тик әле эш бик ашыгыч булмагач, смена белән сөреп тормыйбыз,— дигән җавапны бирде.

— Өч дисәтинә диген, ә? Бер көндә өч дисәтинә? Безнең бит ат белән өч дисәтинә җирне сөреп житкәнче җаныбыз чыга.

— Элек без дә шулай интегә идек. Трактор алганнан соң андый михнәттән котылдык...

Насыйр агай белән теге егет колхоз турында сөйләшеп торган арада, Әхмәт тракторны карарга кереште; әле бер җирен, әле икенче җирен карап, тракторны берничә әйләнде. Тракторның артындагы сабаннарның зур һәм ныклы булуларын, ат белән сөрә торган сабаннарның болар янында уенчык төсле генә булып калуларын уйлап, шаккатып карап торды.

Теге егет, Насыйр агай белән бераз сөйләшеп торганнан соң, май савытын теге ящикка салып куйды да, тракторның әллә кайсы җирен борып, өстенә менеп утырды һәм кулы белән бернәрсәне уңга боргач та, трактор җанлы нәрсә кебек кузгалып та китте.

Насыйр агай белән Әхмәт, көчле төрәннәрнең кәсләрне әйләндереп ташлап, кара җирдән зур-зур дулкын ясап алга киткәнен карап калдылар. Бераз карап торганнан соң, Насыйр агай:

— Менә, ичмасам, сөрү дисәң дә ярый. Машина тек машина шул инде! Жен кебек, җирне пыр туздырып

бара. Егерме ат җиксәң, болай тирән итеп, шәп сөрен булмас. Арык-торык ат белән сабан сөреп, җирне аннан-моннан ерткалап, без дә сабан сөрәбез дип йөрибез шунда, — дип, бәйләп куйган атны алырга китте.

Әхмәт тракторга сокланды һәм аны йөртүче егеткә, аның шулай һөнәрле булуына кызыкты. „Зурайгач мин дә шулай трактор йөртүче булырмын, шуңа өйрәнми куймам...“ дип, эченнән генә уйлап та алды.

Насыйр агай атны алып килеп, арбага утырып, юлга төшеп киткәннән соң, Әхмәткә карап:

— Күрдеңме, балам, трактор ничек сөрә. Ә без монау ат белән сабан сөрәбез дип, үзебез дә хәлдән таябыз, атыбыз да эштән чыга. Сөргән җиребезнең сукыр тычкан казынган җирдән аермасы булмый. Мондый машина белән сабан сөреп йөрүе уен гына бит ул! — диде дә уйга калды һәм, бераз барганнан соң:

— Без дә озакламый, колхозга күчеп, шулар төсле эшли башларбыз инде. Байлар белән муллалар каршы төшә дип, гомер буе тирес лектә ятып булмас, әйдә, на-на! — дип, атны куып юырттыра башлады.

Озак та үтми, Әхмәтләр кечкенә бер авылга керделәр.

— Менә „Алга“ колхозы шушы инде! — диде Насыйр агай.

Авыл кечкенә, ләкин бик матур. Елга буйлап бертөслерәк өйләр тезелгән. Каршыларына зур гына берничә келәт һәм шулар белән рәттән амбар кебек нәрсә бар. Келәтләрнең артыннан ук яшелчә бакчасы башлана. Анда хатын-кызлар һәм малайлар зык кубып бәрәңге утап йөриләр. Шул ук келәтләрдән ерак түгел бер җирдә зур кешеләр тагын бер йорт эшләп яталар. Шул йорт турысыннан узганда, Насыйр агай йортны эшләүче кешеләр белән исәнләшеп үтте һәм, бераз баргач:

— Әнә алар мәктәп сала башлаганнар. Үткән атнада калага барганда, шулар белән сөйләшкән идем: „Балалар өчен теге авылга сабакка йөрү кыш көне уңайсыз була, инде үзебезгә мәктәп салабыз“, диделәр. Бик яхшы итәләр шул. Менә берләшкән кечкенә авыл да ничек алга бара! — дип, үзенең бу авылдагы тормышка кызыкканын белдерде.

Бу вакыт Әхмәт тә бу авылның матурлыгына, кешеләренең өмә вакытындагы төсле мыжгып, шатланып йөрүләренә кызыгып бара һәм эченнән без дә шулай колхозга күчеп утырсак иде дип тели иде.

Авылдан чыгып, берничә чакрым барганнан соң, бик матур бер су буена җиткәч, Насыйр:

— Шушында куннп китик инде. Кояш та батып бара, ат та йончыды. Үзебез дә ачыктык, — дип, атны юлдан борып читкә чыгарды да, зур гына бер агачның астына барып туктатты.

Насыйр үзе атны тугара башлады да, Әхмәткә карап:

— Балам, син чәйнекне ал да, елганың агып яткан җиреннән генә чәйгә су алып кил. Һәйбәтләп чәй эчеп алырбыз, — дигәч, Әхмәт чәйнекне алып суга китте. Агачлар арасыннан барып, елганың чылтырап агып яткан бер җиренә туктап, чәйнекне яхшылап чайкаганнан соң, чәйгә су алып, бер як читкә куйды да, кулларын сызганып, салкынча су белән бик әйбәтләп юынды. Салкын су белән юынгач, ул тагын да рәхәтләнеп китте. Әхмәт су алып килгәндә, әтисе атны тугарып бетереп, суытыр өчен бер агачка бәйләп куеп, үзе кулына балта алып, чәй кайнатыр өчен, коры утыннар җыеп йөри иде.

Күп тә үтми, чәйнек асарга агач кагылып, ут ягылды. Коры чыбыклар матур гына тавыш чыгарып, гөрләп яна башладылар.

Хәзер Актырнак, үлән өстенә ятып, бу матур күренешкә сокланган кебек карап ята. Әхмәт чәйнек тирәсенә агачлар куеп, чәй кайнатып утыра. Насыйр агай арбадан әйберләрне алып, чәй урыны хәзерләп йөри иде.

Чәйнек озак көттермәде: атылып кайнап чыкты. Чәй салынып, ашъяулык җәелеп, өйдән алып чыгылган юл азыгы ашъяулык өстенә куелды да, чәй эчү башланды. Юлаучыларның мондагы чәйләре өйдә эчелгән чәйләргә караганда татлы, азыклары тәмле, бөтен күренеш соң дәрәҗәдә ямьле булып күренде.

Юлга алып чыккан азыклардан Актырнакка да өлеш чыкты. Аңа да, бераз булса да, икмәк кисәкләре, салкын итнең калдык-постыклары эләкте. Актырнак өчен чәйнең һичбер кирәге булмаганга күрә, ул чәйгә омсынып та тормады. Ул Әхмәт белән Насыйр кулындагы ит кисәкләренә карый, шул тәмле нәрсәләрдән үзенә

әлеш чыгуын көтә, аларның бу азыкларны авызларына кабып җибәргән вакытларында күзләрен майландырып, башын бер яккарак кыйгайтып, „ах, миңа да шул тәмле нәрсәләрне үз ихтыярым белән шулай ашап торырга туры килсә, нинди шәп булыр иде!..“ дигәнсымак карый иде.

Тирә-яктагы агачлар арасындагы кайбер җанварларның шытырдап тавыш чыгарулары, төрле кошларның ботактан ботакка очкан вакытта, агач яфракларының җилфердәп киткән тавышлары ишетелгән вакытта, Актырнак тавыш чыккан якка карап ала, дәртле кузгалып, чабып китәргә уйлап куя, тик мондагы ашамлыкларның калдыкларын ашаудан коры калуыннан куркып, тагын да урыныннан кузгалмый кала иде.

Матур җирдә сөйләшеп эчелгән чәй, бик тәмле тоелып, байтак вакыт алды. Чәйнектәге чәй, суына төшкән саен, кабыргасы белән янып торган утка куелып, берничә рәт чыжылдатып алынды.

Болар чәй эчеп бетәр чакта, туры ат, үзенең дә ашыйсы килүен белдерер өчен, аягы белән тыпырчынып, бәйләп куйган җиреннән китәргә теләп тартына башлады, буе җиткән җирдәге агач яфракларын әләктереп алып, агач ботакларыннан тавыш чыгарды.

Чәй эчелеп беткәч, Әхмәт, ат янына барып, аның ял асларын тотып караганнан соң:

— Әти, әллә атны ашарга кушабызмы?.. Ял астында тире кипкән, — дигәч, Насыйр салмак кына тавыш белән:

— Аз гына тора төшсен әле. Көн бөркү чакта, байтак җир килер. Капыл гына яшь үләнгә җибәрмиң, иң элек аз гына коры печән ашатып алырбыз, — дип җавап бирде.

Этисенең шул сүзеннән соң Әхмәт, шундагы чирәмлектән җиләк эзләп, агачлар буйлап алга китте. Аның артыннан Актырнак та ияреп, агач тирәсендә искәнеп йөри торгач, әллә кайда кереп югалды.

Менә бервакыт агачлар арасыннан атылган ук кебек бернәрсә килеп чыкты да икенче якка карап чапты. Аның артыннан Актырнак атылып чыгып, бернәрсәгә дә карамый, куянны куып китте.

Бу нәрсәнең капыл гына килеп чыгуыннан Әхмәт башта сискәнеп китсә дә, аның куян икәнен белгәч, аларның артларыннан карап калды.

Актырнак, куян артыннан китеп, бераз югалып торганнан соң, кире кайтты. Күрәсең, куян юлын ялгыштыргандыр да, шуның өчен Актырнак аны тота алмагандыр...

Әхмәт арба янына кайтканда, әтисе атны ашарга кушкан, зур гына агачларны утка салып, ут ягып җибәргән иде инде.

Ут яктысында чәй әйберләрен җыеп, арбага куйганнан соң, Насыйр:

— Балам, син ят инде. Иртәгә иртәрәк китәрбез,— дигәч, Әхмәт, астына печән салып, аның өстенә чыпта җәйде дә, бишмәтен ябынып, аякларын чишенми генә, йокларга ятты. Ул йокларга ятканда, Актырнак күзләрен ялтыратып, арба астында карап ята, ат шырт-шырт иттереп печән ашый, тирә-яктагы агачлар арасында төрле кошлар чыркылдашып сайрыйлар иде. Әхмәт шул кошларның сайрауларын тыңлап, күктәге җем-җем итеп ялтырашкан йолдызларны карап ята торгач, үзенең тәмле йокыга киткәнен дә белми калды. Төнлә белән Актырнакның әллә нәрсәләрдән шикләнеп өзек-өзек өреп куюын да ишетмәде, бызлап килеп, битенә кунган черкиләрнең ашауларын да сизмәде...

КАЛА КҮРЕНӘ БАШЛАДЫ

Әхмәт иртәнчәк әтисенең:

— Тор инде, балам, китәргә кирәк! — дигән тавышына уянды. Ул торганда, ерактан таң сызылып, кояш чыгышы яктырып килә, кошлар сайрыйлар, әтисе арбаны майлап бетереп, атны камытлый, Актырнак арбадан ерак түгел бер җирдә әллә нәрсәнең өнен[1] карап азаплана иде.

Әхмәт өстенә бишмәтен киеп алды да, елгага барып, тиз генә битен юып килде. Ат җигелеп бетеп, китәр вакыт җиткәч, әйбер-кара онытылып калмадымы икән дип, арба тирәсен карап чыктылар да, һәммә әйбер дә алынганын белгәч, арбага утырып, юлга чыгып, калага таба карап киттеләр.

---

[1] Өн — әрлән, тычкан, төлке кебек җанварларның җир астына казып ясаган оялары. *М. Г.*

Елгадан үтеп, арыш басуы аша аркага менгәч, кояш та чыкты. Бу калку аркадан озын-озын нәрсәләре, югары күтәрелеп чыккан зур-зур өйләре әллә кайдан күренеп торган кала яңа гына чыккан кояш нурлары астында ялтырап, матур булып күренә иде.

Насыйр туры атны куа төште дә:

— Балам, әнә кала күренә. Берәр сәгатьтән барып җитәрбез инде,— дип, атны юырттыра башлады.

Кала Әхмәткә, читтән караганда ук, матур һәм бик зур булып күренде. Андагы озын-озын трубалардан чыккан төтеннәрнең, чиркәү, мәчет кебек нәрсәләрнең өсләреннән чыгып югары күтәрелгән манараларның, шул чаклы ерак җирдән аермачык күренеп торган зур-зур йортларның күплегенә карап аптырап китте. Ул хәзер кала ягыннан күзен дә алмый, ул якта булган нәрсәләрне карап бара башлады.

Актырнак, күрәсең, әле һаман каланы күрми торгандыр, чөнки ул һаман, бернәрсә дә булмаган кебек, әле агачлыклар арасына кереп китә, әле аннан чыгып, болар янына килеп, бераз карап бара, әле берәр нәрсәгә карап, яисә искәнеп артта торып кала иде.

Калага якынлашкан саен, баручылар да, аннан болай таба кайтып килүчеләр дә күбәйгәннән күбәйде. Ком сибелгән, ике ягы канау казып ясалган олы юлга барып төшкәннән соң, баручы һәм кайтучыларның саннары тагы да күбәйде.

Барган саен, кала якынлашты. Кала үзе дә, аның тирәсендәге нәрсәләр дә аермачык күренә башладылар.

Әнә, Әхмәтләр китеп барган олы юлдан ерак түгел, сузылып яткан калку бер җирдән авылдагы кечкенә өйләр зурлыгында булган бик күп вагоннар таккан бер зур кара нәрсәнең, көлтә-көлтә төтеннәр сибеп, алга китеп баруы күренде. Ул үзе бик шәп бара, берничә йөз тәгәрмәчнең тәгәрәгән тавышлары гөрелдәп тора. Алдан тартып барган нәрсәсе: „гап-уф, гап-уф...“ дигән тавышлар чыгара иде. Әхмәт, күзен алмый, шул нәрсәгә карый башлады. Менә бервакыт алдан тартып барган кара нәрсәнең нәкъ аркасыннан куе, ап-ак пар чыга башлап, шуның артыннан ук чыккан тавышы яңгырап, тирә-якка таралып китте.

Әхмәт кыш көнендә мәктәптә укыган чагында, укучы балаларга мөгаллим абзалары тимер юлы һәм

ул юлда йөри торган паровоз һәм вагоннар хакында байтак нәрсәләр сөйләгән һәм Әхмәт, аларның рәсемнәрен уку китапларында күреп, анда да ничек йөрүләре турында бераз укыган иде. Шуның өчен Әхмәт, бу нәрсәләрне күрү белән, боларның теге, мәктәптә мөгаллим абзасы сөйләгән һәм үзе уку китапларында күргән паровоз белән вагоннар икәнен, теге калку булып сузылып киткән җирнең тимер юлы булганын аңлады. Тик шул үзе белгән нәрсәне беркетеп куяр өчен, әтисеннән:

— Әти, әнә бик шәпләп китеп барган әйберләр нәрсә ул? — дип сорады.

Насыйр агай:

— Тимер юл дигән нәрсә шул инде. Шуның өстеннән паровоз вагоннар тагып китеп бара; күрәсеңме, нинди шәп бара ул!.. Аның баруына күз чак-чак иярә,— диде һәм үзенең Герман сугышына барганда да, кайтканда да шуңа утырып, атналар буенча баруларын һәм кайтуларын, аның бик шәп чапкан атлардан да шунда ук узып китүен, ялгыз паровозның әллә ничә мең пот йөк, әллә ничә йөзләп кешеләрне бернәрсәгә дә күрми тартып йөрүен сөйләп алып китте.

Шул арада паровоз һәм вагоннар, берничә чакрым җирне үтеп, тау артына кереп югалдылар...

Тимер юлын күргәч, Әхмәт үзенең калада моңарчы бер дә күрмәгән яисә уку китапларында рәсемнәрен генә күргән бик күп яңа нәрсәләр күрәчәген уйлап бик шатланды.

Кала хәзер тагын да якынайды.

Калага якынлашкач, аннан чыгып төрле якка таралган һәм рәттән бер тигез тезелеп киткән баганаларны, аларның башларындагы чынаяк өсте кебек ак нәрсәләр аркылы үтеп сузылган тимер чыбыкларны күргәч, Әхмәт бу нәрсәләрнең дә мәктәптә мөгаллим абзасы сөйләгән, теге, ерак җирдән торып хәбәрләшә һәм сөйләшә торган телеграф, телефон баганалары икәнен исенә төшерде.

Менә каланың нәкъ яныннан агып ята торган зур Идел! Аның аркылы салынган зур күпер!..

Әхмәт бу күпернең озынлыгына, әллә ничә арба янәшә йөрерлек киң һәм матур итеп салынуына гаҗәпкә калды.

Шул арада күпернең югары ягында, баягы паровоз тавышыннан да юан һәм моңлы иттереп сузып-сузып кычкырган тавышны ишетеп, шулай таба карады. Караса, ни күзе белән күрсен: ап-ак буяуга буялган ике катлы, әллә ничә тәрәзәле, өстеннән бик юан бер морҗа чыккан бер нәрсәнең Идел суын шапылдатып, дулкынландырып, яр буйлап китеп барганын күрде.

Әхмәт бу нәрсәнең пароход булуын исенә төшерсә дә, аптыраганнан:

— Әти, йөзеп килгән зур әйбер нәрсә ул? — дип сораганын да сизми калды.

— Ул, балам, пароход. Су өстендә кешеләр йөртеп, йөкләр ташый торган нәрсә ул! — диде әтисе.

Әхмәт бу нәрсәләрне карап бара торгач, Актырнакны бөтенләй онытткан иде. Капыл гына Актырнак исенә килеп төште дә, әллә кайда адашып калмаган булса ярар иде дип, арба тирәсенә карый башлады. Ләкин Актырнак югалмаган, бәлки, телен чыгарып, боларның арбасы белән янәшә генә, күпердән чыгып бара иде. Әхмәт, Актырнакны барлап алганнан соң, күзен тагын теге зур пароходка ташлады. Ул хәзер, ерак җирдән килеп арыган кебек булып, морҗасыннан аз-аз гына төтен чыгарып туктап тора, өске катның әйләнәсендә әллә ничаклы кешеләр әрле-бирле йөриләр иде.

Бервакыт Әхмәтнең күзе күпернең түбән ягына төште, менә ап-ак зур баганалар өстенә челтәрләп ясалган икенче бер күпер. Әхмәт ул күпернең матурлыгына, аның шушындый биек ясалуына, баганаларының аралары бик ерак булып, ул баганаларның юанлыгыннан хәйранга калды. Әхмәт, ул күпергә шаккатып карап барганда, күпернең бер як башыннан баягы кебек бик күп вагоннар таккан паровоз „киттек-киттек!.. киттек-киттек!..“ дигән тәсле тавышлар чыгарып үтеп барганын күргәч, бу күпернең тимер юл күпере икәнен белде.

— Ничек итеп эшләгәннәр икән мондый зур күперне?.. Теге, без мәктәптә укыган чакта, эшчеләр турында сөйләп укыталар иде бит әле, бу күперне дә шулар эшләгәннәрдер инде, — дип уйлады.

Актырнак хәзер, үзенең Әхмәт һәм арба белән ат яныннан аерылып еракка китәргә ярамаганын белгән

кебек, арбаның янынан гына бара һәм Әхмәткә ешеш кына күзен төшереп:

— Калага да җиттек бит, әй! — дигән кебек карапкарап куя иде.

Күперне чыкканнан соң, Насыйр:

— Атны аз гына эчереп алыйк әле. Эчергәч тә йөреп китсәң бер дә зыян булмый, — дип сөйләнәсөйләнә, атның башыннан тотып, су буена алып төшерде дә, аркалыгын бушатып, су эчәргә кушты.

Шул ук эчереп торган җирдә әллә нинди бер авыл кешесенә очрап:

— Итнең поты ничә сум тора? — дип сорап алды.

— Яхшы итләрнең бер поты сигез-тугыз сумнарга барып җитә, — дигән җавапны алганнан соң, атның аркалыгын күтәреп, әкренләп кенә кала урамына кереп киттеләр.

КАЛА УЙЛАГАННАН ДА МАТУР БУЛЫП ЧЫКТЫ

Әле көн яхшы ук иртә булуга карамастан, кала урамында йөрүчеләрнең күплеге Әхмәтнең күзенә бәрелде. Аңа үзләренең аты да, арбалары да бәләкәйләнгән төсле булып күренде. Урамның ике ягыннан тезелеп киткән өйләрнең зурлыкларына карап аптырап калды. Мондагы шаулаулар, әрле-бирле йөргән арбаларның таш җәелгән урамнан тавышланып йөрүләре әтисенең үзенә карап әйткән сүзен дә ишеттермәделәр.

Менә бервакыт карлыгып беткән юан тавыш белән, „кур-рыйк“ дип, каты кычкырып, болар каршысына үзеннән-үзе йөри торган бернәрсә килеп чыкты. Бу нәрсә боларның янынан гына үтеп алга таба китте. Бу үзе йөри торган нәрсәнең өстенә әллә ничаклы ящиклар төялгән, алдына ике кеше утырган иде. Аларның берсе бәләкәй арбаның тәгәрмәче кебек түгәрәк бер нәрсәне әрле-бирле борып бара иде.

Бу нәрсәгә очраганда, Әхмәтләрнең аты, капыл гына бер якка тайпылып, арбаны чак-чак аудармый калдырды. Бу нәрсәдән Актырнак та куркып китте. Ул тиз генә арба астына кереп качты да, теге нәрсәнең артыннан карап калды.

Әхмәт бу нәрсәнең уку китапларында язылган атсыз йөри торган арба (автомобиль) икәнен белде.

Менә тагын озак та үтми икенче бер, шуның кебек үзе йөри торган автомобиль килеп чыкты. Монысы үзе чиксез шәп бара, үзе карап торуга бик матур булып ялтырап тора иде. Бу автомобиль, „ә“ дигәнче килеп, Әхмәтләр яныннан үтеп китте дә, бер урам почмагына борылды.

Бервакыт арттан: „тот-тт!.. то-то-тот“ дигән бер тавыш ишетелүгә, Әхмәт артка әйләнеп карады: аннан ике генә тәгәрмәчле нәрсә өстенә утырган бер кеше, аякларын ике якка салындырып, төрәнке кебек бер нәрсәгә ныклап терәгән, үзе алга бөкрәя төшкән көенчә выжлап килде дә, „ә“ дигәнче болар яныннан үтеп тә китте.

Әхмәт бу машинаның шул чаклы шәп баруына, ике генә тәгәрмәчле булуына карамастан өстендәге кешенең тәгәрәп төшеп калмавына аптырап калды.

Бара-бара Әхмәтнең күзе йортларның ишек башларына һәм кыек асларына куелган эре хәрефле язуларга төште:

N ШӘҺӘРЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ БАСКЫЧ
25 НЧЕ СОВЕТ МӘКТӘБЕ

N ШӘҺӘРЕНЕҢ ИКЕНЧЕ БАСКЫЧ
ӨЧЕНЧЕ СОВЕТ МӘКТӘБЕ

N ШӘҺӘРЕНЕҢ ҮЗӘК КӨТЕПХАНӘСЕ

ҖИР ЭШЛӘРЕ МӘКТӘБЕ

дигән язуларны укып, кала җирендә төрле мәктәпләрнең күплегенә, аларның зурлыкларына кызыгып, „харап икән монда!“ дип гаҗәпләнде.

Болардан башка тагын шундый эре хәрефләр белән язылган бик күп вывескаларны күрсә дә, кайберәүләренең мәгънәләренә дә төшенә алмады.

Ул, барган саен, үзе моңарчы күрмәгән бер кызык нәрсә күрә, үзе төшенмәгән әйберләргә очрый, шуларга кызыгып исе китеп карап барганга күрә, күпме җир, ничә урам үткәнен дә белми иде.

Актырнак, калага кергән чагында курка төшеп, беразга чаклы арба яныннан гына килсә дә, бара-бара

өйрәнеп китте. Курка-куркарак булса да, урамның читенә чыгып, ачык торган капкалардан, ишек алларына карап-карап китә башлады.

Шулай бераз барганнан соң, зур бер өйнең капкасы төбендә бик зур бер этнең карап торганын күреп, йөрәге калтырап китте. Зур гәүдәле бу этнең башына йөгән кебек әйбер кидерелгән, муенына тәңкә кебек ялтырап торган бер нәрсә тагылган иде.

Бу зур эт, Актырнакны күрү белән, бер-ике сикерүдә Актырнак янына килеп тә җитте. Актырнак куркуыннан баскан урынында катып калды. Теге эт, артык дошманлык күрсәтми, Актырнак белән исәнләшкән кебек, борынын искәде дә, артык тукталып та тормый, кире китте.

Актырнак бу этнең үзен болай яхшы каршы алуына шатланды һәм:

— Каланың этләре дә рәт беләләр икән... Күрәсең, нинди яхшылап исәнләште дә кире китте. Авылда булса, килү белән, ырылдап, өскә менеп таларга керешер иде әле. Мондагы этләргә, авыл җирендәге атларга кидергән йөгән кебек, йөгән кидерәләр икән. Үзенең муенына нинди матур тәңкә такканнар, — дип гаҗәпләнде. Шуның артыннан ук кичә теге авылда үзенең башыннан үткән күңелсез эшкә очравы, анда дистәләгән этләрдән талануы һәм үзенең чак-чак имгәнми калуы исенә төште.

Актырнак Әхмәт кебек зур йортларга да, әрлебирле үтеп киткән автомобиль, мотоциклет кебек нәрсәләргә дә артык гаҗәпсенмәде. Ул, бигрәк тә капка төпләреннән үтеп киткәндә, алардан чыккан май исләренә кызыкты.

— Бу йортларның ишек алларында сөяк-санаклар бик күптер. Әллә шунда кереп, бераз гына булса да, тамак ялгап, сыйланып чыгасымы икән, — диган уйга төшсә дә, үзенең адашып, Әхмәтләрдән аерылып калуыннан куркып, бу уеннан кайтты.

Берничә озын урамнарны үтеп, базарга барып җиткәнче, ул тагын башларына йөгән кидерелгән, төрле төстәге, төрле гәүдәдәге этләргә очрашып, исәнләшеп киткән кебек искәшеп китте. Хәзер ул этләргә очрашудан курыкмый искәнеп йөри башлады. Дөнья күреп өйрәнгән кала этләренең үзен талап ташламауларына

ышанды. Тик менә базарга җитәр чагында гына очраган бер кечкенә этнең усаллыгына аптырады. Үзенең өендә калган балаларыннан аз гына зуррак булган бу бәләкәй этне исәпкә дә алмый үтеп барган чагында, ул нәрсә, өрмичә генә, Актырнакның сырт ягыннан тешләп алды. Шундый бәләкәй башы белән бу чаклы усаллык эшләвенә Актырнакның да ачуы кабарды. Үзен җилкәсеннән эләктереп алды да, әйләндереп торып җиргә бәрде дә, сиңа шул да җитәр дигән кебек, алга китте.

КАЛАНЫҢ БАЗАРЫ ШУШЫ ИКӘН!

Авыл җирендәге кооператив лавкаларын, бер җирдә өелеп кенә торган кечкенә базарны күреп өйрәнгән Әхмәткә каланың базары, базар тирәсендәге зур-зур магазиннар, аларның тәрәзәләреннән күренеп торган төрле төстәге товарлар гаҗәп төсле күп, матур, зур булып күренделәр. Ул мондагы кешеләрнең адашмый йөрүләренә, бер-берсенә бәрелешеп уңайсызлыкка төшмәүләренә аптырады.

Алар, базар эченә кереп, төрле якка борылып байтак җир барганнан соң, кечкенә-кечкенә ит кибетләре тезелгән җирдән ерак түгел бер урынга барып туктадылар.

Болар туктаган җирдә ит, май, тире-яры кебек нәрсәләр сатарга килгән авыл кешеләренең исәбе дә юк иде.

Насыйр, килеп туктагач та, атны тугарып, арбаның тәртәләрен бер-берсенә тартып бәйләп, югары күтәрде дә, атны бәйләп куйганнан соң, йөкнең өстен ачты.

Әхмәт, арбадан төшеп, күп утырып килү сәбәпле оеп киткән аякларын әрле-бирле басып алганнан соң, тирә-ягына карап алды. Актырнак, кала базарына килеп җитүен белдергән кебек, Әхмәткә сөйкәлеп, „кала дигәннәре шушы икән инде!“ дигән кебек койрыгын селкеп, арба астына кереп китте.

Шулай рәтләнеп, алай-болай итеп тә өлгермәделәр, берничә кеше боларның арбалары янына килеп, ит һәм тире белән майны сатулашырга да керештеләр.

Насыйр үзенең алып килгән нәрсәләренә бер төрле хак сорагач, алар:

— Абзый, тиешсез хак сорыйсың, алай булмый...

— Я, сез үзегезнекен әйтегез!..

— Тияреи сора, тиярен...

— Менә тияре шул! — дип, Насыйр агай белән кул сугышып сатулашырга керештеләр.

Насыйр үзе сораган хактан күп төшми тартыша башлады. Ул алучылар янына тагын берничә алучы килеп кушылды. Алар да:

— Кара әле, абзый, сиңа шул хак. Бирәсең икән, бир. Аннан да артык хакны базар күтәрми! — дип китә башлаган булдылар.

Шулай төрле алучылар белән сатулаша торгач, тиренең бәясенә килештеләр. Тире җыючы, акча түләп, тирене сөйрәтеп алып китте.

Бераздан соң ит белән май да сатылды.

Хәзер инде өйдә чакта хисаплары язылган әйберләрне йөреп аласы гына калды.

Насыйр агай әйбер саткан акчаларын арба өстенә куеп, Әхмәт белән бергәләшеп исәпләп караганнан соң, бик әйбәтләп кесәсенә салып куйды. Шуннан соң туры атның алдына печән салып ашарга кушты да, бик тиз генә барып, Әхмәткә бик яхшы пешкән ап-ак калач китереп бирде дә:

— Балам, син арбага менеп утыр да, шушы калачны ашап ал. Арбадан төшеп йөрмә. Атны чишеп алып китә күрмәсеннәр. Мин кызыл товарлар алып килим. Соңыннан сиңа итек алырбыз да, складка барып сабан карарбыз! — дип, әйберләр алырга китте. Әхмәт, арбага утырып, бик тәмләп торып, кала күмәчен ашарга кереште. Ул, бер яктан, тәмләп-тәмләп калач ашый, икенче яктан, тирә-якны карап, каланың кызыклыгына, кешеләрнең күплегенә хәйран булып утыра иде.

Сату-алу белән булышып йөргән Насыйр да, аларны карап торган Әхмәт тә Актырнакны онытканнар иде. Тик әтисе китеп бераз торганнан соң, Әхмәтнең исенә Актырнак килеп төште. Ул арба артыннан караса да, Актырнак анда юк иде инде. Әхмәт: „Актырнак кайда китте икән? Әтигә ияреп киткәндер инде ул“, дип уйлады да тагын да калач ашый башлады.

АКТЫРНАК ЙӨРЕРГӘ КИТТЕ

Актырнакның төрле исләрне сизә торган борыны базар тулган ит һәм май исләрен бик тиз сизде. Аның бик вак нәрсәләрне дә күрә торган күзләре мондагы ашамлык нәрсәләрен шунда ук күреп алды. Ул, арба килеп туктап, ат тугарылып бетеп, Насыйр белән алучылар арасында сатулашу башлангач та, арбалар арасыннан ашарлык нәрсәләр эзләп, иснәнеп йөри торгач, ваклап ит сатучылар рәтенә барып чыкканын сизми дә калды.

Ул кала базарындагы итләрнең күплегенә, мондагы байлыкка аптырап калды. Ит сатучыларның берсе тарафыннан ашарга яраксыз булганы өчен ыргытылган канлы бер ит кисәге аның алдына ук килеп төште. Актырнак шул секундта бу ит кисәген кабып йотып та җибәрде. Аның артыннан шунда чәчрәп төшкән кечкенә бер сөякне туры китереп ялады. Аннан китеп, икенче бер урында эчәгесымак бернәрсә табып ашап алды. Шулар белән аның тамагы ялганып, күңеле күтәрелеп китте. Насыйр белән Әхмәтне исеннән чыгарып, шушы тирәдә йөри башлады.

Монда Актырнактан башка да берничә этләр булып, алар да шулай ит базары арасында йөриләр, ташланган кисәкләрне табып ашыйлар, кайвакытта үзара талашып та китәләр иде. Актырнак өчен мондагы тормыш бик җанлы һәм кызыклы булып күренде. Болай вактөяк ызгышып талашулар кирәкле бер эш кебек күренеп, үзе дә шулар рәтенә кереп китте.

Әхмәт Актырнакны уйлап, калач ашап утырганда, ул инде күптән үзе кала эте булуны, монда күчеп килүне уйлап, итчеләр арасында йөри иде...

АКТЫРНАКНЫҢ ЭЛӘКТЕРДЕЛӘР

Актырнак, шундый уйлар уйлап, итченең ит чапканын карап торганда, ничектер шул тирәдә торган кайбер этләр тирә-якларына карандылар да, бер якка карап, чабып чыгып та киттеләр. Актырнак аларның болай ашыгыч рәвештә качып китүләренә әһәмият бирмәде: „Аларның анда башка эшләре булгандыр да, шуның артыннан киткәннәрдер. Алар киткәч, монда бер үземә генә бигрәк тә шәп булыр. Алар анда йөреп

килгәнче, сыйланып калырмын“, дип, ит чабучының алдында иткә күзләрен текте.

Актырнак шулай гамьсез генә карап торганда, арт яктан аның өстенә авыр бер нәрсә килеп төште дә, „ә“ дигәнче, аның муеныннан буып алды. Һичбер көтмәгән вакытта булган бу эштән Актырнак, куркып, бер якка сикереп китмәкче булган иде дә, ләкин китә алмады. Ул үзенең ихтыярыннан башка чалкан әйләнеп төште дә җирдән сөйрәлә башлады. Тагын тиз генә аягына басып, үзен буып алган нәрсәдән ычкынмакчы булып, аякларын алга терәп, артка тартылып караса да, үзен тарткан көчкә каршы тора алмады.

Актырнак шунда гына үзенең бугазына аркан төшкәнен, ул арканның икенче як башыннан зур гәүдәле, сәләмә киемле, кап-кара битле бер кешенең үзен алга таба тартып барганын күрде. Актырнак, эшнең бу дәрәҗәгә җиткәнен күргәч, куркуыннан үрле-кырлы сикерүенә, ямьсез тавышлар чыгарып кычкыруына карамастан, аны алга табан сөйрәп алып китте. Актырнак, артык каушавыннан, шул тирәдә карап торган кешеләрнең:

— Элегрәк кача белмәдең шул, хәзер эләктең инде, мескен! — дигән сүзләрен дә ишетмәде.

Теге кеше Актырнакны, ай-ваена куймый, сөйрәтеп алып бара, Актырнак, аякларын терәп, алга бармас өчен тартыша, җиргә ятып сөйрәлеп карый, һаман да бер эш тә булдыра алмый иде. Бара торгач, бугазыннан буып алган бауның кысуыннан хәлсезләнеп гыжлый башлады. Күзләрен кан басты. Тирә-ягындагы нәрсәләр чуарланып, туктаусыз дыр-дыр селкенгән кебек күренделәр. Йөрәге калтырап, күз аллары караңгылана башлагач, бөтен көчен җыеп, алгарак сикерде дә, үзен тартып алып барган бауны тешләп алып, башын әрлебирле чайкап, бауны өзгәләргә кереште. Ләкин аның бу рәвешле тартышуы үзе өчен зарар гына булып чыкты. Чөнки Актырнакны сөйрәп алып барган кеше, бауны бик капыл гына тартып кую белән, бау ычкынып, аның бер-ике тешен сындырып чыгарды. Тешләре сынып чыгу аркасында, Актырнакның авызы кан белән тулып, авызыннан җиргә агып төште. Ул, канга батып тартышуына карамастан, ычкына алмавын күргәч, йөрәге әчеләнеп, ялынып елагансымак кызганыч тавышлар чыгара башлады. Шундый авыр һәм кызганыч хәлдә

байтак сөйрәлеп барганнан соң, теге кеше бер җиргә барып туктады. Актырнак, бу нинди урын икән дип, тирә-ягына күз салу белән нәкъ үзенең каршысында торган арбага күзе төште.

Аның алдында балалар бармагы юанлыгындагы тимер чыбыклар белән челтәрләнеп ясалган читлек куелган бик зур бер арба тора. Арба өстендәге ул зур читлек эчендә әллә ничаклы эреле-ваклы этләр үзләренең тоткынлыкка төшү кайгысыннан буталышалар иде.

Бу этләрнең кайберләре иркен тормыштан кысынкылы тормышка эләгүләренә кайгыларыннан шыңшыйлар, кайберләре, ачуларыннан тимер рәшәткәне тишеп ватып, бу тарлыктан чыгып качу юлын эзлиләр, кайсы берсе, арбаның тирә-ягыннан карап торучы кешеләргә „безне коткарыгыз әле!..“ дигән кебек, ялынып, ярдәм өмет иткән кебек карыйлар иде.

Актырнак үзенең каршында әллә ничаклы этләр тутырылган читлекле арбаны күргәч, куркуы тагын да артты. Авызы канап бетүгә карамастан, бауны тешләп тарткаларга кереште. Әрле-бирле чәбәләнеп, бауны өзеп качарга тырышты. Ләкин булдыра алмады, көчле тимер кыскыч белән аның муеныннан эләктереп алып, теге этләр арасына ыргыттылар.

Тимер читлек эченә кертелгәч тә, ул, ачуыннан туктала алмый, йөрәк ярсуы белән бутала башлады. Шулай итеп, үзенең бу кысынкы тормыштан риза түгел икәнен, авылда үзенең имчәк балалары калганын белдерергә тырышкан кебек, сузып-сузып елаган тавышлар чыгарды. Көтелмәгән бу бәлагә төшүен уйлап, йөрәге әрнеде һәм, качарга юл эзләп, читлекнең төрле почмакларын әйләнеп чыкты.

Аның бу тырышулары һәммәсе дә файдасыз иде. Хәтта Актырнактан бер-ике сәгать элек ябылган этләр дә аның бу борчылуына, кулдан килмәс эшне уйлап азаплануына карап гаҗәпләнеп тордылар.

Ул шулай байтак вакытлар үзен-үзе белми чәбәләнгәннән соң, йөрәк ярсуы бераз басыла төште. Тыныч кына торган этләргә карап: „Әллә мин юкка гына борчыламмы икән? Менә бит бу этләр, минем кебек, тарлыкка төшкән булсалар да, үзләрен тыныч тоталар, берәр нәрсә белә торганнардыр, шушы арба белән берәр җиргә алып барганнан соң, һәммәбезне дә ирекә җибәрерләр әле...“ дип, үзен-үзе юата башлады.

Авызыннан аккан каннарны теле белән ялап, авыз тирәләрен тазартып алды.

Бара торгач, „әле дә ярый теге усал кеше асып үтермәде әле; асар дип курыккан идем“, дигән уйга төшеп, хәсрәтен шатлыкка таба борды.

Әле күптән түгел генә кечкенә бер ташландык ит кисәге өчен зык кубып, бер-берсе белән талашып йөргән этләр, монда кергәч юашланганнар, талашу дигән нәрсәне онытып, бер-берсе белән дуслашып киткәннәр иде.

Актырнакның ачуы басылып, йөрәк ярсуы бетеп, бераз торганнан соң, тагын да бер зур этне сөйрәп китерделәр. Бу зур сары эт, ике кешенең бердән тартып хәлен бетереп буарга тырышуларына карамастан, алар белән тартыша, сөйрәүчеләрнең өсләренә ташланырга тели, теге бауны тешләп әрле-бирле селки иде. Аның муеныннан тимер кыскыч белән буып алып, читлек эченә ташлый алмый аптырап беттеләр.

Ул этнең бу чаклы көчлелеген, батырларча каршылык күрсәтүен карап торган этләр, бер яктан, гаҗәпсенделәр, икенче яктан, „юкка каршы торып үзен-үзе имгәтә, барыбер ычкына алмый бит, мескен“, дип кызгана башладылар.

Бик озак азапланганнан соң, ул этне дә Актырнаклар арасына күтәреп бәрделәр. Ул эт, читлеккә бикләнгәч тә, бик күпкә чаклы тынычлана алмый йөдәде. Аның бу чаклы борчылып тавышлануыннан, башка этләр дә ялыгып беттеләр.

АЛАРНЫ КАЙДАДЫР АЛЫП КИТТЕЛӘР

Бервакыт этләр тутырылган читлекле арбаның кузгалуына бу этләр чайкалып бер якка авышып киттеләр. Арбага утырып йөрергә өйрәнмәгән этләргә бу эш бик сәер генә булып калды. Алар бер-берсенә карашып, аптырашкан кебек булдылар.

Актырнакның янәшәсендәге зур гына, карап торуга акыллы гына булган бер эт бара иде. Ул эт, бераз баргач та, Актырнакка карап торды да:

— Безне болай кайда алып баралар икән? — дип сорады.

Бу вакытта Актырнак Әхмәтләрдән аерылуын һәм өйдә торып калган балаларын уйлап бара иде. Теге этнең соравына каршы:

— Белмим шул. Мин үзем калага бүген иртә белән генә килгән идем, шуның өчен мондагы эшләргә төшенеп җитә алмадым... Әллә син кайда алып баруларын беләсеңдер? — диде.

— Син авылдан икәнсең! Белмәсәң дә гаҗәп түгел шул. Менә мин үзем калада торып та, безне ни өчен тотканлыкларын һәм кайда алып баруларын белмим. Үткән көннәрдә безнең күрше эте дә китеп югалган иде. Күрәсең, ул да шундый бер эшкә очрагандыр... Әле һаман кайтканы юк.

Актырнак югалу, кайтмау хәбәрен ишетеп кайгырып куйды һәм:

— Шулай ук безне тиз генә ычкындырмаслар микәнни? Ул вакытта минем өчен бик кыен була инде.

Теге эт бераз уйлап торганнан соң:

— Белеп булмый инде. Ерак җиргә озатсалар, тиз генә кайтып та булмас шул, — диде дә, Актырнакның артык тынычсызлануына күзен төшереп алганнан соң:

— Нигә соң син алай артык борчыласың? — дигән сорауны бирде.

Актырнак көрсенеп алды һәм кайгылы бер тавыш белән:

— Мин бит каладан ике көн эчендә урап кайтырмын дип киткән идем. Әгәр дә тиз кайтып булмаса, анда калган кечкенә балаларым өчен бик авыр була инде! Менә мин шулар өчен бик борчылам, — дигән җавапны бирде.

Теге эт Актырнакның бу сүзеннән соң уңайсызланган кебек булды һәм аны кызганып:

— Синең дә эш авыр икән шул. Яшь балаларың булгач, алай ташлап китәргә кирәк түгел иде.

— Бу эшкә очрауны белгән булсам, китмәгән булыр идем, — диде Актырнак.

— Балаларыңны имчәк ташлаткан идеңме соң?

— Ташлап ук җитмәгәннәр иде әле. Шулай да соңгы көннәрдә имезүне сирәгәйткән идем инде. Үзләре дә юынтык суларын эчәргә, вак-төяк сөякләрне кимерергә өйрәнә башлаганнар иде инде.

— Яшьрәкләр икән шул әле. Шулай булса да, алар үз көннәрен үзләре күрә башларлар әле.

Актырнак тагын да уфлап:

— Әллә үз көннәрен үзләре күреп китәрләр дә бит... Шулай да, кайта алмасам, балаларым бик кыз-

ганыч калалар инде. Әле алар кемнең дус, кемнең дошман икәнен дә аерып бирерлек бер хәлгә килмәгәннәр бит. Шуның өчен аларны карап, күзәтеп кенә тормасаң, әллә нинди авырлыкларга төшеп, имгәнеп, зәгыйфь булып калулары бар.

Беркөн шулай үзем келәт янында карап ятам. Алар бер-берсе белән көрмәкләшеп уйнап йөриләр. Шунда Муйнак дигән бер балам, шул җирдән үтеп барган Мияубикә белән уйнарга теләп, аның каршысына барган иде, теге явыз нәрсә, йоннарын төрпәйтеп, күзләрен акайтып, тешләрен ыржайтып, балаларның өстенә ташланып, башын тырнап та алды. Ярый әле аның тырнагы баламның күзенә эләкмәде. Әгәр дә күзенә эләксә, бер күзе зәгыйфь булып калачак иде. Үзем тизрәк барып, Мияубикәне куып җибәрмәгән булсам, күзен дә тырнап алган булыр иде. Ярый әле, үзем шунда булып, күреп калдым...

Актырнак тагы да:

— Аннан соң беркөн шулай...— дип, нәрсәдер сөйләмәкче булган иде, боларны алып барган арба капыл гына туктап калганлыктан, башлаган сүзеннән туктады. Арба капыл гына тукталганлыктан, этләр бер-берсенә бәрелешеп куйдылар һәм шатлана төшеп:

— Нәрсә булды икән?

— Әллә безне бу тимер читлек эченнән чыгарып җибәрерләрме икән?—дип, тирә-якларына карана башладылар. Ул арада этләр тотып йөрүчеләрнең берсе, озын бауны артына яшереп, җайлап кына барды да, канау буенда йөргән кечкенә бер этнең өстенә ыргытып, бугазыннан эләктереп тә алды. Теге кечкенә эт, кызу көл өстенә төшкән таракан кебек чәбәләнеп, нәзек кенә тавыш белән шыңшып караса да, булдыра алмады, ике минут эчендә читлектәге тоткын этләр арасына китерелеп ташланды.

Әле генә иркендә йөргән кечкенә этнең көтмәгән вакытта шундый авырлыкка төшкәнен күргән зур этләр аны кызгандылар. Теге эт тотып йөрүчеләргә ачулы күз белән карап, кызганыч тавышлар чыгарып куйдылар.

Арба акрын гына кузгалып, тагын да алга китте.

Актырнак белән янәшә барган эт:

— Менә бу мескен бер дә гаепсез көенчә эләкте. Аның әле кешеләргә һичбер усаллыгы тигәне юктыр,— дип сүз башлады.

Актырнак бераз уйлап торганнан соң:

— Шул мескенне күргәч, тагы да балаларым исемә төште. Ул бит безнең авыр хәлдә килгәнне күргәч тә качарга кирәк иде. Ә ул үзенең аңсызлыгы аркасында карап тик тора. Балаларымның да шундый хәлгә төшүләреннән куркам,— дип, яңа гына тотылган кечкенә эткә карап уйга китте.

Теге эт тагын сүз башлады:

— Шулай инде... Балаларны үсеп, үз көннәрен үзләре күрә башлаганчы карап үстергән яхшы.

— Бик дөрес!.. Мин үзем авылда чагымда, аларны ташлап, авылның икенче очына да барганым юк иде. Ни өчендер шушы кала дигән җирне күрәсем килеп, аларны калдырып киттем... Исән-сау гына торсалар ярар иде!..

— Ә соң хуҗаларың нинди кешеләр? Бик каты күңелле түгелләрме?

Актырнак күңелсез рәвештә генә:

— Нәрсә дип әйтергә инде? Алай усал дип үк әйтерлек түгелләр. Шунда да хуҗа хуҗалыгын итә инде. Кайвакытта ачуланган чаклары да була. Кайбердә иркәләп тә куялар. Бу көнгә чаклы балаларыма рәнҗеп караганнарын, кагып-сугуларын күрмәдем. „Үзе юкның күзе юк“ дигән кебек, үзем булмагач, әллә җәберләп тә куярлар, белеп булмый инде...

— Алай ару кешеләр булгач, үзең кайтканчы балаларыңны карап, туйдырып торырлар әле. Алар, синең кайтмаганыңны күргәч, бәләкәй балаларыңны бигрәк тә кызганырлар.

— Үзем дә шулай итәрләр әле дип уйлыйм. Анда минем балаларымны бик ярата торган үзләренең дә бер кечкенә малайлары бар. Ул малай бик ягымлы бала!.. Мин бар вакытта да ул балаларымны кулына алып сөя, аркаларын сыйпап уйната торган иде. Шуның өстенә, көн саен дип әйтерлек, кечкенә ялгаш (тагарак)ка сөт салып, аларны сыйлап, үзе шуннан китми көлеп карап утыра иде. Ул малайны да (Әхмәтне әйтә) калада безне тоткан кебек тотып алып, шулай бер җиргә алып китеп, әрәм итеп ташламасалар, кайту белән балаларымны карый башлар дип уйлыйм. Алар гына тизрәк кайтып җитә күрсеннәр иде инде!

Бу вакытта Актырнакның күзләреннән мөлдерәп яшь ага иде.

Бераз барганнан соң, юл тигезсезрәк булып, арба әрле-бирле чайкалып бара башлады. Этләр бер-берсенә бәрелешеп селкенеп куйдылар.

Актырнак белән сөйләшеп бара торган эт, тирәягына карап алды да:

— Болар безне һаман алып баралар бит әле. Хәзер каладан чыгарга да якынлаштык инде. Күптән түгел үземнең хуҗам белән, шушы урманнан барып, кырга чыккан идем. Ахры болар безне кырга алып барып ташларга уйлый торганнардыр! — диде.

„Кырга алып барып ташлый торганнардыр“, дигән сүзне ишеткәч, Актырнакның күңеленә җылы кереп китте:

— Шулай итсәләр ни әйттең иде! Калага әйләнеп тә карамый, авылга карап чабар идем. Төн буе йөреп, арып-талып булса да кайтып җитеп, балаларым янында тынычлап йоклар идем, — дип куйды һәм аның йөзе ачылып китте.

— Шулай булмаганда, ни өчен безне каладан читкә алып чыгарлар икән?

Актырнакның сердәше шул сүзен әйткәндә, эт тотучыларның кучерда утырып барганнан башка икәвесе кайдадыр кереп киттеләр. Аларның киткәннәрен күргәч, теге эт үзенең сүзе дөрескә чыгуына тагын да ышана төште дә, Актырнакка карап:

— Күрдеңме? Әнә теге безне тотып ябучы усал нәрсәләр бөтенләй безне ташлап киттеләр. Кучерда баручысы аның бер нәрсә түгел. Аның, базарда безне тотып монда япканда, һичбер катнашы булмады. Шулай булгач, безне кырга алып барып ташлавында шик тә юк инде...

Боларның сүзләрен тыңлап, читлеккә кергәннән бирле моңаеп барган бер ала эт боларга карап:

— Ай-һай!.. Безне кырга чыгарып ташлар өчен генә тотып, боярлар кебек итеп алып килерләрме икән?!. Мин шулай безнең кебек тотылган этләр турысында хәбәрләр ишеткән идем, безнең башка да шул куркынычлар килмәсә ярар иде... Мин шуннан куркам! — диде.

Ала этнең шундый шомлы сүзен ишеткәннән соң, Актырнак та, аның белән сөйләшеп барган эт тә, өсләренә кайнар су сипкән кебек булып, калтыранып куйдылар. Алар гына түгел, читлектәге башка этләр дә

бу эткә карап аптыраштa калдылар һәм берничәсе бердән:

— Безне анда нинди куркынычлар көтә! Әллә бүреләр, аюларга каршы алып баралармы? — дип сораганнарын сизми дә калдылар. Шунлыктан читлек эче кайгылы тавышлар белән тулды. Боларның шыңшыган кызганыч тавышлары бөтен урамга таралып, үткән-барганнар тукталып, боларга карый башладылар.

Актырнак һичбер сүзсез-нисез, теге этнең авызына карап, аның җавап биргәнен көтә башлады.

Теге ала эт артык ашыкмый гына:

— Бүреләр, аюлар тора торган урманнарга алып барып ташласалар, куркыныч дип әйтмәс идем. Минем ишетүемә караганда, алай гына түгел. Алай гына була торган булса иде, безнең кайберәүләребез аларның үткен тырнаклары, көчле тешләре астында үлсәләр дә, кайсыберебез котылып, исән калыр иде.

Аның бу сүзе этләргә яшен суккан кебек булып бәрелде. Бәләкәйрәк этләр куркуларыннан дер-дер калтырана башладылар. Бу куркыныч хәлләрне ишеткәннән соң, зур этләрнең күбесе катып калдылар. Тик теге, Актырнак белән сөйләшеп килгән эт белән икенче бер эт кенә тынычлык саклый алып, ала эткә карап:

— Бүреләргә очрашудан да куркыныч эш нинди эш булырга кирәк?.. Арслан, каплан дигән иң усал дошманнар булсалар да, алар безнең бу тирәдәге урманнарда юк, диләр бит!..

— Нинди куркыныч?.. Белсәң тизрәк әйт! — дип сорадылар.

Ала эт, тирә-ягына каранып алганнан соң:

— Анда безне бүре дә, аю да, арслан белән каплан да көтми, башка бернәрсә көтә,— диде. Шуннан соң берничә эт бердән:

— Нәрсә көтә?!.

— Ул чаклы аю, бүре, арсланнан да куркыныч булган нәрсә — кем соң ул? — дип сорадылар.

Төрле яктан кызганыч тавыш белән ашыгып соралган бу сорауларга ала эт, ничек итеп җавап бирергә белми, аптырап калган кебек, бераз уйланып торды да, бик авыр сулаганнан (уфлап тын алганнан) соң:

— Минем ишетүемә караганда, алда безне үлем көтә! — диде.

Ала этнең бу сүзләреннән соң этләр утырган урыннарында таш кебек катып калдылар,

Тик бераз торганнан соң, берничә эт бер авыздан:

— Үлем көтә?..

— Нинди үлем ул?.. Безне үтереп аларга ни файда килә? — соравын бирделәр дә, артык сүз таба алмый, ала этнең күзенә карадылар. Этләрнең бу чаклы куркып борчылуларын күргәч, ала эт алдагы куркыныч хакында сүз башлавына үзе дә үкенде. Ничек итеп җавап бирергә белми аптырап калды.

Актырнак белән сөйләшеп бара торган эт бик авырлык белән генә:

— Безне үлем көткәнен кайдан белдең соң син? — диде.

Ала эт, үзе дә калтырана төшеп, түбәндәгечә сөйләп китте:

— Моннан бер атна элек безнең күршедән Муйнак исемендәге бер эт югалды. Шул Муйнакның хуҗасы минем хуҗам янына килеп:

— Күрше, минем Муйнак югалды бит әле. Эт җыючылар кулына гына төшмәгән булса ярар иде. Алар кулына эләгә калса, әрәм була инде, — дип әйткәч, минем хуҗа:

— Нигә соң эзләп, артыннан барып алып кайтмадың? — дип сорады. Шул вакытта Муйнакның хуҗасы:

— Үзем өйдә булмадым. Хәзер баруда да файда юк. Алар кулына эләккән булса, икенче көнне үк тиресен тунап алулары билгеле инде. Тик әле икенче берәр кеше ияртеп алып киткәндер, берәр көнне кайтып килер дип уйлыйм, — дип җавап бирде. Менә мин, Муйнак турында булган шул хәбәрне ишеткәннән соң, болар кулына төшкән этләрнең исән калуларына ышанмыйм. Шуның өчен:

— Безне алда үлем көтә! дим.

Ала этнең бу сүзләреннән соң күп этләр үзләренең җаннарыннан өмет өзделәр. Кайберәүләре куркуларыннан улап җибәрделәр.

Актырнак һуштан язарга якынлашты. „Тунау“ дигән сүзне ишетү белән, кичә иртә белән үзенең күз алдында бугазланып, тиресе туналган кызыл сыер күз алдына килде... Шуның өстенә балалары исенә төште дә, кызганыч, ачы тавыш белән елап җибәргәнен сизми дә калды...

Хәзер боларны алып барган арба, шәһәрдән чыгып, бик еракта күренгән такта белән ябылган каралтыларга таба киткән юл белән бара иде.

Болар бераз вакыт сүзсез генә барганнан соң, араларыннан берсе теге ала эткә күзләрен тутырып карады да:

— Син үзең, безне алда үлем көтә, дип, безне чиксез куркуга салдың. Ә соң син үзең, мондый куркыныч барлыгын белгәч, нигә бу эт тотучылардан сакланмадың? — дигән сорауны бирде.

Кайбер этләр моның сүзен дөресләп:

— Чынлап та, шулай шул... Син үзең ничек болар кулына эләктең? — дип сорадылар. Алабай сулап уфлаганнан соң:

— Мин эт тотучыларны аерып танымый идем. Аларның кайда һәм ничек тотуларын да белмәдем. Аннан соң, Муйнак хуҗасының ул вакытта әйткән сүзләрен истән чыгарган идем. Бүген әллә ни эшләп кенә базарга чыктым бит!.. Шунда берәүнең ит чапкан җирендә карап торганда, муеныма элмәк килеп төшкәч кенә, Муйнак башына төшкән нәрсә икәнен аңладым. Менә шуннан соң гына үземне һәм сезне үлем көткәнен белдем, — дип җавап бирде.

Аның бу сүзләреннән соң этләрнең калган өметләре дә югалды. „Хәзер үк бу үлем читлегеннән котылу юлын карарга кирәк...“ дигән уйга төшеп, читлекнең тимер чыбыкларын тешләп кимерергә керештеләр. Кайберәүләре улый, шыңшый башладылар. Ләкин тимер чыбыкларны тешләүдән, тешләрен авырттырудан бүтән файда булмады.

Бара торгач, кайберәүләре тынычланды. Кайберәүләре бөтенләй уйлый алмый катып калдылар. Үзара сөйләшеп бару да бетте.

Актырнак белән сөйләшеп бара торган эт башын күтәреп, Актырнакны кызганып, бераз карап торганнан соң:

— Син ахры артык кайгырасың. Алай ук кайгырма әле. Әллә Алабайның сүзе дөрес булып та чыкмас. Дөрес була калганда да, берәр юл табып, исән калырбыз, — дип, Актырнакны юатырга кереште.

Актырнак аның мондый мәрхәмәтле һәм күңел юата торган сүзләрен тыңлаганнан соң, йөрәгендәге авыр хәсрәт басылгандай булды һәм:

— Аның сүзләре бушка чыгып, үлемнән котылсак, гомерем буена шатланыр идем,— дип, иптәшенә карады да аның сүзен көтә башлады.

Теге эт:

— Мин әле җанымнан өмет өзмим, һәм син дә артык борчылма әле,— дип куйды.

Иркен кыр белән арбада китеп бару этләр өчен кызык төсле күренә башлады. Әкрен генә тирбәлеп барган арбада кайберәүләре йокымсырап, башларын түбән иеп бара башладылар.

Актырнак капыл гына:

— Гомер буена арбага утырып, атта йөргәнем юк иде, болай үзе күңелле генә икән,— дип куйды.

Актырнак белән сөйләшеп бара торган эт аның сүзеннән көлә төшеп:

— Кызык та бит... Шулай да ирекле рәвештә йөрүгә җитми шул. Менә хәзер без ирекле булсак, нинди күңелле булыр иде!.. Теләгән җиребезгә барыр идек. Шушы иркен кырда көрмәкләшеп, чабышып уйнар идек. Теләсәк туп-туры өйгә кайтып китәр идек... Менә шул якларын уйлаганда, арбада баруның кызыклары югала шул,— диде.

Актырнак:

— Кызык дип, аптыраганнан әйтәм. Син әйткәнчә, иркендә йөрүгә җитәме соң! Мин хәзер ирекле булсам, беләсеңме ни эшләр идем?.. Бер минут тормый, авылга карап чабар идем. Анда минем балаларым мине нинди шатланып каршы алырлар иде! Уф, булмас шул! — дигән сүзләрне әйтте. Шул вакытта аның ике күзеннән яшьләре тәгәрәп төште.

Арба тегеерактан күренгән каралтыларның капкасына килеп җитте дә, әкрен генә ишек алдына кереп китте.

Аның ишек алдына керү белән, этләрнең танауларына үлемне күз алдына китерә торган исләр килеп бәрелде. Читлектәге этләр шул минутта ук теге Алабайның: „Безне бүреләрдән дә, арсланнардан да куркыныч нәрсә көтә!.. Үлем көтә!..“ — дигән сүзләренең дөрес булачагын күз алларына китереп, уларга, шыңшырга, курку тавышлары чыгарып өрергә керештеләр. Боларның бу тавышларына, болардан бер көн элек китерелеп, сарайга бикләнгән этләрнең дә тавышлары кушылды.

Арбадагы этләр шул минутта ук үлем көтеп, куркуларыннан нишләргә белми буталышып, бер-берсенә аралашып киттеләр. Арбадагы этләрнең кызганыч тавышларына болардан элек китерелеп, сарайга ябылган этләрнең дә тавышлары кушылды. Аларның тавышларын ишеткәч, арбадагы этләрнең куркулары тагы да артты. Хәзер болар үзләрен бик зур куркыныч көткәнен чынлап аңладылар да, читлеккә тырнашып өрә, бутала һәм әче тавышлар чыгарып шыңшый башладылар.

Озак та үтмәде, бу этләрнең һәммәсе дә үзләреннән элек китерелеп ябылган этләр янына кертелеп бикләнделәр.

Актырнак, сарайга ябылганнан соң, үзенең балаларыннан гомергә аерылганын белде. Ул инде үлем көтеп, өйдә калган балаларын уйлап, иректә йөргән вакытларын күз алдына китереп, кызганыч тавыш белән, көчсез рәвештә шыңшып елый башлады.

ТАГЫ ДА КЫЗЫКЛЫ НӘРСӘЛӘР

Насыйр агай кочагын тутырып, бәйләм-бәйләм товарлар алып кайтканда, Әхмәт ул калдырган калачны туйганчы ашап, күптән бирле этисен көтеп утыра иде инде.

Әхмәт этисенең кулындагы товарларын күреп шатланса да, Актырнакның этисе белән булмавын күргәч, уңайсызланып китте һәм:

— Эти, Актырнак синең белән бармадымы?.. Ул бит монда да күренми,— дип сорады.

Әтисе Әхмәтнең соравына артык әһәмият бирми генә:

— Юк, балам, бармады. Ул әллә кайда китмәс, шунда ит сата торган лавкалар арасында йөри торгандыр,— дип, кочагындагы товарларын арбага куеп, өстен торпыша белән япты да:

— Мин аны анаудагы ит лавкалары тирәсеннән эзләп алып килим әле. Шуннан соң атны җигеп, складка барып сабан алырбыз да, постоялый дворга барып, чәй эчәрбез,— дип, Актырнакны эзләргә китте.

Әхмәт яңа сабан алуны, шәһәрнең күрмәгән җирләрен күреп йөрүне уйлап та бетмәде, әтисе урап килеп:

— Актырнак ул тирәдә дә күренми әле. Әллә авылга кайтып киттеме икән? Эт дигән җанвар адашмый ул. Кайда да булса, берәр җирдә искәнеп йөри торгандыр шунда. Әйдә, балам, атны җигеп, аласы әйберләрне алыйк та, чәй эчәргә керербез,—дип сөйләнә-сөйләнә, ат җигәргә керешге. Атны җигеп, әкрен генә базардан чыгып, урамга төштеләр. Озак та үтми, төрле машиналар белән тулган складка барып керделәр. Болар барып кергәндә, складта, Әхмәт уйлаганча, сабаннар гына түгел, әллә нинди гаҗәп машиналарның исәбе дә юк иде. Әхмәт иген суккыч, җилгәргеч һәм чаба торган машиналарны күргән булса да, монда әле ул күрмәгән зур-зур машиналарны күреп хәйран калды. Бу машиналар арасында Әхмәт белмәгән кешеләр йөриләр, аларны тотып, кайбер җирләрен әйләндереп карыйлар, үзара аларның кайсы яхшы икәне хакында сөйләшәләр иде. Насыйр агай да, аларның яннарына барып, теге машиналарны карап, берничә сүз кыстырганнан соң, үзләре алачак сабаннар тирәсенә килде. Сабан карап йөргән башка кешеләр белән бергә ул да бер сабанны алып карарга керешге. Хәзер Әхмәт тә, арбадан төшеп, йөзләгән сабан арасыннан сайланып алынган сабан янына барды. Ул беренче күрүдә үк этисе караган сабанны яратып:

— Әти, шушы сабанны алыйк. Әхмәт бабайларның сабаннары да нәкъ шуның төсле. Аларның шул сабаннары бик килешә бит,—дип, шушы сабанны яратканын белдерде. Ләкин этисе:

— Балам, ашыкмыйк әле. Кайбер сабан болай өстән карауга чибәр күренсә дә, берәр җире туры килеп җитмәгәнлектән, көйсез булып чыга,—дип, башка сабаннарны алып, төрлечә утыртып, әйләндереп, тикшереп карады. Берничә сабанны шулай бик җентекләп караганнан соң гына, бер сабанны алып:

— Менә, балам, шушы сабан яхшы булырга кирәк, шуны алыйк,—дип, бер як читкәрәк тартып куйды.

Ямь-яшел буяуга буялган бу сабан уйнап торган кебек матур күренә иде. Бу сабанны Әхмәт тә бик яратты. Тагын берничә мәртәбә әйләндереп, винтларын тотып караганнан соң, шул сабанны алмакчы булдылар.

Насыйр агай шунда килгән крестьяннарга төрле машиналар, сабаннар күрсәтеп йөргән бер кешегә үзе-

нең шушы сабанны алырга теләгәнлеген белдерде. Ул кеше, сабанның номерын карап, язу язды да, ул язуны Насыйр агайга биреп, конторага кереп акча түләп чыгарга кушты.

Сабанга акча түләп, арбага салдылар да, складтан чыгып, берничә урам барганнан соң, капка башына „Крестьян йорты" дип язылган бик зур йортка барып керделәр.

Әхмәт үзләренең мондый зур йортка керүләрен бер дә уйламаган иде. Шуның өчен бу зур йорт, андагы төрле бүлмәләр, аларның стеналарына асып куйган төрле буяудагы матур сурәтләр аның өчен бик кызык булып күренде.

Насыйр агай, атны туарып, әйберләрне бер бүлмәгә кертеп урнаштырып, алай-болай бит-кул юганчы, самовар да килеп өлгерде. Алар тиз-тиз генә чәй эчтеләр дә тагын кала арасына чыгып киттеләр.

Иң элек, зур бер магазинга кереп, Әхмәткә итек карадылар. Анда яраклы итек туры килмәгәч, икенче бер магазинга кереп, бик күп караганнан соң, Әхмәткә итек алынды. Шыгырдап торган яңа итек Әхмәтнең кулыннан ычкынып китәр төсле күренгәнгә, ул аларны кулыннан ычкындырмаска теләгән кебек, бик нык кысып тотты. Магазиннан чыгып барганда, артыннан килеп, аның яңа итеген кире алырлар төсле булганга, ашыгып атлый башлады. Аяк киемнәре магазиныннан чыкканнан соң, тәрәзә төпләренә бик күп төрле уенчыклар тезелгән кибетләр яныннан үтеп киттеләр. Әхмәт тәрәзә төбендәге төрле буяуларга буялган уенчыкларга, кечкенә мылтыкларга кызыкса да, барыбер алмаслык булгач, ул хакта әтисенә бер сүз дә әйтмәде.

Тагын бераз баргач, тәрәзәләренең якларына һәм төпләренә төрле исемдәге китаплар тезелгән, төрле төстәге каләмнәр куелган бер кибет турысына җиттеләр. Бу нәрсәләрне күргәч, Әхмәтнең күзе дүрт булды. Ул, кибеткә кереп, каләм, дәфтәр һәм бертөрле булса да китап аласы килеп, кыяр-кыймас кына, әтисенә үзенең теләген белдерде.

Насыйр агай калага беренче рәт кенә килгән баласының теләген кире какмады:

— Әйдә алай булса, тиз генә кереп алып чыгыйк,— дип, китап магазинына керделәр. Кайда барып бәрелергә белмәгән кебек, бераз каранып торганнан соң,

шунда китаплар рәтләп йөргән бер кешенең каршысына барып бастылар. Ул кешенең:

— Агай, сезгә нәрсәләр кирәк иде?—дип соравына каршы, Насыйр агай:

— Менә бу балага каләм, дәфтәр кирәк иде,—дип әйтү белән приказчик берничә төрле каләм һәм төрле дәфтәрләрне боларның алларына китереп куйды.

Әхмәт бу каләм, дәфтәрләрнең кайсыларын алырга белми аптырап калды. Аның аптырап торганын күргәч, приказчик:

— Тукта әле, сиңа бик яхшы каләм белән дәфтәрне үзем сайлап бирим,—дип, каләмне һәм дәфтәрне үзе сайлап бирде. Ул сайлап биргән каләм кебек матур каләмне һәм калын дәфтәрне Әхмәт бу көнгә чаклы күргәне дә юк иде әле. Алар шул каләм белән дәфтәрне алмакчы булдылар.

Приказчикның:

— Я, тагын нәрсә кирәк? Китаплар да кирәктер бит?—дигән сүзе Әхмәтне тагын күңелләндерде. Насыйр агай да:

— Яңарак чыккан берәр төрле кызыклы китап булса бир әле,—дигәч, приказчик, боларның алдына берничә төрле китапларны китереп:

— Менә балалар өчен шушы китаплар бик файдалы,—дип, китапларны да үзе күрсәтә башлады. Әхмәтнең күңеле бу китапларның берсен дә калдырмый алырга теләсә дә, ул эш мөмкин булмаганга күрә, ул боларның арасыннан ике китапны сайлап, үзенең шуларны алырга теләгәнен белдереп, әтисенә:

— Әти, шушы китапларны алыйк әле,—дип әйткәч, әтисе дә риза булды.

Хәзер Әхмәт үзенең кулына кергән нәрсәләрнең күплегеннән шатлана, өйгә кайту белән, буш вакытында бу китапларны укуны уйлый иде.

Китап магазиныннан чыгып, тагын берничә кибеткә кереп, өйдә чакта сөйләнеп, хисаплары чыгарылган нәрсәләрне алганнан соң, баягы „Крестьян йорты“ на кайттылар.

Анда кайтып, атны карап, алай-болай иткәнче, кояш та баеды. Алар бүген алган әйберләрен тагы да берәмләп карап, барлап, хакларын исәпләп чыктылар.

— Караңгы төште инде, нигә лампа яндырмыйлар икән?—дип торганда гына, Әхмәтләр бүлмәсендә гөлт

итеп бернәрсә янып китте дә бөтен бүлмәне яктыртып җибәрде.

Тавык йомыркасыннан аз гына зуррак булган, озынчарак пыяла эчендәге нәзек кенә чыбыкларның яныл, бөтен бүлмәне яктыртып торуы Әхмәткә бик кызык булып күренде. Әгәр дә Әхмәтнең күзе чагылмаса, үзеннән-үзе янган бу нәрсәгә бик озак карап торган булыр иде. Нәкъ шуның кебек бер төсле лампаларның башка җирләрдә дә, хәтта ишек алларында, ат куйган лапасларга чаклы януы Әхмәтне бигрәк тә кызыксындырды. Әгәр дә мәктәптә мөгаллим абзыйсының электрик хакында сөйләгән сүзләре исенә төшмәгән булса, ул үзеннән-үзе яныл киткән бу нәрсәләргә бигрәк тә хәйран калыр һәм боларның чын булуларына да ышанмас иде. Әхмәт бу нәрсәләрнең кызыклыгы турында уйлап та бетермәде, аларның бүлмәсенә каршы булган залда юан тавыш белән бер кеше нәрсәдер сөйләргә кереште. Насыйр агай белән Әхмәт, бу тавышны бераз тыңлап торганнан соң, эчә торган чәйләрен ташлап, юан тавыш белән сөйләгән кешене күрер өчен, каршыдагы зур бүлмәнең ишегеннән барып карадылар. Анда байтак кешеләр, почмакка таба карап, бер сүзсез нәрсәдер тыңлыйлар, ә аларның каршыларында юан тавыш белән сөйләүче кеше үзе бер дә күренми иде. Кеше булмаган җирдән тавыш чыгуына болар аптырап киттеләр дә, тагын да эчкәрәк кереп, теге кешеләрнең яннарына ук бардылар. Теге тавышның почмактагы өстәл өстенә куелган бәләкәйрәк тәлинкә кебек бер нәрсәдән чыгуын күргәч, боларның аптыраулары тагын да артты. Әхмәт, әллә шул өстәлнең астында берәр кеше торып, шул кеше сөйли микән әллә дип уйласа да, аз гына карап тору белән, эшнең алай түгел икәнен аңлады.

Менә бервакыт теге тавыш бетте. Икенче бер тавыш әллә нинди сүзләр әйтеп аз гына торгач та, бик озын көйгә сузып җырлаган җыр тавышы килә башлады. Тыңлап утыручылар:

— Менә нинди гаҗәп эш!..— дип бер-берсенә караштылар. Җыр тавышы бетеп, аз гана торгач та, бик матур музыка тавышы ишетелә башлады. Бу матур тавышка тыңлап утыручылар дәртләнеп, урыннарыннан кузгалып куйдылар. Насыйр агай да, Әхмәт тә, эчә торган чәйләрен онытып, тик шундагы бер кешенең:

„Бүгенге концерт бетте инде“, дип әйткән сүзеннән соң гына, үзләре төшкән бүлмәгә кереп, яңадан чәй эчәргә керештеләр. Аталы-уллы шушы кызык нәрсә турында сөйләшеп йокыга яттылар.

Әхмәт йоклап киткәнче, аның күз алдында бүген иртәдән башлап кичкә чаклы күргән төрле кызыклы нәрсәләр берсе артыннан икенчесе үткән кебек булалар һәм йоклар алдыннан гына ишеткән төрле көйләр колак төбендә генә уйнап торган төсле тоелалар иде...

Иртән торып, шәһәрдән чыгып киткәндә, Әхмәт үзенең бик яраткан нәрсәләрен шушы шәһәрдә калдырган төсле булды. Аның өчен шәһәрдә күренгән төрле нәрсәләр — һәммәсе дә кызык, барысы да матур булып, алардан аерылып китү кыенсымак булып сизелде. Шуның өстенә үзләренә ияреп килгән Актырнакның әллә кайда китеп югалуы аны күңелсезләндерде, һәм ул әтисенә карап:

— Әти, безнең Актырнак мескен кайда китте икән? Авылга кайтып киткән булса ярар иде,— дигән сүзләрне әйтте. Әтисенең салмак кына тавыш белән:

— Ул, бәлки, балаларын исенә төшереп кайтып киткәндер. Эт дигән җанвар һичбер вакытта да адашмый ул! — диде.

Актырнак хакында сүз озакка сузылмады. Алар килгән юллары белән алга киттеләр. Шәһәр, аның янындагы көзге кебек яткан Идел, аның аркылы салынган озын күпер, гөжләп йөргән паровозлар берәм-берәм артка калдылар.

Актырнак болар янында юк иде. Аның шәһәрдә югалып калуы Әхмәтнең эчен пошырса да, ул мескен Актырнакның балаларын сагынып шыңшып елавын ишетми. Аның төрмәдәге тоткыннар кебек эче әрнеп, йөрәге янганлыктан, ни эшләргә белми, әрле-бирле йөрүен күрми иде...

ЯТИМ КӨЧЕКЛӘР

Әхмәтләр калага чыгып киткәннән соң берничә сәгать үткәч тә, Актырнакның балалары әниләрен юксынып: „Ул кайда китәр икән?..“ дип эзләнеп йөри башлаганнар иде инде. Алар башта әниләренә иркә-

ләнеп, аның янында уйнап йөрер өчен юксынсалар да, бара торгач, карыннары ачып, имәселәре килгәнгә күрә эзләргә керештеләр. Әниләрен төрле җирдән эзләп тә таба алмагач, нәзек кенә тавыш белән шыңшый башладылар. Әниләре бар чагында гелән бергә йөргән көчекләр, эзләнеп йөри торгач, төрлесе төрле якка таралдылар. Бер көн эчендә моңарчы күрмәгән кыенлыкларны да күреп алдылар.

Аларның берсе, үзләренә кергән күрше этен, үзенең әнисенә ошатып, аның янына йөгереп барган иде, теге эт „һам!“ иттереп бер якка чөеп ташлады. Икенче берсе, әнисен эзләп йөри торгач, арба астында күшәп яткан кәҗә янына барып, аның корсагыннан ими эзләргә керешкән иде, кәҗә, урыныннан торып, аның өстенә басып, кабыргасын сындыра язды. Өченче берсе, чебиләрен канат астына җыеп утырган тавык янына барып чыгу белән, теге тавык аның өстенә сикереп менеп берничә җиреннән чукып алды. Тагын берсе ташландык сөяк табып, кимерергә теләп азаплана гына башлаган иде, теге күрше эте килеп чыгып, үзен бер якка алып ыргытты да сөяген тартып алып китте.

Шулай итеп, алар әниләре киткән көнне үк ятим балалар кебек ачлык һәм төрле авырлыклар күрә башладылар. Ишек алдындагы тавыктан чукылдылар, кәҗәдән сөзелделәр, күрше этеннән тешләнделәр.

Әхмәтләр урап кайтканчы, Хәсби җиңги чыгарып салган юынтык суларны да рәтләп эчә алмадылар. Чөнки алар тагарак янына килеп җиту белән, берничә дистә тавыклар килеп, боларны чукып җибәрә торган булдылар. Әгәр дә Хәсби җиңги үзе карап, берничә рәт машинадан калган сөтне эчермәгән булса, бу кечкенә көчекләр күптән хәлсезләнеп егылган булырлар иде.

Икенче көн үтте. Менә бервакыт Әхмәтләр кайтып керделәр. Хәсби җиңги йөгереп аларга каршы чыкты. Кечкенә көчекләр, аларның кайтуларын сизеп, төрле яктан килеп арба янына җыелдылар. Әхмәт аларны күрү белән кызганып китте һәм шунда ук әнисеннән:

— Әни, Актырнак монда кайтмадымы?— дип иң элек Актырнакны сорады.

Әнисенең:

— Юк, балам, кайтмады,— дигән сүзе Әхмәтнең йөрәген чымырдатып җибәрде. Ул ашыгып:

— Актырнак югалды бит, әни. Ул калага баргач та, безнең яннан китте дә кире килмәде,— диде дә, кечкенә көчекләрне кызганып, күзе яшьләнде.

Насыйр агай:

— Без аны монда кайткандыр дип уйлаган идек, кайтмаган икән. Күрәсең, адашып берәр якка чыгып киткәндер, —дип, ат туарырга кереште.

Хәсби җиңги дә:

— Бик әйбәт эт иде, куйган нәрсәләргә һичбер вакыт тими торган иде,—дип, югалган Актырнакны кызганып куйды.

Актырнакның балалары, югалган әниләрен эзләгән кебек, арба тирәсендә бераз искәнеп йөрделәр дә шыңшый-шыңшый, төрлесе төрле якка таралдылар.

Әхмәт шунда ук сөт алып чыгып аларга сөт эчерде. Аларның аркаларыннан сыйпады. Алар, „әллә безнең әниебез шушымы икән?“ дигәнсымак, Әхмәткә карап куйдылар һәм, ул өйгә таба китә башлагач, аның артыннан иярен бардылар.

Хәзер Әхмәтләр өендә күңелле генә тормыш башланды. Тик бу күңелле тормышны Актырнак кына күрә алмады. Чөнки бу вакытта Актырнак үтерелеп, аның тиресе башка этләрнең тиреләре белән бергә таш амбарның идәненә кертелеп ташланган иде.

КОРЫГАН АГАЧЛАР

I

ЯҢА КИБЕТ

Вәли, яңа алган магазинына күчкәч, тагын да бер приказчик алды. Эшләре шул дәрәҗәгә житкәч, хәзер ул үзенең чын сәүдәгәрләр рәтенә кергәнен, булдыклы сәүдәгәр исеме алырга хаклы булганын хис итте. Хәзер аның каршында кешеләр ике төрле: берсе — сәүдәгәрләр, икенчесе — сатучы була алмаган „гади кешеләр“ булып күренә башлады.

Ул әле үзе, сума ягыннан караганда, теге мәшһүр байлар кебек булып ук бетмәсә дә, үзен шуларның юлларыннан баручы „акыллы“ бер кеше иттереп уйларга кереште. Аныңча, бөтен акыл байларга гына булып, бай кеше акыллы була, яисә акыллы кеше бай була... дип уйлый, шуның өчен зур байлар аңа чиксез акыллы булып күренгән кебек, эшчеләр, ярлы кешеләр, хезмәткәрләр акылсызлар булып күренәләр иде.

Ул, үзеннән зур байларны үзенә караганда акыллырак, алар гына дөньяда тора беләләр дип уйлаганга күрә, байларның бөтен эшләренә, аларның кыланыш һәм йөреш-торышларына тәкълит итүчән[1] булып китте.

Мәсәлән: Садыйк бай сөйләшкән чагында аның тавышы, калын булып, мөгердәп чыга. Әхмәт, сүз арасында тамак кырып, күркә төсле гырылдап куя, Сабирҗан бай күзләрен бер якка чалышайтып елмая... Вәли әнә аларның шул сыйфатларын акыллы һәм бай булуларыннан килгән аерым бер хасият дип белеп, үзе дә шулар кебек булырга тырыша, Садыйк бай кебек, тавышын юан чыгарырга, Әхмәт бай кебек, сүз арасында тамак кырып куярга маташа иде. Ул шулай

---

[1] Тәкълит итүчән — иярүчән.

тавышын юан чыгарганда, сүз арасында тамагын кырып куйганда, үзе дә шатланып китә, үзен барган саен байлыкка таба барган, акылы арткан бер кеше итеп хис итә иде.

Ул байларның бу эшләренә тәкълит итү белән генә канәгать итми, аларның йөреш-торышларына тәкълит итүне, бөтен эшләрдә алар кебек булуны зур эшләрнең берсе итеп саный башлады. Шуның өчен аның гает намазына киеп бара торган туны, Садыйк байның туны кебек гаҗәп кыйммәтле затлардан тегелгән булмаса да, шуңа охшатып тегелгән, бүреге зурлыкта һәм фасонда Әхмәт байның бүрегенә охшатылып эшләтелгән иде.

Ул, шушы туны белән бүреген киеп, җомга һәм гаетләргә барганда, үзен бик шат хис итә, теге байларның кечкенәрәк бер үрнәкләре дип уйлый һәм алар утырган сафларга якынрак утыруга үзен камил хаклы саный иде.

Ул, байларның һәммә эшләре дә алга бина кылып эшләнә торган булуында шөбһә итмәгәнгә күрә, алар сыйфаты белән сыйфатланса, алар рәвешле тора алса, байлыгы тагын да артып, шөһрәте таралыр кебек күренә иде.

Беркөн шулай Садыйк байның кибете алдыннан үткәндә, аның йомыш-юлга йөри торган малаен ачуланганын күреп үтте. Шуннан соң үзе дә, малайларга ачуланганда, ничек ачуланырга кирәк икәнен өйрәнгән кебек, үзенең малайларына Садыйк бай кебек ачулана башлады.

Ул, байларның бик шәп аргамакка утырып, кучерлар белән генә йөрүләренә бик кызыга иде. Ул бу теләккә дә иреште. Өендәге гади нәсел ат өстенә яхшы ат һәм рессоралы тарантас алып, һәрбер йомышка ярый торган Шәйдине кучерга утыртып йөрергә керешге. Ул хәзер, кибеткә барганда, кайтканда һәм башка җирләргә йөргәндә, кучер белән йөри торган булды. Бу рәвешле йөрү генә әле чын байларча йөрү кебек булып бетмәсә дә, ул үзен байлык юлларының икенче, өченче баскычларын атлаган кебек хис итте.

Ул байлыкта һәм байларга охшауда үзенең көннәнкөн күтәрелгәнен белсә дә, башка кешеләр аны, акыллы бай дип, зурлар рәтеннән йөртмәгәнгә эче поша һәм үзен бөтен мәхәллә халкына таныштырасы, хәтта бөтен шәһәрдә үзен белдерәсе килә иде.

Ул шул теләккә ирешер өчен, сирәкләп, мәхәлләнең күзгә күренгән кешеләрен, берничә мәхәлләнең муллаларын ашка чакыра, гаетләргә барган чагында сәдаканы башкаларга күрсәтерлек рәвештә күбрәк өләшә, бер нәрсә файдасына акча җыйганда, өр-яңа ефәк эчле кәләпүшен кулына тотып, сафтан сафка йөри... Шушы юллар белән игътибарлы булуны көтә иде.

Аның шулай „дин өчен, мәхәллә файдасы өчен“ тырышулары бушка китмәде:

Бу ел мәхәллә мөтәвәллиләре сайлаганда, аны да мөтәвәлли итеп сайлау өстенә, мәхәллә мулласының:

— Вәли әфәнде, сез хәзинәдар[1] булырсыз инде...— дигән сүзе буенча, аны хәзинәдар да итеп сайладылар.

Ул, бу рәвешле халыкның игътибарлы кешесе булып әверелгәнен күреп, үзен тагын бер баскыч күтәрелгән кебек хис итте һәм үзен шул мәхәлләнең ин акыллы бер кешесе, иң эшлекле бер әгъзасы, хәтта шул тирә халкының башлыгы кебек итеп фараз итә башлады.

Мәхәлләнең игътибарлы кешесе булганнан соң, җомга һәм гаетләргә барганда кияр өчен чалма белән чапан да алып куйды. Башкаларга исәнләшкәндә башын югары күтәреп кенә, ияк кагып кына исәнләшә торган булды.

Үзе шулай булу белән генә калмый, ун яшьлек Гайнулласына читек, кәвеш, өстенә җөббәгә охшатып тегелгән бишмәт, башына фәс кидереп, үзе белән бергә җомга һәм гаетләргә алып бара башлады. Аның кечкенә Гайнулласы шушы киемнәр аркасында мәхәлләнең ярлы кешеләренең балаларыннан аерылып күренә һәм Вәлинең үзе кебек акыллы булырга хәзерләнә кебек булып күренде.

Мәхәлләнең мөтәвәллие булу да, йөреш-торышларын үзеннән югары байларга охшатып алып бару да аның сату-алу эшләренә комачаулык итми, бәлки файда гына итә бардылар. Ул барган саен сумаланды. Үзенең йорты янындагы кибете китергән файда базар сәүдәсенә комачаулык иткәнгә күрә, аны бөтенләй япты, аның урынына базардагы кибетен зурайтып, товарларын арттырды, төрләрен күбәйтте.

---

[1] Хәзинәдар — казначей.

Ләкин әле ул үзенең һаман байлар арасында танылып бетмәвен, алар арасына чынлап та керә алмавын, алар белән син дә мин бер мәҗлестә утырырга туры килмәвен уйлап борчыла, алар авызыннан:

— Вәли уңган егет булып чыкты... Тиз арада гына кеше арасына кереп байлык ясап алды,— дигән сүзләрне ишетәсе килә иде.

II

СУГЫШ АЛАР ӨЧЕН ФАЙДАЛЫ БУЛДЫ

Вәлинең сәүдә эшләре, тигез юлда барган арба тәгәрмәчләре кебек, алга барган чагында, Европа империалистларының үзара сугышлары чыгып китте. Эшчекрестьяннарга бик күңелсез хәлләр тудырган, аларның бала-чагаларын ятим калдырып, күз яшьләре агызырга сәбәп булган бу зур сугыш Вәли һәм башка сатучыларга, зур җир хуҗалары — байларга аның киресенчә булып чыкты.

Сугыш чыгу белән, сату-алу эшләренең файдасы бермә-бер артты. Сугыштан элек алынып куелган капчыклар, тагын әллә нәрсәләр ике-өч хак белән сатылдылар. Кайбер товарлардан сумга сум файда ителде.

Шулай итеп, бу сугыш Вәлигә көтелмәгән бәхет ишеген ачты. Бик аз вакыт эчендә унар-егермешәр мең сум файда итеп ташлау аның күңелен үстереп җибәрде. Ул хәзер үзенең бай — чын бай булачагына чынлап та иман китерде.

Сума арту белән, товар арту белән, кибеттә эш артты. Борыннан хезмәт итеп килгән Шәйди белән ике малай өстенә эшне яхшы белә торган бер малай, бер приказчик алды. Хәзерге сәүдә өчен теге кибет кечкенәлек итә башлаганга күрә, икенче бер зур кибет алып, малларын шунда күчерде.

Хәзер аның бу яңа кибетенең ишекләре өстендә, эре хәрефләр белән путаллап язылган вывескасы әллә

Вәлиулла Әхмәт угылы Нигъмәтҗановның төрле маллар сәүдәсе

кайдан ялтырап күренә, аны күргән саен үзенең күңеле күтәрелә иде.

Ул хәзер, кулында шул чаклы мал, шул чаклы акча булганын күргәч, шәһәрнең читенә табан, шундый

өч-дүрт кенә бүлмәле өйдә торуны үзенә һәм тоткан юлына килештерә алмый башлады.

Бигрәк тә сугыш аркасында йорт-җир сатучылар күбәеп китүе һәм башка зур сәүдәгәрләрнең борынгы йортлары өстенә 40—50, хәтта 100 мең тәңкәгә чаклы зур-зур йортлар алулары аның күңелен кытыклады.

Кайберәүләр авызыннан:

— Вәли тәмам аякка басты, зур сумалы булды, эшләрен юлга салып җибәрде,— дигән сүзләрне ишетү аның бу теләгенә көч биргән шикелле булды.

Йорт-җир бер алынып куелса, алар һичбер вакыт бәһаларын югалтмый торган, гомерлек „милек" дигән уйлар белән, шәһәрнең урта бер җиреннән йорт алырга карар бирә, агай-энеләре арасында йорт алырга теләге булганлыгын сөйләп йөри башлады.

Күп вакыт үтмәде, ире сугышта үлгән бер полковникның тол калган маржасының N урамындагы йортын сатарга теләвен Вәлигә хәбәр иттеләр.

Йорт шәһәрнең урта җиренә якын, хәтта Садыйк байлар белән бер урамда булуы өстенә, хакы да артык кыйммәт булмагач, Вәли йортны алды да унбиш көн эчендә күчеп тә өлгерде.

Борыннан иркен һәм шәп тормышка каратылып эшләнгән алты-җиде бүлмәле өйгә, Вәлиләрнең әүвәлге йорт җиһазлары җитәрлек тә һәм ул җиһаз белән мебельләр бу йорт эчендә аргамак өстенә юкә шлея кидергән кебек күренгәч, яңа мебельләр алырга туры килде. Шуның өчен кайдадыр күченеп китә торган берәүдән яңа өйгә килешә торган мебельләр алды. Бу нәрсәләр дә асылда торган бәһаларыннан күп арзан нәрсәләр булып чыктылар.

Шушы йорт һәм йорт җиһазларына берничә ун мең сумнар расход чыгаруга карамастан, Вәлинең сәүдә эшләре борынгыча барды, файда агып тора торган чишмәгә һичбер зыян килмәде.

Йорт алганнан соң өч-дүрт ай эчендә файдасы йорт һәм җиһазлар алырга чыккан расходларын каплап өлгереп, алар һәммәсе файдага калдылар.

Вәлиләр яңа алган йортларына күчкәч, эчке тормышка да үзгәреш ясарга туры килде. Элек теге бәләкәй йортларында торган вакытта алар кечкенә бер асрау кыз тоталар, күбрәк эшне Хәмдия (Вәлинең хатыны) үзе эшли, аш-суларга чаклы үзе пешерә иде.

Хәзер, зур йортка күчкәч, тагын бер асрау кирәклеге күзгә бәрелде. Шуның өстенә, башка бай хатыннарының кул астында берничә асрау булуы, хуҗа хатыннарының йорт эшләре белән пычранып йөрмәүләре дә күзләренә чагылды. Шуларга карап, Хәмдиянең күңеленә: „Бай хатыны бул да, үзең чучка кебек пычранып эшләп йөр, имеш!..“ дигән уй төште. Ул бу уйларын Вәлигә дә әйтеп, аның да күңеленә төшерде.

Вәли Хәмдиянең бу хаклы таләбен, байларча торырга булган теләген читкә какмады. Бәлки, туры килсә, аш-су пешерү рәтен белгән бер асрау алырга кушты.

Күп тә үтми, ире сугышка китеп, берничә айдан бирле хәбәре килми торган япь-яшь бер хатынны асрау итеп алдылар.

Электән мондый күренекле асрау белән торып өйрәнмәгән Хәмдиягә шундый асрау белән тора башлау бик сәер тоелды. Аңа нинди хезмәтләр йөкләтү, бу өй эчендә аның хокукының микъдарын[1] билгеләү, аның йөреш-торышындагы хәрәкәтләрен чикләү, аны Вәлигә күрсәтеп-күрсәтмәү аның башын ватты. Ат кебек таза, тулы гәүдәле япь-яшь бер хатынның күз алдында йөрүе, Вәлинең аңа күзе төшү ихтималы барлыгы, аны шикләндерә төште. Ләкин башка байларда шундый берничә асрау булуын, бай булгач, шунсыз торып булмавын, ул ничаклы таза, матур булса да, тамак асрар өчен кергән асрау икәнен, ә үзенең бу өйнең төп хуҗасы булган Вәлинең никахлы хәлаль[2] хатыны икәнлеген уйлап, үзенә югары бәя куйды. Шуның өстенә үзенең асрау белән теләсә ничек мөгамәлә итәргә, аны кысарга да, тиргәргә дә, андый-мондый начар гадәте беленә калса, шул сәгатьтә үк куып чыгарырга да хаклы икәнен уйлап, күңелен юатты.

Шәһәр уртасына, шундый зур өйгә күчкәч, шәһәр читендә торган вакытта кигән өс киемнәре дә хәзер ярамаган кебек булып күренделәр. Шуның өчен алар үзләренең дә һәм Гайнулла белән Сәгыйдәнең (кызлары) дә киемнәрен үзгәртеп, яртылаш „урысчалатып“ тектерә башладылар.

Алар — элек үзләрендә хезмәт итүче Шәйди белән Сафаны үзләре белән бер өйдә кухня тирәсендә то-

---

[1] Микъдарын — күләмен

[2] Хәлаль — законлы.

талар иде. Бу өйгә күчкәч, аларны бу өйдә тоту бер дә мәслихәт эш булмавын уйлап, ат сарайлары янында, электән теге бояр марҗасының кучеры тора торган ике тәрәзәле кечкенә йортка күчерделәр.

Шулай итеп, Вәлинең сату-алу эшләре шәбәюе, зур йортка күчүе, аларның тормышларын үзгәртергә, икенче төрле әйткәндә, иске тормышны яңа формага әйләндерергә, чын „байларча“ торырга мәҗбүр итте.

Хәзер Вәли үзенең тормышыннан канәгать итсә дә, тик әле һаман теге зур байлар арасына кереп китә алмавына, алар тарафыннан „акыллы, эшлекле, чибәр эш йөртүче егет“ булып танылмавына эче поша. Ул бу эшне үзенең игътибарлы булып җитә алмавыннан күрә һәм шул теләгенә ирешер өчен бер форсат[1] көтә иде.

III

„ҖӘМГЫЯТЕ ХӘЙРИЯ“НЕҢ ГОМУМИ ҖЫЕЛЫШЫ...

Көзгә каршы... шәһәренең „җәмгыяте хәйрия“сенең гомуми җыелышы булу хакында шул шәһәрдәге бер бай тарафыннан нәшер ителеп килә торган „Заман“ гәзитендә игълан чыкты.

Игълан түбәндәгечә иде:

„1915 нче ел 15 нче сентябрьдә „җәмгыяте хәйрия“-нең гомуми җыелышы булачак һәм җыелышта түбәндәге мәсьәләләр каралачак:

1—Җәмгыяте хәйриянең үзенә махсус йорт алу.

2—Сугышта мәҗрух булган[2] солдатларга мөселманнар исеменнән лазарет ачу.

3—Яңа әгъзалар кабул итү.

4—Агымдагы эшләр.

Җәмгыятьтә каралачак мәсьәләләр соң дәрәҗәдә мөһим булганлыктан, әгъзаларның килүләре үтенелә.

Җәмгыяте хәйрия идарәсе“.

Шул ук „Заман“ гәзитенең шушы номерында, булачак җыелышның мөселманнар өчен гаять мөһим булуы турында аерым мәкалә язылып, ул мәкаләдә һиммәтле байларның милләт һәм ватан юлында үзлә-

---

[1] Форсат — уңайлы вакыт.
[2] Мәҗрух булган — яраланган.

ренең байлыкларын кызганмый зур иганәләр[1] итәргә тиеш икәнлекләре кабат-кабат искә төшерелеп үтелгән иде. Сугыш вакытында сату итеп көрәйгән базар сатучылары бу хәбәрне бик хуплап, ниһаять дәрәҗәдә мөһим эш итеп каршы алдылар.

Гәзиттә игълан һәм „мөһим“ мәкалә чыгу белән, җыелышта каралачак мәсьәләләр, бигрәк тә җәмгыяте хәйрия исеменә йорт алу, лазарет ачу турындагы матдәләр[2] хакында кызу мөзакәрә[3] һәм ярдәмгә өндәүләр башланды.

Шакирҗан байның җәмгыяте хәйриягә һәм лазарет ачар өчен зур сумалар иганә итәргә нияте булганлыгы сөйләнде.

Бу эшләр эшләнә калсалар, мөселманнарның тәрәкъкый итүләренә зур адым булачагы, рус байлары һәм түрәләре арасында йөзләре агарачагы телдән-телгә йөрде.

Байлар тарафыннан ясала торган аш мәҗлесләрендә бөтен сүз шушы мөһим җыелыш һәм анда эшләнергә тиешле эшләр турында барды. Бу мәҗлесләрдә шәһәрнең могтәбәр[4] ахун һәм муллалары, „Заман“ гәзитенең баш мөхәррире Кадри әфәнде һәм башкалар алдагы җыелышның әһәмияте хакында бик мөһим гыйльми сүзләр сөйләп, сәяси һәм матди[5] яктан әһәмиятле икәнен исбат иттеләр. Җәмгыяте хәйрия өчен йорт алу — милләтне тәрәкъкый иттерү булса, лазарет ачу — руслар арасында мөселманнарның абруйларын арттыру икәнлеген сөйләделәр.

Сугыш вакытында яңа күтәрелеп килгән сәүдәгәрләр дә бу җыелышка үзләре хәзер булып ярдәм кулларын сузарга, һиммәт күрсәтергә тиеш икәнлекләрен күз алларына китерделәр.

Зур байлар шул чаклы әһәмият биреп караган эш булгач, безнең Вәли дә бу эшне бик мөһим, кирәкле эштер дип, күңеленә беркетеп куйды. Хәтта эченнән генә үзенең күпме иганә бирәчәген, җыелышта акча җыюның барышына карап бу чаманы арттырырга мөмкин икәнен һәм игътибарлы сәүдәгәр, булдыклы кеше

---

[1] Иганәләр — ярдәмнәр.
[2] Матдәләр — пунктлар.
[3] Мөзакәрә — фикер алышу.
[4] Могтәбәр — игътибарлы, абруйлы.
[5] Сәяси һәм матди яктан — политик һәм материаль яктан.

икәнен бөтен шәһәр халкына һәм үзеннән зур байларга күрсәтергә юл ачылачагын уйлап шатлана башлады.

Гомуми җыелыш ясау көне сату-алу булмаган көндә — якшәмбегә каратып куелган иде.

Якшәмбе көн, өйләдән соң, сәгать берләрдә үк җыелыш булачак биржа залы халык белән тула башлады. Бер сәгать эчендә зал каракүл бүрек, бархат якалы бертөслерәк пальтолар кигән, тик юанлык-нәзеклектә, картлык-яшьлектә генә бер-берсеннән аерылган кешеләр белән тулып китте.

Боларның күбесенең авызында бу көнге җыелышта каралачак мәсьәләләр булып, тик кайберәүләре генә сугышның барышы яки үзләренең алыш-бирешләре хакында сөйләшәләр иде.

Бер сәгать көттергәннән соң, аерым бүлмәдән, җәмгыяте хәйриянең идарә әгъзалары чыгып, зур өстәлнең халыкка каршы ягыннан урын алдылар. Алар рәтеннән берничә мулла, шәһәрнең могтәбәр затлары — байлары утырдылар. Шул тирәдәге утыргыч һәм скамьяларга, сату эшләренең зурлык-азлыгына карап утырган кебек, ваграк байлар, алар артына байларга күп хезмәтләр күрсәткән җитез, булдыклы приказчиклар тезелделәр.

Халык шулай урнашып беткәч, җәмгыяте хәйриянең идарә рәисе, бу җыелыш өчен рәис сайларга тиеш икәнен әйткәннән соң, үзе тарафыннан рәислеккә Хәлим Карачуринны мәслихәт күреп, шуны тәкъдим итте. Аның сүзе тәмам булуы белән:

— Ярар, ярар, Хәлим әфәнде рәис булсын! — дигән тавышлар чыкты. Тик арадан кайберәүләре генә икенче байларның исемнәрен кычкырдылар. Ләкин ул исемнәре әйтелгән байлар үзләре:

— Хәлим әфәнде рәис булсын, без дә аның рәис булуын телибез, — дигәч, рәис сайлау мәсьәләсе хәл кылынып, Хәлим Карачурин рәислек урынына утырды.

Рәис, урынына утыргач, җыелыш өчен секретарь сайларга гарыз итте[1]. Халыкның алга утырган бер группасы тарафыннан:

— Хәйрулла әфәнде Әхмәтов, — дигән тавышлар чыкты. Кайбер байлар да аның секретарь булуын ишарә иттеләр.

---

[1] Гарыз итте — тәкъдим итте.

Рәис:

— Хәйрулла әфәнде, әйдәгез, әйдәгез! — дигәч тә, Хәйрулла Әхмәтов, бик зур бер урынга сайланган кебек масаеп һәм кызара төшеп, рәис янына килеп утырды һәм әүвәлдән хәзерләнеп куелган кәгазьләр өстендәге каләмне алып караганнан соң, алдындагы кәгазьгә нәрсәдер яза башлады.

Шул чакта арадан берничә кеше:

— Җыелыш коръән укылып ачылсын иде! — дигән тәкъдимне керттеләр. Бу тәкъдимне бөтен җыелыш тәсдикъ итте[1].

„Коръән укырга“ дигән тавышны ишеткәч, муллалар кузгалышып, бер-берсенә карашып алдылар.

Шунда кемдер: „Ахун хәзрәт укысын иде“, — дигән сүзне әйтте. Өстәл тирәсендәге кешеләр дә:

— Хәзрәт, берәр аять рәхим итегез!.. — дип, ахунга карадылар. Җиһаннур ахун Ишгилдин кызара төшеп, әдәп ригая итү[2] йөзеннән, халык тарафыннан бирелгән коръән уку правосын янындагы муллаларга тәкъдим иткәнсымак, аларга карап:

— Рәхим итегез! — диде. Алар башлары белән ишарә итеп, „үзең укы“ дигән сүзне аңлаттылар. Шуннан соң гына Җиһаннур ахун, авызын иплән, тамагын йомшак кына кырып, авазларны мәхрәҗләреннән[3] чыгарып, авазларын аерым рәвештә йомшак әйтеп, гоннәләрен (тавышны танаудан чыгара төшеп) берничә аять укып ташлады. Коръән укып беткәч, һәммә халык догага кул күтәрде.

Дога кылынып беткәч, рәис аягүрә басып, мәҗлесне ачык игълан итте һәм көн тәртибендәге мәсьәләләрне берәмләп әйтеп чыкканнан соң, җәмәгатькә карап:

— Арттыра торган мәсьәләләр юкмы? — дигән сөальне бирде. Җәмәгать байларга карады. Байлар арасыннан Шакирҗан бай белән Садыйк бай: „Башка арттыра торган мәсьәлә юк“, дигәннән соң, көн тәртибе шул көенчә кабул ителеп, беренче мәсьәлә булган *„Җәмгыяте хәйрия“гә йорт мәсьәләсе* мөзакәрәгә куелды һәм рәис бу хакта сөйләргә тотынды.

Иң башта җәмгыяте хәйриянең хәзинәдары Шакирҗан бай сүз алып, бу җыелышны ясарга губернатор

---

[1] Тәсдикъ итте — раслады.
[2] Әдәп ригая итү — әдәп саклау.
[3] Мәхрәҗләреннән — сөйләү органнарыннан.

тарафыннан ничек рөхсәт алынганын әйтеп үткәннән соң, җәмгыяте хәйрия өчен махсус йорт кирәклеген, аның бик мөһим икәнлеген, хәзерге көндә шәһәрдә берничә йөз меңгә зур гына йорт алып булуын, әгәр дә һиммәт итеп, шундый бер йорт алынса, берничә бүлмәсен җәмгыяте хәйриянең идарәсе һәм җыелышлар өчен хаслап калдырып, бер катында татар балалары өчен гимназия кебек берәр мәктәп ачарга мөмкин булуын, аннан калган җирләрен иҗарәгә — арендага биреп, доход алып торырга мөмкин икәнен, шуның өчен бу эшкә һичкем икеләнеп карамый, хәзердән үк акча җыйнарга тиешлеген сөйләп, сүзен тәмам итте.

Аның һәрбер сүзен башыннан ахырга чаклы дөресләгән кебек баш иеп, „дөрес!.. кирәк!“ дип кычкыру өстенә, шатлык белдереп, шаулатып кул чаптылар.

Шакирҗан байдан соң, сүз сөйләргә бер хәзрәт рөхсәт алып, аягүрә басты. Ул әкрен генә тавыш белән башлап, бара торгач тавышын шәбәйтә төште. Дин һәм милләтнең һиммәтле[1] байлар, хәмиятле[2] затлар, чын гыйльми, инсафлы голәмалар[3] аркасында яшәп тәрәкъкый итүен, шулар аркасында гына белем — һөнәр таралуын аять, хәдисләр катыштырып, алга киткән Европаны мисалга китереп, өч йөз миллион мөселманнарның артка калуларына һиммәтле кешеләрнең азлыгын сөйләп, аять, хәдисләрдән дәлилләр китерде. Ниһаять, җәмгыяте хәйрия өчен йорт алып калуның кирәк икәнлеген әйтеп, сүзен тәмам итте. Бу хәзрәтнең сүзләре дә халык тарафыннан хуплап каршы алынды. Ул сөйләгәндә, тәрәкъкый пәрвәррәк[4] ваграк байлар, бер-берсенә карашып, хәзрәткә тәхсин[5] игкәнлекләрен белдергән рәвештә, шатлыкларын йөзләренә чыгарып утырдылар.

Болар соңында башка берничә бай, югарыда сөйләнгән кешеләрнең фикерләренә кушылганлыктан, үзләренең җәмгыяте хәйриягә махсус йорт алу тарафында икәнлекләрен белдерделәр.

Шулай беренче мәсьәлә инде хәл кылынды дигән

---

[1] Һиммәтле — эшлекле, булдыклы.
[2] Хәмиятле — яклаучы, саклаучы.
[3] Голәмалар — галимнәр.
[4] Тәрәкъкый пәрвәррәк — прогрессиврак.
[5] Тәхсин — мактау.

чагында гына, арттан — ишек төбенә якын бер җирдән берәү күтәрелеп, сүз сөйләргә рөхсәт сорады.

Хәзергә чаклы сөйләнгән сүзләрдән артык сүз, хәзергә чаклы әйтелгән фикерләрдән артык фикер әйтүче булыр дип берәү дә уйламаган иде. Шундый бер хәлдә, түбәннән торып, зурлар, байлар, голәмалар алдында сүз сөйләргә җәсарәт[1] иткән кем булыр икән дигән кебек, җыелышта булган һәммә халыкның күзе теге ишек төбендәрәк торып сүз сөйләргә рөхсәт сораган кешегә таба юнәлде.

Ул кешенең бу көнгә чаклы мондагы кешеләрнең берәвесенә дә таныш булмаганын, бервакытта да байлар арасында, аларның мәҗлесләрендә-фәләннәрендә күзгә төшкән кеше түгел икәнен күргәч, бу мескен нәрсә сөйләмәкче була икән, дигән кебек бер хәлдә калдылар һәм аңа күз белән карап, аны тәхкыйрь иткән[2] кебек көлеп куйдылар.

— Юк, сөйләмәсен! — дигән тавышлар чыкты.

Рәис ул кешегә сүз бирми килештерә алмады:

— Сөйләсен, җәмәгать, тыңлап карыйк! — диде. Рәис шулай дигәч, башкалар да: „Ярый, мескен, сөйләсен инде, нәрсә әйтмәкче була икән“, — дигән кебек, аның сүзләрен көттеләр.

Теге кеше баскан урынында киерелә төшеп:

— Җәмәгать, сез монда бернәрсә дә эшли алмаган, коры исем күтәреп, татарларны алдап артта калдыра торган җәмгыяте хәйрия исеменә йорт алуның мөһим эш икәнен сөйлисез. Коры бер җәмгыяте хәйрия белән мөселманнарны тәрәккый иттермәкче, бер йорт алуны зур бер эш итеп күрсәтмәкче буласыз. Дөрес, сез теге ләр анда сугышып йөргәндә, монда сату итеп җыйган акчаларыгыз аркылы бер йорт алган булып, шуның белән халыкның күзен буяп, үзегезне зур эш эшләгән иттереп, башкаларны хәйран калдырмакчы була торгансыздыр...

Ул шул урынга җиткәндә, халык арасыннан:

— Кирәкми!.. сөйләмәсен! — дигән тавышлар аның сүзен бүлделәр.

Рәис колокол шалтыратып, җыелыштагы халыкны тынычлыкка өнди һәм сөйләүчегә карап, теләктән

[1] Җәсарәт — батырчылык.
[2] Тәхкыйрь иткән — мәсхәрәләгән, кимсеткән.

читкә китми, нәрсә әйтергә теләгәнен кыскалык белән әйтүен үтенде.

Теге кеше тагын сүз башлап:

— Әгәр дә сезнең акчаларыгыз бик күп булып, алай изгелек итәргә телисез икән, әнә хәзер сезне саклар өчен аталары сугышка китеп, шунда үлгән яки хәбәрсез югалган кешеләрнең ятим торып калган әллә ничаклы балалары бар. Шуларны карау юлларын эзләргә кирәк. Икенче, сез гимназия дигән буласыз. Во-первых, сез бу режим булган вакытта, үзегез теләгәнчә гимназия түгел, иптидаи[1] мәктәп ачарга да рөхсәт бирәчәк түгелләр. Бирсәләр дә, анда сезнең үз балаларыгыз, ягъни бай балалары гына укыячак. Шуның өчен ул һаман үзегез өчен эшләнгән эш булачак...

Рәис мәсьәләдән читкә чыкмаска тәнбиһ[2] ясады. Халык гөж килеп:

— Долой!

— Нәрсә сөйләп торган була!..

— Акчаң булса, аларны үзең кара!..

— Ай, җөнтәс! — дип кычкыра башладылар. Бу тавышлар арасында сөйләүченең: — Ничум монда халыкны катнаштырып, милләт исеменнән сөйләп торырга! — дигән сүзләре ишетелеп калды.

Тавыш, шау-шу берничә минутка сузылды. Халык кызып китте. Шунда җыелыш тәртибен карап утыручы янындагы берәү белән колактан-колакка нәрсәдер пышлашканнан соң, теге кешегә таба бара башладылар. Ләкин ул арада баягы сөйләгән кеше урынында юк, каядыр китеп өлгергән иде.

Хәзер җыелыш тынычлыкка килгән кебек булса да, ничектер күңелсезләнгән, теге „әллә кем“ кызып барган җыелышның хозурын җибәргән күк булып күренде.

Бу күңелсез тормышны күңелләндерү — байларга тагын гайрәт биреп җибәрү кирәк иде. Шуны тиз генә сизеп алган Заһир мулла, урыныннан торып, берничә генә сүз әйтергә рөхсәт сорады.

— Сөйләсен!.. — тавышлары астында Заһир мулла сүз башлап, мондый җыелышларда андый ихтилафларның[3] булуын, фикерләр ихтилафыннан хакыйкать тууын,

[1] Иптидаи — башлангыч.
[2] Тәнбиһ — кисәтү.
[3] Ихтилафларның — бәхәс, тартыш, дискуссия.

ислам диненең хөррияте кәлам әсасына[1] нигезләнгәнен... шуның белән бергә милләт, дин юлында эшләнгән эшләрнең мәгънәсенә төшенмәүчеләрнең каршы чыгуларын, ләкин андый мәгънәсез чыгуларга карап алган эшләрне ярты юлда калдыру ярамаганлыгын... милләтнең һиммәтле байлары, хәмиятле галимнәре булган вакытта, берләшеп эш күргәндә һәрбер дошманның сүзе аска калачагын... сөйләп, мәҗлесне җанландырып җибәрергә тырышты. Аның бу сүзләренә шатлык белән карап утырган кешеләр, ул сөйләп бетергәч тә, кул чабып: „Афәрин!.. рәхмәт!..“ дип кычкырдылар.

Аның соңыннан Хәйрулла Әхмәтов чыгып, Заһир мулланың сүзләре дөрес икәнен, җәмгыяте хәйриягә йорт алу хакында мөзакәрәне бетерү өчен, рәиснең тавышка куюын үтенде.

Башкалар да Әхмәтовның сүзенә кушылдылар.

Рәис мөзакәрә бетерүне тавышка куйгач, бу тәкъдим беравыздан кабул ителде.

— Мөзакәрә бетсен, мәсьәлә бик аңлашылды! — дигән тавышлар чыкты.

Йорт алу мәсьәләсе рәис тарафыннан тавышка куелып, беравыздан кабул ителде. Моның шатлыгыннан бик озак кул чаптылар.

Шушы карардан соң, Шакирҗан бай урыныннан торып, җыелыштагы җәмәгатькә елмаеп карап, йорт алуның мөһим икәнен, моның өчен һәркемнең кулыннан килгән кадәр ярдәмне кызганмый бирергә тиешлеген әйткәч:

— Миннән 25 мең сум языгыз!.. — дип, кире урынына утырды.

Сразы 25 мең сумны ишеткәч, кешеләр аптырап киттеләр.

— Афәрин!..

— Шакирҗан абзый, яшә!..

— Рәхмәт һиммәтеңә! — дигән сүзләр артыннан тагын куллар чабылды. Шакирҗан байдан соң башка байлар бер-берсенә караштылар. Халыклар: „Тагын кем күпме бирә инде?..“ дигән кебек, теге мәшһүр байларга карадылар.

Шул вакыт Садыйк Кадриев урыныннан торып:

---

[1] Хөррияте кәлам әсасына — сүз ирке нигезенә.

— Миннән 15 мең сум языгыз! — дип, урынына утырды. Күрәсең, халык аның борыннан миллионер булуына карап күбрәк бирүен, һич булмаса Шакирҗан байдан да ким бирмәвен көтеп торгандыр. Шуңа күрә аңа ашыгып рәхмәт әйтүче, кул чабучы бик аз булды. Кайбер кешеләр Садыйк байның 15 мең сумнан арттырып бирергә тиеш икәнен әйтеп, ишарә кылып куйдылар. Садыйк бай әйткән сүзендә нык торды, арттырмады. Аның шулай тартышуы аркасында мәҗлес тагын да ямьсез бер төс алды. Байлар арасында сүз китте.

Ниһаять, Садыйк бай 20 мең сум бирергә риза булды. Аннан соң халыкның күзе урта яшьле Хәбиб Нәгыймовка терәлде. Хәзер ул үзенә нәүбәт җиткәнен, халык карамаса да, белә иде. Шуның өчен бер дә көттерми урыныннан торып:

— Мин хәзер үз исемемнән бернәрсә дә әйтә алмыйм. Чөнки бу хакта әти карт белән сөйләшкәнем юк. Аның киңәшеннән башка нәрсә әйтсәм дә, килешмәс. Соныннан яздырырбыз, башкалардан, иншалла, калышмабыз,— диде. Аның бу рәвешле акыллы сүзләрен урынлы табып, кул чаптылар һәм „аларның бирүләре мәгълүм, аны кулдагы акча кебек белергә кирәк...“ дип өстәп тә куйдылар.

Моннан соң байлыкта болардан түбәнрәк икенче, өченче дәрәҗәдәге байларга күчтеләр. Болар хәзер бер-берсенә ишарә итеп: „Әйдә син башлап яздыр... син башлап бир...“ дип үзара димләшә башладылар. Ул арада югары байлар тарафыннан бу кечкенә байлардан берничәсенең исемнәре дә әйтелеп өлгерде.

Безнең Вәли хәзер үзенә һәм үзе кебек яңа күтәрелеп килгән байларга нәүбәт җиткәнен күреп, йөрәге кагып китте. Чөнки ул, җыелышка килгән вакытта ук, үзенең һиммәтен күрсәтеп, зур байлар каршында танылып китүне уйлап килгән иде. Бәлки, теге зур байлар тарафыннан үзенең исеме, фамилиясе телгә алынмауга аның эче пошып китте. Үзен күрсәтәсе килеп, алай-болай селкенеп, бүреген рәтләп куйды. Теге исемнәре телгә алынган вак байлар берәм-берәм торып, зур байлар утырган өстәл каршысына барып, меңәр, икешәр мең сум иганә яздыра башладылар. Зур байлар һәм кайбер муллаларның шунда өзлексез димләп: „Фәлән әфәнде, синнән бу гына аз, арттыра

төш, һимматеңне күрсәтеп кал!..“ дип әйтүләренә карап, бер меңне ике мең, ике меңне өч мең итеп, арттырып яздыручылар да булды.

Бервакыт Садыйк бай, бернәрсә эзләгәнсымак, халык арасына күзен йөртә башлады. Вәли аның шулай карганын күргәч, „мин монда...“ дигән кебек күтәрелә төшеп, тамагын кырып куйды. Шул чакта Садыйк байның күзе белән Вәлинең күзләре бергә очраштылар. Вәли шатланып китте, йөрәге кага башлады. Менә нәкъ шул вакытта Садыйк бай:

— Әнә тегендә яңа, яшь байлардан Вәли әфәнде бар, аннан күбрәк яздырырга кирәк...— дигән сүзне әйтеп, Вәлигә карап башын селкеп, исәнләшкән кебек булып куйды.

Садыйк байның бу сүзе Вәлинең йөрәгенә килеп керде. Садыйк байның сүзенә башкалар да кушылып: „Әйе шул, Вәли әфәндедән күбрәк алырга кирәк, аның эше яхшы“,— дип өстәп куйдылар. Бу сүзләрне ишеткәч, Вәлинең йөрәге түзмәде, эченнән генә мине дә телгә ала башладылар дип шатланды һәм, үзенең янәшәсендә утырган Гарифның тезенә төртеп куйды. Ул үзе белән бер чама булган сәүдәгәрләрнең, хәтта шәһәр арасында үзеннән игътибарлы, үзеннән баерак дип исәпләнеп йөргән уртачарак байларның күпме яздырганлыкларын бик дикъкать белән карап утыра иде, һәм бу җыелышта үзен күрсәтмәкче булып, үзенең шөһрәтен чыгарырга уйлап куйган иде. Садыйк байның „Вәли әфәнде“ дип исемен атап әйтүе, башкаларның да Садыйк байның сүзенә кушылып китүләре аны тагын да дәртләндерә төште. Шулар өстенә Шакирҗан бай Вәлигә карап:

— Я, Вәли әфәнде, бире рәхим итегез, сезне көтәбез...— дип әйтүе аны җилкендереп җибәрде. Шакирҗан байның сүзен ишеткәч, урыныннан торганын да сизми калып, идарә әгъзалары утырган өстәл каршысына барып басты. Анда барып басканнан соң, андагы байларның һәм муллаларның һәммәсе дә Вәлигә карап исәнләшкәч, тагын да кәефләнде. Үзенең һәркемгә мәгълүм була башлаган „акчалы кеше — акыллы кеше“ икәненә канәгать хасил итте. Аның каршысында утырган байларның һәркайсы яхшы җаннар, акыллы абзыйлар, якын иптәшләр төсле булып күренделәр.

Байлар Вәлидән ике мең чамасы көтәләр иде. Вәли аларның көтүләренә каршы һич уйламаганда:

— Рәхим итеп, миннән өч мең сум языгыз!..— дип җибәрде.

Байлар аның бу һимммәтен күргәч, аңа елмаеп карадылар:

— Менә рәхмәт! Шулай кирәк ул... Бик яхшы!..— дип Вәлине мактап куйдылар. Садыйк бай аерым рәвештә:

— Бик яхшы иттең, зур һиммәт иттең...— диде. Вәли шундый зур байның үзенә дусларча карап, матур сүзләр кушканын күргәч, үзенең күңелендә аңа каршы әйтеп бетермәслек җылылык сизде. Садыйк бай аңа үз атасыннан да якын, бөтен кешеләрдән акыллы булып күренде. Иганә списогына исем, фамилиясе һәм иганә итүе языылып беткәнче ул бик эреләнеп, өстәл янында басып торды. Кире үзенең урынына кайтканда, һәммә халык аңа караган, барча җәмәгать тарафыннан үзенең байлыгы, акыллылыгы, һиммәте тәсдикъ ителгән кебек булып сизелде. Эшнең көткәннән артык булып чыгуына эченнән шатланды. Бу шатлыгын уртаклашырга кеше таба алмас кебек булды. Урынына утырып, йөрәк кагуы бераз басылгач: „Мине күрдегезме?“ дигән кебек, сөальле бер караш белән тирәягындагы кешеләргә карап алды. Ул хәзер үзен өстәл тирәсендә утырган зур байлардан өч-дүрт кенә баскыч түбән кебек сизде.

Җәмгыяте хәйрия өчен йорт алырга иганә җыелып бетте. Иң соңыннан бик вак сәүдәгәрләр һәм байларның зуррак приказчиклары иганә бирделәр. Боларның иганәләре илле сум тирәсеннән башлап, ике-өч йөз сум тирәләренә чаклыга күтәрелә иде.

Вәли үзе өч мең сум биреп тә, үзеннән түбән бик күп кешеләрнең илле-йөз сум тирәләрендә генә йөргәннәрен күргәч, үзендә тагын бер югарылык күрде. Тегеләргә үзеннән түбән һәм бичаралар дигән күз белән карады. Үзенең шулар дәрәҗәсендә генә кешеләр җөмләсендә калмавын уйлап, аллага шөкранә итте.

Бу мәсьәлә беткәч, Заһир мулла, иганә итүчеләргә дин һәм милләт исеменнән тәшәккер итеп, зуррак иганә итүчеләрнең исемнәрен аерым әйтеп, аларның һәммәсенә дә афәрин укыды. Халык кул чапты.

Икенче мәсьәлә:

— Сугышта мәҗрух булган солдатлар өчен мөселманнар исеменнән лазарет ачу иде.

Рәис әфәнде, мөселманнар исеменнән лазарет ачуның әһәмиятен, сугышта йөрүчеләрне „онытырга“ ярамавын, губернатор хәзрәтләренең дә бу хакта мөселманнардан ярдәм көтүен кыскача сөйләп чыкты. Аның сүзе дикъкать белән тыңланды.

Рәистән соң бер мулла торып, ватанны саклаучы каһарман гаскәрләребезнең мәҗрухларын тәрбия итү бөтен халык, шулар җөмләсеннән мөселманнар өстенә дә төшүен, бу эшнең дә хөкүмәт каршында мөселманнарның абруйларын арттырырга сәбәп булачагын һәм сәяси яктан да әһәмияте зур икәнен, ватандаш руслар каршында, безне иҗаби яктан[1] карарга сәбәп булачагын тәфсыйлле[2] рәвештә сөйләп, лазарет ачарга өндәде.

Аның сүзләре дә җәмәгать тарафыннан яхшы каршы алынды. Хөкүмәт тарафыннан килгән вәкил дә елмаеп, шатланып куйды. Алардан соң Шакирҗан бай берничә сүз әйтеп, дошман һөҗүменнән безне саклаган, „мал-милкебезнең“ исән-сау торуына тырышкан хөкүмәткә мал, җан белән ярдәмләшү кирәклеген искә төшереп үтте. Аның сүзләрен дә дөресләп каршы алдылар.

Алардан соң әллә нинди кызмачарак берәү чыгып, рәистән рөхсәт сорап тормый:

— Җәмәгать, дөрес, без һәрвакытта хөкүмәткә ярдәм итеп киләбез, балаларыбыз солдатка баралар, сугыш сафында үләләр... Үзебез газиз малларыбызны да кызганмыйбыз, ләкин, җәмәгать... әйе, җәмәгать, ул бит Төркия белән, ягъни мәсәлән, үзебезнең дин кардәшләребез белән сугыша... Алар нигә сугышалар? Моннан кемгә файда... Мәсәлән, безнең бер теләк тә бирелми...— дип сөйли башлаган иде, рәис урыныннан торып, колокол шалтыратып, аны тиз генә сүздән туктатты. Җәмәгать һәм байлар куркуларыннан агарынып киттеләр. Эш бозыла язып куйды. Хөкүмәт вәкиленең йөзенә зәһәрле ачу чыкты. Халык аптырашып калды. Шунда бер-ике кеше торып, тиз генә

---

[1] Иҗаби яктан — уңай яктан.

[2] Тәфсыйлле — кат-кат, аңлатып.

теге сөйләүчене ике яктан җитәкләп алып чыгып киттеләр.

Бу кунелсез күренешне ничек тә капларга кирәк иде. Юкса, хөкүмәт вәкиле аркылы бөтен мөселманнарга „йөз карасы“ ягу булган бу сүзләр югары түрәләрнең колакларына ирешеп, мондагы бөтен игътибарлы затларның игътибарлары төшүгә, хөкүмәт ирләре һәм мәгълүм рус байлары каршында абруйлары югалуга сәбәп булачагы мәгълүм иде.

Шул „йөз каралыгын“ бетерер өчен, теге сөйләүченең сүзләре мәгәр үзенең фикере икәнен, аның гайре бер табигый хәлдә икәнен күрсәтер өчен, тиз генә:

— Долой, сөйләмәсен!..

— Кайдан килгән бу акыллы баш!..

— Исерек бит ул!..—

дигән сүзләр чыкты. Ләкин болай аны сүздән туктату гына, аны „акыллы баш“ дип мыскыл итү генә, исерек баш дип хурлау гына бу „кара тапны“бетерә алырлык түгел икәне мәгълүм иде.

Бу вакытта тагын да телгә оста Заһир мулла чыгып:

— Җәмәгать, мәҗлес күркәм бара. Җәмгыяте хәйриягә һиммәтле байларыбыз унар меңләп иганә бирделәр. Ватанны усал дошманнарның каты һөҗүмнәреннән саклау юлында мәҗрух булган гаскәрләргә лазарет ачып, хөкүмәткә ярдәмгә килү турысында һәрберсе ярдәмгә хәзер торганлыкларын әйтеп торалар. Вакыйган безнең мөселманнар ватанның иң авыр хәлгә килгән чакларында да һәрвакытта алгы сафта булдылар. Җаннарын, малларын фида иттеләр[1], һичбер вакытта кызганып тормадылар. Хөкүмәтнең биргән боерыкларына каршылык күрсәтмәделәр. Хәтта без бу эшләрдә руслардан алда торабыз дип ифтихар итсәк тә[2] хаклыбыз. Аллага, аның пәйгамбәрләренә һәм өлельәмергә итагать итү[3] безнең дини бурычларның иң зурысы. Бу безнең каннарыбызга сеңешкән. Немецлар Россия хөкүмәтенең алга барганлыгын күрә алмый безгә һөҗүм иттеләр. Алар безгә дошманнар, Төркия гәрчә безнең дини кардәшләребез булсалар да, аларның эш башындагы кешеләре бу турыда хаталык итеп,

---

[1] Фида иттеләр — корбан иттеләр.

[2] Ифтихар итсәк тә — мактансак та.

[3] Өлельәмергә итагать итү — түрәләргә буйсыну.

безнең дошманнарыбыз булган немецлар ягына, ягъни Германиягә кушылып, бөек Россия дәүләтенә каршы үзләре сугыш игълан иттеләр.

Монда ниндидер берәү, шуңа икенче төрле мәгънә бирергә маташып, халыкның фикерен саташтырырга теләде. Сәясәттән хәбәрсез булган мондый намәгълүм кешеләрнең сүзләренә безнең мөселман кардәшләр һичбер вакытта колак салмадылар һәм салмаслар.

Хөкүмәт белән халык, бигрәк тә мөселманнар арасын бозарга йөрүчеләр бар икән, алар я аңламыйлар, яки явыз ниятле кешеләрнең игъва[1]-коткыларына ияреләр булсалар кирәк. Бинаән галәйһи йөзләре ачык булмаган кешеләрнең сүзләре кирәк түгел. Андый сүзләргә ияреләргә монда утырган ил агалары һәм башка хәмиятле егетләр сабый түгелләр (хөкүмәт вәкиленә карап, тамагын кырып):

— Әйе, җәмәгать! Бу көнге кебек, күп мөселманнарның бергә җыелган вакытларында, без чын күңел белән берләшеп, хөкүмәткә ярдәмгә килергә тиешлебез. Яшәсен Россиянең батыр гаскәре!.. Яшәсен бөек Россия дәүләте!— дип сүзен бетерде. Аның сүзеннән соң җәмәгать шатланып кул чапты. Теге кеше тарафыннан, җыелыш өстенә төшкән кара болыт күтәрелгән, „кара тап“ бетерелгән кебек булды. Байлар бер-берсенә карап, муллага баш иеп, елмаешып куйдылар.

Рәис урыныннан торып, кулындагы бер кәгазьне күрсәтеп:

— Җәмәгать! Монда лазарет ачу хакындагы мөзакәрәне туктатып, мәсьәләне тавышка куярга тәкъдим керттеләр. Хәзер мин мөзакәрәне туктату-туктатмауны тавышка куям, ярыймы? — диде.

— Тукталсын!..

— Сөйләнсен!..

— Тавышка куелсын!.. —

дигән тавышлар чыкты.

Рәис тагын сүз башлап:

— „Тукталсын“ дигәннәр күбрәк. Хәзер тавышка куям. Бу мәсьәлә хакында мөзакәрә тукталсын дигән кешеләр кул күтәрсеннәр, инде тукталмасын дигән кешеләр тик калсыннар,— диде.

---

[1] Игъва — аздыру.

Куллар күтәрелде. Шакирҗан бай урыныннан торып саный башлады.

— Бер, ике... җитмеш биш.

— Кулларыгызны төшерегез!..— Төшерделәр.

Каршы кул күтәрүчеләр алты-җиде кешедән артмаганга күрә, санап та тормадылар.

— Битарафлар![1]

— Юк.

Җәмәгать гөрләтеп кул чабып җибәрде.

Шуннан соң рәис урыныннан торып, мөселманнар исеменнән лазарет ачу-ачмауны тавышка куярга булып, ачу ягында булган кешеләрнең кулларын күтәрүләрен үтенде.

Шул минутта бик күп куллар күтәрелеп, яфраклары кәҗәләр ашап киткән агачлар кебек, бер күренеш хасил булды.

Шакирҗан бай тагын да урыныннан торып:

— Бер, ике, өч, дүрт...— дип санап китеп, сиксәнгә тутырды. Кайбер кешеләрнең икешәр кулларын күтәргәннәрен күреп, көлә төште дә:

— Икешәр кулларыгызны күтәрмәгез, болай да санап бетерер хәл юк,— дип, санавында дәвам итте.

— Җиде, сигез...

— Егерме, егерме бер...

— Утыз, кырык... „сиксән...“ булып чыкты.

Рәис каршы тавыш бирүчеләрнең кулларын күтәрүне үтенгән иде дә, каршы тавыш биреп, кул күтәрүче булмады.

— Битараф кешеләр кул күтәрсеннәр!— диде. Ул да булмады.

Рәис шатлана төшеп:

— Единогласно, то-есть, бертавыштан кабул ителде,— дип игълан итте.

Тагын да гөрләшеп кул чаптылар. Һәм бик күп кешеләр:

— Я, каршы чыгарга көче җитә торган кеше булса, ник хәзер каршы чыкмый?— дигән бер караш белән тирә-якларына, баягы каршы сөйләгән кеше торган урынга карап куйдылар.

Лазарет ачарга карар бирелгәннән соң, аның матди ягын тәэмин итү юлларын эзләргә тиеш икәне хакында рәис сөйләп үтте. Кайбер кешеләр хәзер үк акча җыя

[1] Битарафлар — тавыш бирүдә катнашмаучылар.

башларга тәкъдим иттеләр. Кайберәүләр, акча җыя башлаудан элек, бу эшне эшләп, һәрвакытта алып барыр өчен аерым комиссия сайлауны мәслихәт күреп сөйләделәр. Башта һәр якны яклап сөйләүчеләр булса да, Шакирҗан бай иң элек аерым комиссия сайлауны яклап сөйләгәч, аның бу сүзенә башка байларның бәгъзеләре белән муллалар да кушылгач, моның өчен аерым комиссия сайлау тарафдарларының яклары көчәйде, тавышка куйганнан соң, комиссия ясау ягы өстен чыкты. Җиңелгән яклар мәсьәләне зурга җибәрмәделәр, көлеп каршы алдылар.

Рәис урыныннан торып, колокол шалтыратып, халыкны тынычландырганнан соң, комиссиягә әгъзалар сайлау өчен кандидатлар билгеләүне тәкъдим итте:

— Шакирҗан әфәнде...

— Садыйк абзый Кадриев...

— Карачурин әфәнде...

— Әхмәт әфәнде Шәмсиев...

— Заһир хәзрәт...

— Нәгыйм Садыйков...— дигән исемнәр тезелеп киттеләр.

Боларны берәм-берәм тавышка куйганнан соң, Шакирҗан әфәнде Әлимгулов, Садыйк бай Кадриев, Хәлим әфәнде Карачурин, Заһир хәзрәт һәм Хәйрулла әфәнде Әхмәтов комиссия әгъзаларына сайланган булып чыктылар. Ләкин Садыйк бай белән Кадыйров үзләренең картлыкларын, икенчедән, сәүдә эшләренең күплеген әйтеп, үзләре урынына яшьрәк кешеләрне сайлауны үтенделәр.

Аларның гозерләре халык күпчелеге тарафыннан кабул ителеп, алар урынына башкалар сайланды.

Комиссия әгъзалары сайланып беткәч, шул ук әгъзаларның тәкъдимнәре буенча, шушы җыелышта ук список төзелеп, лазарет ачу өчен акча җыю чарасы күреләә башлады.

Бу эштә Шакирҗан бай беренче булып, биш мең сумга язылды. Бу юлы Садыйк бай белән Кадыйровлар да, Шакирҗан байдан калышуны мәслихәт күрмәделәр, алар да бишәр мең сум яздырдылар.

Хәбиб Нәгыймов та әтисенә киңәш итеп тормый:

— Безнең Нәгыймов фирмасы исеменнән биш мең сум язуыгызны үтенәм...— дип, биш мең сумны яздырды.

Зур байлар артыннан ваграк байлар да үзләренең чамаларына карап иганә бирделәр.

Безнең Вәли бу юлы да үзенең тиңдәшләреннән арттырып, сразы биш йөз сум яздырды.

Лазарет ачу мәсьәләсе хәл кылынганнан соң, агымдагы эшләргә күчтеләр. Ләкин агымдагы эшләр арасында озак тикшереп торырлык зур мәсьәләләр булмаганлыктан, озакка сузылмады. Болар арасында бер ятим карчыкның, бер картның һәм кайдадыр укучы бер шәкертнең ярдәм сорап биргән гаризалары бар иде.

Карчыкка ике сум ярдәм итәргә, шәкерткә бирмәскә һәм картның тормышын тикшерүне җәмгыять идарәсенә тапшырырга карар бирү белән эш тәмам булды.

Рәис җыелышның ябылуын игълан иткәч тә, җыелган халыклар гөруһ-гөруһ[1] булып тарала башладылар. Бара торгач, җыелыш булган биржа залында җәмгыяте хәйриянең идарә әгъзалары белән лазарет ачу өчен яңа сайланган комиссия әгъзалары һәм кайбер байлар гына калдылар.

Безнең Вәли, гади кешеләр таралып беткәч тә, мондагы байлар янында калды. Ул хәзер үзен алар янында йөрергә тиешле кеше, аларның һәммә серләренә төшенергә мөстәхикъ[2] кеше итеп фараз итте.

Электән артык ук таныш булмаган „җәмгыяте хәйрия" эшләренә хәзерге минуттан башлап үзләшкән кебек булып китте. Шушы җәмгыятьнең эшләренә, алда алыначак йортына, ачылачак лазаретка үзенең катнашы бар кебек сизде һәм теге байларның янна рына барып: „Я, тагын да нинди эшләр, нинди киңәшләр бар?.." дигән рәвештә сөальле бер караш белән карап торды. Ләкин алар тарафыннан алай-болай сүз кушучы булмады. Аларның сүз кушмауларын эшләре күплеккә, урыны бу түгеллеккә хәмел кылды[3]. Шунда да киткән вакытта, алар янына барып, һәммәсе белән дә күрешеп һәм „хәзер мине белдегезме?" дигәнсымак булып, аларның күзләренә карады. Берәр сүз әйтүче булмас микән дип, бераз торганнан соң, биржа йортыннан урамга чыкты.

Урамга чыккач, вак товар белән сату итүче Сафига очрап, аның белән сөйләшеп киттеләр. Вак товарчы

[1] Гөруһ-гөруһ — төркем-төркем.
[2] Мөстәхикъ — лаеклы, хаклы.
[3] Хәмел кылды — юрады.

Сафи, аз гына баргач та, сүзне хәзер генә үткән җыелышка борды, байларның һимммәтләренә хәйран калганын сөйләде. Вәлигә карап:

— Син дә зур егетлек иттең, шулай кирәк ул, халык та аптырап китте бит!..— дип, Вәлинең бу көнге иганәсен сөйләп, бу сүзе белән Вәлине күтәреп җибәрде. Ул атлавын әкренәйтә төшеп, Сафига карап:

— Мондый вакытта да шулай итмәгәч, ярыймы инде. Әнә анда Шакирҗан абзый бик дөрес әйтте: без, ди, бу елларда яхшы сату иттек, ди. Бу милләтнең, ди, ятим-җөсерләрен, мәктәпләрен без карамагач, кем карасын, ди. Җәмгыяте хәйрияне шәбәйтергә кирәк, аны шәбәйтер өчен йорт кирәк, ди. Болар барысы да урынлы сүзләр. Чынлап та шулай бит, Сафи абзый... Шундый урында да бераз кесәне кармап карамагач, булмый инде...— дип алга киттеләр.

Алар җыелышта булган хәлләрне, кемнәрнең күпме акча бирүләрен, кайберәүләрнең саранлык күрсәтүләрен сөйләшеп бара торгач, кайтып җиткәннәрен дә сизми калдылар.

Вәли өйгә керүгә, Хәмдия аны:

— Син кайда китеп югалдың? Ашлар суынып бетте!..—дигән сүз белән каршы алды. Вәли Хәмдиягә җавап бирергә бик ашыкмады. Чишенеп, кулларын юып, өстәл янына утыргач кына, сүз башлап:

— Җәмгыяте хәйриянең җыелышы бик озакка сузылды. Хәйран калдырырлык эшләр эшләп ташладык. Йорт алырга, лазаретка акча җыйдык,— дип, җыелыштагы хәлләрне сөйләргә кереште.

Хәмдиянең: „Син дә бирдеңме соң?" дип соравына каршы:

— Ник бирмәскә! Анда шул безнең кебек кешеләрдән акча җыяр өчен, әлеге шундый кешеләрне чакырганнар да инде. Анда бер генә кеше дә акча бирми калмады. Анда акча бирмәгән кеше бармый да, барса да, ана илтифат итүче дә юк. Андый кешеләр, шунда күзләрен мөлдерәтеп, акча биргән кешеләргә кызыгып карап утыралар да, аптырагач чыгып китәләр. Акча булсын да, шундый җиргә бирергә язсын ходай. Кеше арасына керү, абруй арттыру үзе ни тора!

Хәмдиянең: „Күпме бирдең соң?.." дип соравына каршы:

— Алар бит андый зур эшләргә һәрвакыт акча җыеп

тормыйлар. Андый эшләр сирәк була. Шуның өчен мин дә өч мең тәңкә бирдем.

Хатыны аптырап китте:

— Өч мең!.. Ул ни дигән сүз?.. Әллә син тилердеңме?..

Вәли көлә төште:

— Әй, хатын, хатын!.. Син эшнең нәрсәдә икәнен аңламаганга күрә, хәйран каласың. Хәзерге сугыш вакытында ул акча атна-ун көн эчендә артыгы белән кайта ул. Шуның аркасында кеше арасына кереп, зур байлар арасында танылып каласың... Син анда Шакирҗан абзый белән Садыйк байның миңа карашларын күрсәң иде, „нигә күбрәк бирмәдең?“ дип әйтер идең әле. Шакирҗан абзый бер үзе 25 мең сум бирде. Садыйк бай 20 мең сум яздырды.

— Бирсәләр ни, алар бит байлар!..

— Байлар, байлар!.. Ә без ярлымыни соң?.. Син андагы хәлне күрсәң, бу сүзләрне әйтеп тә тормас идең.

Вәли — гәрчә хатыны бик нык аңламаса да — анда Садыйк бай һәм Шакирҗан байларның вә башка кешеләрнең үзенә рәхмәт әйтүләрен, „яңа баеп килгән эшлекле егет“, дип карауларын тагын бер кат сөйләп чыкты да:

— Шулай, хатын, ул якларын мин үзем беләм инде. Хатын-кызларның акылы җитәрлек түгел ул,— дип, сүзен бетерде. Ул хәзер үзенең зур байлар арасына керә башлаганын, игътибарлы кеше булуын уйлап шатлана иде.

IV

„МИЛЛӘТ АТАЛАРЫНЫҢ БӨЕК ҺИММӘТЛӘРЕ...“

Җыелыштан ике көн соң чыккан „Заман“ гәзитендә ул җыелыш турында бик озын бер мәкалә һәм иганә итүчеләрнең исемнәре басылып чыкты.

„Милләт аталарының бөек һиммәтләре“ сәрләүхәсе[1] астында язылган бу мәкалә түбәндәгечә башланган иде:

„Һәрбер милләт үзенең галимнәре, һиммәтле әгънияләре саясендә тәрәккый итә[2]. Бу көнгә чаклы надан-

[1] Сәрләүхәсе — исеме.

[2] Һиммәтле әгъниляләре саясендә тәрәккый итә — булдыклы, эшлекле байлары аркасында алга китә.

лыкта яшәп, артта калган мөселманнар да, хәзер бу сүзләрнең хакыйкать икәнен төшенеп, милләтне тәрәкъкый иттерү юлында төрле чаралар күрә башладылар. Һәр җирдә дини вә дөньяви мәктәп һәм мәдрәсәләр тәэсис иттеләр[1]. Мөселманнары күп булган һәрбер олуг шәһәрләрдә җәмгыяте хәйрияләр ачып, фәкыйрь-фөкара, карт-карчык һәм ятимнәргә ярдәм күрсәтә башладылар. Һиммәтле байларыбыз гәзитләр нәшер итәргә керештеләр. Бу эшләрнең һәммәсе дә милләтебезнең алга китәргә мөстәгыйт[2] бер милләт икәненә зур дәлилдер.

Өченче көн булып үткән җәмгыяте хәйриянең гомуми җыелышында бирелгән карарлар, милләт һәм ватанны саклау юлына кыйлынган олуг иганәләр байларыбызның ни чаклы һиммәтлеләр икәнлеген тагын бер кат исбат итте. Бу җыелыш ватандашларыбыз рус милләте каршында йөзебезне агартырлык рәвештә мәҗрух гаскәриләргә ярдәм итәргә, лазарет ачарга булды. Бу исә безнең һәрвакыт бөек Россиянең хамиләре[3] икәнлегебезне күрсәтәдер...

— Яшәсен милләтнең һиммәтле байлары!..“

Мәкаләнең ахырында:

„Чиксез матур дәвам иткән җыелышта үзләрен милләт алдында мәсьүл дип белә алмаган кайбер кызыл авызлар, эшне чуалту, милләт арасына тәфрика[4] керту, руслар алдында йөзебезне кызарту уе белән юк-бар сүзләр сөйләргә тырышып караганнар иде дә... ләкин халык аларның авызларын да ачтырмады... Андый кешеләргә без милләт исеменнән нәфрәт белдерәбез...“ дигән сүзләр дә бар иде.

Гәзитнең өченче битендә, иганә итүчеләрнең исемнәре аерым кертелеп, түбәндәге рәвештә язылган иде:

„Өченчекөн булып үткән җәмгыяте хәйриянең гомуми җыелышында җәмгыяте хәйриянең йорт алу һәм мәҗрух гаскәриләргә лазарет ачу өчен иганә итүче мөхтәрәм әфәнделәрнең исемнәре һәм иткән иганәләре:

1 — *Шакирҗан* әфәнде . . . . 25 мең сум
2 — Садыйк әфәнде Кадриев . . . . 20 „
3 — Әхмәт әфәнде Сәлимов . . . . 15 „

---

[1] Тәэсис иттеләр — оештырдылар.
[2] Мөстәгыйт — сәләтле, булдыклы.
[3] Хамиләре — яклаучылары.
[4] Тәфрика — талаш, ызгыш, тарткалаш.

4 — Нәбиулла әфәнде Сәлимов . . . . . . 10 мең сум
5 — Сәйфетдин әфәнде Ильясов компаниясе 10 „
6 — Борадәран Галимовлар . . . . 10 „

Болардан соң бишәр, өчәр мең сум иганә итүчеләрнең исемнәре язылып китә. Шулар арасында:

— Яшь байларыбыздан Вәлиулла әфәнде Нигъмәтжанов — 3 мең сум,— дигән сүз дә ялтырап тора иде.

12 нче жирный хәреф белән язылган бу исем-фамилияләрне һәрбер иганә итүче бай берничә рәт карап чыкты. Алар үзләренең дәрәҗәләреннән һәм тоткан урыннарыннан үзләренең исемнәре түбән куелып-куелмавын тикшереп үттеләр.

Шулай ук, Вәли дә, үзенең эре хәреф белән ташка басылып чыккан исем-фамилиясен берничә рәт карап, сокланып утырды. Үзенең исем-фамилиясе шундый зур байлар белән беррәттән гәзиттә ташка басылып чыгуын күреп, шатлыгы эченә сыймады. Хәзер аны һәркем белә, һәркем аңа хәйран каладыр кебек булып күренде.

Үзенең шатлыгын кем белән уртаклашырга белми торганда, аның янына күрше кибеттә сәүдә итүче Солтан Галимов кереп сәлам бирде.

Башка вакытларда Вәли, иптәш сәүдәгәрләргә очрау белән, сүзне сәүдә эшләре, алыш-биреш мәсьәләләре турында башлый иде. Бүген алай итмәде. Галимов белән алай-болай агай-энеләрчә исәнләшкәннән соң, кулындагы гәзитне күрсәтеп:

— Менә, күрше, шуңа гаҗәпкә калып барам әле! Бик кызык бер заманга туры килдек. Җәмгыяте хәйрия җыелышы турында гәзиткә басып чыгарганнар. Хәтта кайсы байның күпме акча бирүенә чаклы язганнар...— дип, Галимов белән үзенең шатлыгын уртаклашырга кереште.

Галимов ул гәзитне, үзе дә иртә үк алып, кесәсенә салып куйган иде. Шулай да гәзитне күргәнен әйтеп тормый:

— Шулай шул, Вәли әфәнде, андый зур эшләрне тиз өлгертәләр инде. Аларның шуннан башка нәрсә эшләре бар. Габидулла абзый Солтановның жалуниягә яллап куйган кешеләре эшлиләр алар...— дип, Вәлинең сүзләренә кушылып китте.

Вәли гәзитнең өченче битен күрсәтеп:

— Менә монда кичә иганә итүчеләрнең берсен дә калдырмаганнар, хәтта аз-маз гына акча биргән мине

дә язганнар, — дип, үзенең күпме акча бирүен Солтанның авызыннан әйттерәсе килде.

— Һимматне күрсәттең инде, күп кешедән уздырдың. Өч мең сум акча аз түгел ул. Андый урында үзеңне күрсәтә белгәч, рәхмәт инде!.. — дип, Вәлинең күңелен тагын да күтәреп җибәрде.

Вәли, Әхмәт байча тамагын кырып, Садыйк байча тавышын калын чыгарып:

— Күп түгел дә бит, ярый инде. Һәркем юрганына карап аягын суза, Шакирҗан абзыйлар кебек баесак, без дә күбрәк бирербез әле, — дип, үзенең байлыкта тагын да үсәргә теләвен белдереп, Галимовның йөзенә карады.

— Күп инде, бу да күп, алла кабул итсен, — диде Солтан.

Шулай кичәге җыелыш хакында байтак сөйләшкәннән соң гына, сүзләрне алыш-биреш ягына бордылар. Кайда нинди товар барын, кемнәрнең, бу арада яхшы сәүдә итеп, зур гына сумада файда итүләрен сөйләшкәннән соң аерылдылар.

Вәли бүген кибетендә көн буенча кәефле йөрде. Гадәт буенча көненә әллә ничә рәт тиргәп ташлый торган малайларын да тиргәмәде. Әллә ничә рәт башка кибетләргә кереп, кичәге җыелыш хакында сөйләшеп, йөреп кайтты. Шуннан соң гына ул үзенең зур иганә итүен һәркем белгәнлегенә, байлар рәтенә кергәнлегенә ышанды...

V

ФАТИХА АЛЫРГА КИРӘК

Кибет ябып кайтканда да шат иде ул. Башка вакытларда һәр көнге сату акчаларын, өйгә кайту белән, башка бернәрсәгә дә карамый, үз кулы белән язу өстәле астына салып бикли, шуннан соң гына юынып, аш өстәле янына килеп утыра да сүз башлый иде.

Бүген өйгә кайтып керү белән, бер төргәк акчаны кесәсеннән алып, эре генә рәвештә Хәмдиягә биреп:

— Мә әле, шул нәрсәне алып, җыеп куй!.. — дип, үзе чишенеп юынырга кереште.

Хәмдия, ире биргән төргәкне тотып карау белән, акча икәнен белде һәм, аның күплеген белер өчен

кулы белән селкеп караганнан соң, мәгълүм акча җыя торган урынга илтеп куйды.

Вәли әле һаман сүз башламаса да, йөзе шат иде. Ул, Хәмдия әйтмиче үк, өстәл янына килеп утырды.

Аштан соң чәй эчкәндә, кесәсеннән бүген чыккан „Заман“ гәзитен алып, авызын пышылдатып, теге мәкаләне укырга керешге. Бераз укыганнан соң, үзеннән-үзе көлеп җибәрде.

Хәмдия, иренең токтымалга көлгәнен күреп:

— Сиңа нәрсә булды? Тик торганда көләсең? — дип соравына Вәли тагын да кәефләнә төшеп:

— Менә гәзит язучыларын әйтәм әле, өченчекөнге җыелышны ташка басып та чыгарганнар!.. Габидулла абзый кушкандыр инде,— диде.

— Нәрсә язганнар соң?..

Хәмдиянең соравы Вәлигә сүз ачарга сәбәп булды. Ул гәзитне өстәлгә куеп:

— Нәрсә дип язсыннар?.. Билгеле инде: бик зур эшләр эшләнде, яхшы байлар бик зур иганәләр бирделәр дип язганнар.

Шуннан соң ул иганә итүчеләрнең исемнәрен укып китте. Үзенең исеменә җиткәч, авызын тагы да зуррак итеп ачып, „яшь байларыбыздан Вәлиулла әфәнде Нигъмәтҗанов — 3 мең сум...“ дигән сүзне укыды да бераз туктап торды. Шуннан соң үзеннән аз сума иганә иткән кешеләрнең исемнәрен әһәмиятсез генә укып чыкты.

Хәмдия тагын әллә нәрсәләр көткән кебек:

— Шул гынамыни?.. Алар сине мактап язсыннар иде,— ди.

Вәли аның сүзенә каршы:

— Шулай язгач та җитәр!.. 15—20 мең сум биргән байларны да шулай язганнар әле. Байлар рәтеннән калдырмый, шулай язулары да аз эш түгел...

Вәли бераз тукталып торганнан соң, бик мөһим бер мәсьәлә кузгаткан кебек сүз башлап:

— Син! Күптән бирле шуны әйтергә йөри идем: агай-энеләр очраган саен, „я, Вәли! Яңа йортны кайчан котлыйбыз?.. Алай ярамый, синең кебек кешегә килешми...“ диләр. Чынлап та, галим-голәмаларны, агай-энеләрне чакырып коръән укытып, фатиха алырга кирәк иде. Әллә алдагы җомгаларның берәрсендә чакырып алабызмы?..

Хәмдия иренең бу сүзен шатланып каршы алды.

— Мин инде аны күптән уйлап йөри идем. Әле беркөн ахирәтләрдә ашта утырганда, абыстай да: „Хәмдия, сезне яңа йорт алган, диләр, бик чибәр, дип сөйлиләр. Я, кайчан күрсәтәсез инде. Мулла абзаң әйтә: Вәли әфәнде үзе белә торган кеше ул, ди. Чакырырга сатуыннан бушый алмый торгандыр, ди. Әллә бик баеп киткәч, фатиха кирәк булмый башладымы?“ — дип йөземне кызартты. Аның сүзенә башка хатыннар кушылып:

— Кирәк, бик кирәк!.. Яңа йорт алып, коръан да укытмагач, ул ни эш була? — дип, колагымны тондырдылар.

Вәли, абыстайның һәм хатыннарның сүзләрен хаклы тапкан кебек, көлә төшеп:

— Әйтерләр шул. Алар кай арада безнең йорт алганны белеп беткәннәр!.. Алай булса, алдагы җомгага чакырып алыйк.

Сүз күпме кунак һәм кемнәрне чакыруга күчте.

Хәмдия элек үзләре шәһәр читендәрәк торган вакытта йөрешә торган таныш-белешләренең исемнәрен телгә ала башлаган иде дә, Вәли аның сүзен бүлде:

— Тукта әле син. Безнең чакыра торган кешеләр бик күп, берьюлы гына чакырып бетеп булмас. Без иң элек: Садыйк бай, Шакирҗан абзый...— дип шәһәрнең иң зур байларын, соңыннан мәхәллә муллаларының исемнәрен санап китте.

Хәмдия мәҗлесне алай бик зурдан — шәһәрнең иң зур байларын чакырудан башланыр дип уйламаган, күрәсең, ул аптырап калды:

— Алай бик зурга китә бит... Алар безгә килерме соң? Без аларның күңелләренә ярарлык кадер-хөрмәт күрсәтә алабызмы соң? — дигән сөальләрне бирде.

Вәли Хәмдиянең бик сайдан йөзгәненнән көлә төшеп:

— Ник килмәсеннәр, чакыргач килерләр!.. Хәзер алар безнең кем икәнебезне беләләр инде. Аш-су хәзерләргә аш остасы хатыннар чакырырбыз,— дип, үзенең сүзен исбат итте.

Эш Вәли теләгәнчә, шәһәрнең зурларын һәм галим-голәмаларын чакырудан башланырга булды.

Вәли сул кулын күтәреп бармакларын җәйде дә:

— Садыйк бай берәү...— дип уң кулы белән сул кулының баш бармагыннан китереп тотты.

— Садыйк абзый берәү,
— Шакирҗан абзый икәү,
— Әхмәтҗан абзый өчәү,
— Хәбиб абзый дүртәү,
— Хәлим Карачурин бишәү,
— Заһир хәзрәт алтау,
— Җиһаннур ахун җидәү...

Болардан соң шәһәрнең വграк байларын, яшьрәк муллаларын, картрак мәзиннәрен әйтә торгач, сул кулының бармаклары берничә рәт саналып чыктылар.

— Сәет абзый белән Шәймәрдән карт калды бит,— диде Хәмдия.

— Тукта әле, яңлыштырдың. Ничәү булган иде соң әле, егерме биш идеме?.. Сәет-мәетләреңне бервакыт чакырырбыз әле. Аларны байлар мәҗлесенә чакырып, мәҗлеснең күркен җибәрергә ярамас. Һәркемнең үз ише бар,— диде дә югарыда саналган кешеләрне кабатлап санарга кереште.

Саный торгач, байлар мәҗлесенә чакырырга мәслихәт, алар янында утырырга муафикъ булган кешеләр кырык өчкә тулды.

Бу саналган кешеләр — шәһәрнең иң игътибарлы затлары, һич булмаса, аларга таныш һәм алар белән алыш-биреш итә торган кешеләр иде.

— Шулай, менә шуларны алдагы җомгага чакырып, мәҗлес уздырырга кирәк. Хәзер аларны чакыруның самай вакыты,— диде Вәли. Шуннан киерелә төшеп, сәгатькә карады да:

— Сәгать уникегә җиткән дә!.. Әйдә, ятарга кирәк, иртәгә эш бик күп,— дип, икенче бүлмәгә чыгып китте.

Вәли бүген урынга яткач та бик озак йоклый алмады. Аның күз алдына „җәмгыяте хәйрия“нең җыелышы, „Заман“ гәзите, Садыйк байлар, Шакирҗан абзалары, алыш-бирешләре... ниһаять, тагын дүрт-биш елдан соң, үзенең дә Садыйк байлар дәрәҗәсендә сумасы, игътибары булган „Вәли бай“ булуы бер-бер артлы килеп үттеләр.

Шулай аның күз алдыннан күп нәрсәләр үтә, ул бик күп нәрсәләрне уйлый, тик алдагы көндә революция булуын, шәһәрнең байлары да, муллалары да, бернәрсәгә кирәкмәгән „җәмгыяте хәйрия“ләре себерелеп ташланачагын гына уйлый алмый иде...

ШАГЫЙРЬНЕҢ АЛТЫН ПРИИСКАСЫНДА

I

Апрель числосы керү белән мәдрәсәдәге бай шәкертләр таралып беттеләр. Тик безнең кебек бай малайларына аш пешереп, чәй кайнатып көн күргән ярлы укучылар гына торып калдылар.

Бай малайлары таралу белән, мәдрәсәдә укулар да туктатылганга күрә, без укусыз да, эшсез дә торып калдык.

Хәзер безнең башка „нишләргә инде, кайда китәргә“ дигән уй төште.

Үткән ел җәй без төрлебез төрле җирдә эшләп йөргән идек.

Мин, Тройцк байларыннан бер байның заемкасында, эшчеләргә аш-су хәзерләп, „кашевар“ булып хезмәт иткән идем.

Быел анда барасы килми. Чөнки анда, бердән, көн саен ике квашня икмәк басып, шуны әвәләп, мичкә салу, зур казан белән аш пешерү, көненә берничә рәт ике чиләк сыешлы самовар кайнату, иртәле-кичле сыер саву кебек вак эшләр ялыктырган. Икенчедән, жалованиесе бик аз — айга биш кенә тәңкә. Ул акчага кием алсаң, ашарга калмый, ашарга тотсаң, шәрә йөрергә туры килә. Быел ничек тә күбрәк акча китерә торган берәр төрле файдалы эш табасы килә.

Тормыш барган саен авырлашты. Безнең иптәшләр берәмләп, икешәрләп тарала башладылар: кайберәүләре йон юарга мойкага, кайберсе берәр байның көтүен көтәргә киттеләр. Бара торгач, без мәдрәсәдә өч-дүрт кенә шәкерт торып калдык.

Һәркөн төрлебез шәһәрнең төрле җиренә йөреп эш эзләп тә карыйбыз, кайда нинди эш барын сорашабыз, ләкин һаман рәт чыкмый: я бөтен җәй буена егерме тәңкә генә бирәләр, яисә вакытлы эшләр генә күрсә-

тәләр. Боларның һәр икәвесе безнең корган планга туры килеп бетмиләр.

Безгә җәй буе өзлексез эшләнә торган һәм ин азында 30—40 тәңкә хосул[1] китерә торган эш кирәк.

Бара торгач безнең тагын берәвебезгә эш табылды: Хәмзә дигән иптәш „ишан хәзрәт“нең[2] куйларын көтәргә көтүче булып керде. Ул иртән китә дә, көн буе көтү көтеп, кичен безнең янга кайта, җитмәсә тагын калган бәлешләр, симез итләр ашавын сөйләп безнең йөрәкне яндыра:

„Ач булсагыз, мә, минем эчемне ялагыз“,— дип, безнең ачуны китерә торган иде.

Без, өч шәкерт, һаман эш эзлибез.

Шулай, беркөн, иртүк торып шәһәр арасына чыгып киткән Зиннәт мәдрәсәгә кичкә таба гына әйләнеп кайтты.

Ул үзе алтын тапкан кебек шатланган, кайтып керү белән:

— Мин бүген базар мәхәлләсендәге мәдрәсәдә укыган якташлар янында булдым. Алар иртәгә алтын казый торган җиргә китәләр, моннан 160 чакрым җирдә „Восьмой“ дигән алтын приискасы бар икән... Аның хуҗалары мөселманнар икән,— дип прииcканы мактап китте һәм үткән ел шул приискага эшкә барган кайсыдыр бер шәкертнең җәй буе эшләгәннән соң, ашаудан арттырып, 40 тәңкә саф акча алып кайтканын, быел да шунда эшкә киткәнен үз күзе белән күреп торган кебек сөйләде.

Без аның бу шатлыклы хәбәрләрен колакларыбызны торгызып тыңладык, хәзер үк „алтын тавы“ тапкан кешеләрчә шатландык:

— Әйдәгез, без дә шунда китәбез!

— Ул прииска кайсы якта икән соң?— дигән сүзләрне әйткәнебезне сизми дә калдык.

Зиннәт аның кайсы якта икәнен һәм анда кайсы юлдан, нинди авыллар аша барырга кирәклеген бик төпчеп сорашкан икән. Ул үзе йөреп кайткан кеше кебек:

---

[1] Хосул — табыш.

[2] Зәйнулла ишан. Ул һәркөн сәдакага дистәләп килгән куйларын көттерергә ел саен махсус көтүче яллый. Куйлар тәмам симергәч, кирәк кадәресен суйдыра, артыгын саттыра иде. *М. Гафури искәрмәсе.*

— Ул приска Верхурал (Верхне-Урал) өязендә икән. Анда кояш баешы ягына карап китәргә, иң элек Берлин, аннан Таротин дигән авылга барырга кирәк икән,— дип, авылларның исемнәрен санап китте һәм,— юл сорарга — тел бар, адашмаска — күзебез бар, нәрсәгә куркып торырга,— дип өстәп куйды.

Мин Зиннәткә:

— Булды, китәбез. Ә соң 160 чакрымга ничә көндә житәрбез икән?— дигән сөальне бирдем.

— Биш көндә житәрбез...

— Ну, алты көн китсен, мәгәр безгә бару белән эш кенә табылсын. Бару бушка китмәсме икән соң?

Зиннәт эш табылуына бик нык ышанган бер төс белән:

— Анда барып кына жит! Барып житсәң, эш була инде ул. Рязе[1] алтын чыккан жирдә эш булмый, мин үзем барам тек барам!— дип, үзенең бер дә шикләнми китәчәген белдерде һәм баягы сүзенә өстәп:

— Анда тагын шунысы бар икән әле; анда шәп яңгырлар артыннан, үткән кыш юылып өелгән балчыклар өстеннән алтын эзләргә чыгалар икән. Шунда кайбер бәхетле кешеләр менә шул чаклы зурлыкта — баш бармагын күрсәтеп — алтын кисәге табалар икән. Шул ук байлар үзләре шул алтынның мыскалын шунда ук ике тәңкәдән сатып алалар икән...

Аның бу сүзләрен ишеткәч, безнең колаклар үрә торды.

— Вот әй, кайда икән шәп кәсеп!

— Бәхеткә каршы, берәр кисәк алтын тапсак, сатарбыз да акчасын уртаклашырбыз, аннан без бай малайларына самовар куеп торудан бөтенләй котылырбыз,— дип, хәзер үк самородок тапкандай шатландык, һәм безнең алдагы көннәр яп-якты булып киткәндәй булды.

Китү турындагы сүз байтакка сузылды. Без Зиннәт белән икәү юллык акча рәтләп алу белән „Восьмой" приискасына китәргә карар бирдек.

Ләкин теге бер иптәшебез никтер киреләнде:

— Юк, мин бармыйм, нигәдер күңел тартмый. Шулчаклы жиргә этләнеп, жәяү барырсың да, эш тапмасаң, нишләрсең,— ди.

[1] Рязе — „разве" сүзеннән алынган.

Без аның сүзенә каршы:

— Сиңа бер җирдә дә пешереп куймаслар инде, син эш эшләргә ялкауланасың. Шундый җирдә эш табылмый калу мөмкинме соң? Әйдә барыйк, ни булса да бергә күрербез,— дип, аны кыстап та карадык, булмады.

— Юк, булмый, үзегез барыгыз, мине нигә көчлисез,— дип, безнең белән барудан бөтенләй кул селтәде. Без инде Зиннәт белән икәү генә китәргә сүз бергеттек тә юллык акча табу мәсьәләсен сөйләргә керештек.

— Берәр тәңкә акча кайдан табарга инде?

Иптәш бераз уйлап торганнан соң:

— Ишан хәзрәттән көзгә чаклы бурычка сорап торыйк, көз кайткач бирербез,— дигән фикерне әйтте. Мин аның бу сүзенә каршы төштем.

— Юк, ул безнең кебек ярлы шәкертләргә бирми, тик аталары бай булган ышанычлы шәкертләргә генә бурыч бирә,— дидем.

— Ну, кайдан алабыз соң?

— Әйдә, укый торган китапларыбызны сатабыз, Фәхри хәлфә шундый нәрсәләрне ала бит.

— Ала торган булса, әйдә сатабыз...

Ике сүздән соң ул үзе укый торган „Мохтасар“ китабын, мин „Шәрхемулла“ны сатарга карар бирдек.

Иртә үк торып, китапларны кулга алдык та Фәхри хәлфәнең йортына киттек.

Ләкин бу баруда:

— Хәлфә абзагыз йоклый әле,— дип җавап бирделәр.

Бераздан соң икенче рәт бардык:

— Яңа гына чыгып китте,— диделәр.

— Инде нишләргә соң?

— Лутчы[1] без аның намаздан чыкканын көтеп торыйк та шунда очратыйк,— дип, аның өйлә намазыннан чыккан вакытын көтәргә булып, мәдрәсәгә кайттык.

Өйлә җитте. Ишанга мөрит булырга килгән суфыйлар, тагы әллә кемнәр өйлә намазына агыла башладылар.

Без икәү „Мохтасар“ белән „Шәрхемулла“ны кочаклап, мәчет тирәсендә әйләнгәләп, Фәхри хәлфәнең чыкканын көтәбез.

---

[1] Лутчы — лучше сүзеннән бозылган.

Көтү бик озак булып күренде. Менә намаздан чыга башладылар.

— Әнә, Фәхри хәлфә дә чыкты.

Без аның кешеләрдән бераз ераклашканын карап тордык та, каршысына чыгып сәлам бирдек. Ул безгә сул күзе белән карагач та, без икәү бердән кулыбыздагы китапларыбызны күтәреп, шул китапларыбызны күрсәттек.

Ул башта:

— Кирәкми, алмыйм,— дип җавап бирде. Ләкин без аның яныннан китми, үзенең күзенә тилмереп карап торганны күргәч, бик салкын рәвештә:

— Күпме сорыйсыз соң?— диде.

Без алдан сөйләшеп куйган план буенча:

— „Мохтасар"га 50 тиен, „Шәрхемулла"га 60 тиен,— дидек.

Хәлфә якын да килмәде:

— „Мохтасар"ның яңасы 70 тиен, „Шәрхемулла"-ның 1 сум бит аның,— дигән сүзләрне әйтте дә йортына карап китә башлады.

Без аптыраншта калдык, аркан белән тартып алып барган кебек, аның артыннан барып, ялынган рәвештә:

— Үзең белеп бир инде, хәлфә абзый!— дип, тагын да аның юлын кистек.

Ул аз гына уйлап торды да:

— Икәвесенә 50 тиен бирәм,—диде.

— Бик арзан була бит, хәлфә абзый.

— Китапларның миңа кирәге дә юк, тик әле сезне кызганып кына 50 тиен бирәм,— диде дә, кызу-кызу атлап алга китте.

Аның шулай алга китүен күргәч, безнең прискага барып эшләп акча алу, яңгыр артыннан баш бармак зурлыгындагы самородоклар табу планнарыбыз бөтенләй җимерелгән кебек булды.

Без бер-беребезгә карашып тордык та, „икәвесенә 60 тиен сорап карыйк, бирми икән, икәвесен 50 тиенгә дә бирербез", дигән уй белән хәлфәнең артыннан йөгереп бардык та, аны тагын туктаттык.

— Хәлфә абзый, икәвесенә 60 тиен бир инде.

— Юк, булмый.

— Ярый, алай булгач, ал инде...

— Мин сезгә күптән тиешле хакын бирдем инде,— дип, безнең китапларны алып, сул як култык астына

кыстырды да, уң кулы белән чапанының итәген кайтарып, портмонетын кесәсеннән тартып чыгарды. Акчасының күплегеннән, аның портмонеты буаз крыса кебек бүселергә, акчалары коелып төшәргә тора иде. Ул шул акчалар арасыннан 50 тиенлек көмешне алып безгә бирде.

Без акчаны алгач:

— Хуш, хәлфә абзый! — дигәч кенә, ул бездән кайда китүебезне сораган булды. Без үзебезнең „Восьмой“ приискасына эшкә китүебезне әйттек.

— Бик яхшы! Рәмиевләр приискасына барасыз икән... Барыгыз, бар, анда сезгә эш булыр. Байларның акмаса да тама бит ул. Хыянәтсез, яхшы хезмәт итегез, байларга туры хезмәт иткән кеше һичбер вакыт хур булмый ул, — дип, безгә „нәсыйхәт“ иткән булып, китапларны култыгына кыстырып, өенә кереп китте.

Без: „Ну, саран да соң, нибары 50 тиен бирде! Ул бит көз көне бездән алган китапларны бер-берсен алтмышар-җитмешәр тиенгә сатар, ә үзе бездән ике китапны илле тиенгә алды... Шулай файда иткән өчен дә, ике катлы йорт салган да шул...

Теге приисканың хуҗалары Рәмиев дигән кешеләр икән... Үзләре алтын казыта торган булгач, ну, байдыр да инде алар... Мондагы Янышевлардан да байлар микән әллә?..“ дип сөйләшә-сөйләшә кайтып киттек.

Юлда ашарга кирәк булыр дип, шундагы кибеткә кереп, бер каравай калач, алты мыскал чәй, бер чирек шикәр алып, мәдрәсәгә кайтып кердек.

Тулган ай кебек балкып торган зур каравай калачның күз алдында торуы авызларыбыздан сулар китерә, тамакларыбызның төбен кымырҗытып тора иде. Ниһаять, без чыдый алмадык, „кайда булса да ашарга алынган калач бит ул...“ дип, чәйнек белән чәй кайнаттык та алтын приискасын сөйли-сөйли чәй эчәргә керештек. Үзебез: „ „Мохтасар“ белән „Шәрхемулла“ акчасына алган калач тәмле була икән!“ дип көләбез. Әзләп кенә ашыйбыз дип ашый торгач, калач яртыга кала язды. Тамаклар туйгач, алтын приискасында эшләүчеләрне, яңгырдан соң самородок „табу“-ларны сөйләшүләр тагы да күңеллерәк булып китте. Без шул күңеллелек астында „иртәгә иртә үк юлга чыгарбыз...“ дигән уй белән, кояш баегач та, ятып йокладык.

II

Иртәнге кояш күтәрелгәндә, без инде, Троицк шәһәрен артка калдырып, Берлингә карап киткән юлдан алга бара идек.

Алтын чыккан җиргә китеп бару болай күңелле булса да, күптән түгел яуган яңгырдан пычранып калган юл белән җәяү баруы башта ук авыр төсле сизелде.

Иске читекләр өстенә кигән яңа чабаталар, ике-өч чакрым җир киткәнче үк, шешенеп, аякларны кыса башладылар. Үзләренең табаннарына бер илле чамасында балчык ябышты. Май башлары булуга карамастан, һава яхшы ук салкын булып, төн ягыннан искән җил, кергезин[1] җиләннәрдән үтеп, тәннәрне чымырдата башлады. Шуның өчен без, бик ашыгып, йөгерәатлый барырга мәҗбүр була идек.

Төшкә таба көн бераз җылыта төште. Шунда без бер күл буена туктап, үзебез белән алган чәйнектә чәй кайнатып, калачлап торып чәй эчеп җибәрдек. Хәзер безгә җан керде. Рух күтәрелде. Без хәлләнеп тагын да алга киттек.

Берлин дигәннәре — зур гына бер рус авылы икән. Ул да артта калды, без бүген, Таротинга җитеп, җылы өйдә кунарбыз дигән уй белән барсак та, булмады. Юлда очраган кешеләрдән сорашып, ул авылның моннан 20 чакрымнар чамасында икәнен белдек тә юлдан ерак түгел генә сабан сөреп йөргән кешеләр янына бардык. Алар шул тирәдәге бай бер кыргызның[2] хезмәтчеләре булып чыктылар. Без алар белән аманлашканнан (исәнлек-саулык сорашканнан) соң, шулар янында кунып китәргә карар биреп, аркаларыбыздагы капчыкларны алып куеп, аларның чәй кайнатырга яккан утлары янына җылынырга утырдык. Ярты сәгать эчендә алар безнең кемнәр икәнебезне һәм кайда баруыбызны әнәсеннән җебенә чаклы сорашып беттеләр. Безнең алай-болай шикле кешеләр түгеллегебезне белеп алгач, үзләренең яннарына чәйгә утырттылар. Чәйдән соң без чабаталарыбызны чишенеп, читекләре-

---

[1] Кергезин — бәз шикелле гади материянең бер төре.

[2] М. Гафури бу әсәрендә казах халкын, Октябрьга кадәрге төшенчә буенча, кыргыз дип тә атый.

безне салып, утка каршы утырып, чыланган чолгауларыбызны киптереп, яңадан киендек. Безнең аякларның кай җирләре читекләрнең ямаулы җирләренә туры килеп кабарган, кайбер урыннары чиләнеп киткәннәр иде. Теге хезмәтче кыргызлар, безне кызгана төшеп, аякларыбызга сөртергә сары май бирделәр. Сары майны сөртеп, җылы чолгауны урагач, рәхәт булып калды.

Безнең ятарга теләвебезне сизү белән алар тагын безнең хәлгә керделәр. Астыбызга коры печән җәеп, өстебезгә ябынып ятырга калын киез бирделәр.

Бу өч ялчы кыргызлар, үзләре шушы хәлдә торып, бер байның ялланган батраклары[1] булуларына карамастан, дәртле, күңелле егетләр булып чыктылар. Аларның берсе — араларында иң яшьрәкләре, шунда торган бәйләүле атка сикереп менде дә, сабан сөрә торган үгезләрне сугарырга алып китте һәм, бераз китү белән, озын көйгә салмак кына иттереп үләң (җыр) әйтә башлады.

Аның иркен күкрәгеннән чыккан тавышы тирә-якка таралып, моңлы һәм яңгыраулы авазы тын даланы уятып, җанландырып җибәрде. Ул үзе бездән ераклашып, чиксез киң сахрадагы караңгылыкка кереп югалса да, тавышы һаман ишетелә, бездән ерагайган саен тавышының моңы арта бара иде.

Икенче берсе арбаны йөзтүбән куеп, өстенә печән ябылып ясалган куышсымак нәрсәнең түбәсенә кыстырып куйган думбырасын алып чыгып, ут каршысына килеп, аякларын бөкләп җиргә утырды. Думбырасының кылларын бераз рәтләгәннән соң, күзләрен югарыга күтәрә төшеп, думбыра чиртә башлады.

Бу вакытта аның утка каршы ялтыраган кара күзләрендә ялкынлы дәрт һәм ниндидер бер моң уйнап торган кебек була иде.

Егетләрнең өченчесе — карап торуга әүвәлге ике егеткә караганда яшькә зурраклары — көпесен[2] аркасына яба төшеп кырын ятты һәм кесәсеннән шакшасын[3] алып, тезенә бәргәннән соң, пробкасын ачып сул як кулы-

---

[1] Ул вакыта без „батрак" дигән сүзне белми, аларның изелүләрен аңламый идек әле. Бу сүзләр хәзергә карап алынды. Ихтимал, инде ул егетләр бу көндә авыл советларында яки волисполкомнарда эшлиләрдер. *М. Гафури искәрмәсе.*

[2] Көпе — куй йонныннан сырып теккән тун кебек кием.

[3] Шакша — вак тәмәке сала торган савыт — шешә.

ның очына бер чеметемдәй насбай[1] алып, авызын югары күтәрә төшеп, аскы ирене белән тешләре арасына салып җибәрде дә янган утка карап уйга калды.

Үгезләр эчерергә киткән егетнең тавышы бик еракташ өзек-өзек булып кына ишетелә. Шуның белән бергә, ниндидер бер киңлекне, әллә нинди бер иркенлекне искә төшерә иде.

Думбыра уйнаучы егетнең кулындагы думбыраның кыллары телләнделер, алар үзләреннән үзләре, уйнаучы егетнең дәртен, аның эчен, эчендә булган тойгыларын берәм-берәм санап бирә торган җанлы бернәрсәгә әйләнеп, сөйләп торган кебек тавышлар чыгара башладылар.

Мин бөтенләй җиңеләеп киттем. Бүген иртәдән кичкә чаклы җәяү йөрүдән килгән авырлыклар беткән кебек булды. Чыдый алмадым, башымны күтәрә төшеп, аның дәрт белән думбыра чирткәнен, шул вакыттагы ягымлы кыяфәтен карап ята башладым.

Насбай салган егет, урыныннан кузгала төшеп, янган утны рәтләде, читтә яткан агач башларын утның өстенә салды да, баягыча тагын кырын ятты.

Ул телләнеп арлы-бирле селкенеп янган утның ялкыннарына карап нәрсәдер уйлый, үзе бер дә сүз әйтми, иптәшенең думбыра уйнаганын тыңлый иде.

Думбырачы егет, бераз уйнаганнан соң, башын тагын да күтәрә төште дә, кылларны чиртүен туктатмый, аерым бер дәрт белән:

Былбыллар пәрәз итеп очар гөлдә
Шыгарыр хафаларын бар көнелдә,
Әркемдең өз кайгысы өзенә артык:
Дугадак чүлдә, акко, каз, үрдәк күлдә...
Аса толпар җөргән шакта аяңдамас,
Биртелмәс таска тию менән алмас.
Арсланга тиң килерлек буз балалар
Досманга очрасканда көч аямас[2]
. . . .

---

[1] Насбай — көл белән махорканы кушып төйгән тәмәке. *М. Гафури искәрмәләре.*

[2] Бу үләндәге кайбер казахча сүзләрнең мәгънәләре: пәрәз — очмак, дугадак — һәрвакыт сусыз сахраларда гына көн күргән кош, акко — аккош, аса толпар — яратылышта ук гадәттәге атлардан аерым хасиятләр белән яратылган шәп ат. Казах, башкортлар арасында толпар турында бик күп легендалар бар. Аяңда — атларның атлау белән юырту арасындагы йөрешләре. Буз бала — яшь егет. Аямас — кызганмас. *М. Гафури искәрмәсе.*

Егет шундый шигъри сүзләрне туктаусыз тезеп алып китте. Аның тавышы барган саен күтәрелеп югарылана, думбыраның кылларыннан тезелеп чыккан өзек-өзек авазлар бергә ялганып, көйгә киләләр дә, тагын егетнең тавышына кушылып, тыңлаган саен тыңласыны китерә торган бер рәвешкә кереп, тирә-якка таралалар иде.

Думбыраның тавышларыннан дәрт тә, ярсыну да аңлана, сүзләреннән бертөрле кысынкы тормыштан ялыгу, икенче бер тормышка талпыну да, үзенең башкалар белән тигезсезлегеннән ризасызлык, ләкин күкрәгендә бу тигезсезлектән чыгарлык көче барлык та сизелә иде.

Ул шулай байтак үләң әйтеп думбырасын чирткәннән соң туктады. Ул туктагач, караңгылык эченнән болай таба юыртып килгән ат аягы тавышы ишетелә башлады һәм, озак та үтми, теге үгезләр сугарырга киткән егет кайтып, ат өстендә көенчә утка каршы тукталды.

Мондагы егетләр аның өстенә карап:

— Нәмәнә бар, үгезләрне сугардыңбы?— диделәр. Теге егет:

— Атаңа нәләт, анау сыйдың буендагы челек маңыпан кашкырмы-нәмәдер бер карачкыл җай гына китеп җатыр. Кулымда суйлым булмады гуй. Үзенең әкәсен танытыр идем![1]— дип сөйләнә-сөйләнә, атыннан төшә башлады.

Думбырачы егет аңа каршы салкын кан белән генә:

— Кашкыр имәс, каңгырып җөргән эт шыгар: монда кашкыр нә кылсын,— диде. Өченче егет:— Кашкыр булса да гаҗәп имәс, мондагы малларды аңып йөри торган шыгар. Тик ул сурлы үгезләргә бер нимә дә кылмайды гуй,— дип бүредән куркыныч юклыгын белдереп куйды.

Теге егет атын шундагы арбага бәйләп куйды да, камчысын биленә кыстырып, ут каршысына килеп чүгәләде.

Аның йөзеннән нинди дә булса төгәлләнмәгән бер эше яки нәрсә дә булса башкарырга уйлаган бер теләге барлыгы күренә иде.

---

[1] Сай — чокыр җир. Кашкыр — бүре. Әкә — ата.

Насбай салган егет аның шулай утыруыннан бернәрсә аңлаган кебек:

— Нәгып сөмрәеп утырырсың, атыңның ияр-тукымнарын[1] ал да, уттарга (ашатырга) куя бир,— диде.

Думбырачы егет калҗың (мәзәк) рәвешендәрәк:

— Бүген дә Иркә-җаный җанына барин дип уйлап утыратын шыгар.

Бу сүздән соң теге егетнең йөзе ачылып китте:

— Барып кайтаен дип идем, сездәр ни дисез?— дип боларга карады.

Иптәшләре аның теләгенә каршы төшмәделәр һәм икәвесе бердән:

— Үзеңде аңдып торучылар булмасын, байлар күрә калмасындар, иртән таң саргаюга күлек[2] җигәр мизгелгә килеп җит,— дигән тәнбиһләрне бирделәр.

Егет, аларның бу сүзләрен ишетүе белән, атына менде дә, тыпырдатып, киң даланың караңгылыгы эченә кереп югалды. Тик бик еpактан аның ай-һай салып үлән әйтүе беразга чаклы ишетелеп торды.

Мин эчемнән ул егетнең Иркә-җан исемендәге сөйгән кызын күрергә киткәнен уйладым.

Думбырачы егет, тагын шул ук дәрт белән бераз думбыра уйнаганнан соң, иптәше тагын бер рәт насбай салып алганнан соң, йокларга ятып, яткан җирләреннән, үзләренең ялчы булып хезмәт иткән байлары, көндәлек эшләре һәм аралаш-аралаш хатын-кызлар турында сөйләшергә керештеләр. Мин, бер яктан, аларның сүзләрен тыңлап, икенче яктан, төрле уйлар уйлап ята торгач, йоклап киткәнмен.

Иртәнчәк теге кыз янына киткән егетнең, „айт-һайт“ дип, үгезләрне сабанга җигәргә куып алып килү тавышына уянып киттек. Бу вакытта аның иптәшләре дә торган, өсләренә киенеп, сабан сөрергә китәргә әзерләнеп беткәннәр иде. Алар теге егеткә:

— Җул булдымы, Иркә-җаныңды күрдеңбе?— дигән сөальне бирделәр. Боларның сөаленә каршы:

— Булды!— дигән җавапны бирде.

Без дә урыннарыбыздан торып киендек, алар бездән тыныч йоклавыбызны сораштылар һәм без киенеп,

---

[1] Тукым — ияр астына салына торган киез. *М. Гафури искәрмәсе.*

[2] Күлек — сабан сөрергә атларны яки үгезләрне җигеп эшкә башлау. *М. Гафури искәрмәсе.*

аркаларыбызга капчыкларыбызны асып, үзләре белән рәхмәт әйтеп күрешкәч, безгә юл өйрәтеп җибәрделәр. Без алардан аерылганда, кояш яңа гына чыгып, сабан тургайлары югары күтәрелеп сайрый-сайрый уйнарга керешкәннәр иде.

Бүген үткән көнгә караганда көн җылы һәм тымык; юл сурыкканга күрә, йөрү җиңел булды. Аякларның кабарган һәм чиләнгән җирләре башта авырткан кебек булсалар да, бара-бара кызып, авыртулары сизелми башлады.

Бүген көндез елга буенда чәй эчеп, хәл җыйдык та, Таротин авылына тукталмый үтеп, кичкә каршы Яманчал авылы дигән бер кыргыз авылына җитеп, ярлы гына бер кыргыз өенә кунарга кердек.

Без кыргызларның үзләренә генә махсус булган гореф-гадәтләрен һәм мөсафир кешеләрнең йорт хуҗасы белән ни рәвешле мөгамәлә итүләре тиеш икәнен рәтләп белмәгәнгә күрә, күңелсез бер хәлдә, тартынкырап торган идек тә, өй хуҗасы моны сизеп, борынгы танышларча мөгамәлә итә башлады. Чәй эчерү белән генә калмый, алар безгә ит тә ашаттылар. Күптән күрмәгән итне туйганчы ашау безнең өзелгән йөрәкләребезне ялгап җибәргән кебек булды.

Ул бездән күп нәрсәләр сорашты һәм бу авылның Яманчал авылы дип исемләнүенә сәбәп шул авылдагы зур-зур яшел түбәле йортларның хуҗасы Исмәгыйль Яманчалов[1] дигән байның булуыннан килеп чыкканын һәм аның ниһаять дәрәҗәдә комсыз, ярлыларны җәберләп, куркытып эшләтүче бер кеше икәнен сөйләде. Туйганчы ит ашап, җылы өйдә юрган ябынып (алар безгә ябынып ятырга юрган да биргәннәр иде) яткач, без таң атып кояш чыкканын сизми дә калганбыз.

Без торгач, ул үзенең без бара торган якка бер йомыш белән барачагын һәм безне утыртып алып китәчәген әйтеп, безне тагын шатландырды. Китәргә ат җиккәч, без аның хатынына үзебезнең актык 20 тиен акчабызны бирмәкче булган идек тә, ул:

---

[1] Исмәгыйль Яманчалов — кыргызларның миллионерыннан булып, аның Тройцк шәһәрендә йортлары, каядыр алтын приискасы һәм күн заводлары бар иде. Бу авыл шуның төп авылы икән. *М. Гафури искәрмәсе.*

— Уй-бай, бу нә кылган эш! Кесе мосапирлардан акша алучы идәбе, — дип, безнең акчаны алмады. Без, ул хатынга рәхмәт әйтеп, аманлашып чыктык та, арбага утырып алга киттек.

Шәп кенә атка утырып, төрле сүзләр сөйләшеп бару безнең юлны кыскартты, 25 чакрым җир киткәнебезне белми дә калганбыз.

Ике юл чатлыгына җиткәч, безне алып килүче Аманбай атын туктатты да:

— Сез, усы юл мән туры карап, алга җөрә биреңез, анау түбәнең артында бер урыс авылы булыр. Мин монау юл мән китәмен, — дип, безне арбасыннан төшерде дә, үзе безнең белән исәнләшеп, атына утырып, сул якка киткән юл белән алга китте. Без аның артыннан карап калдык.

Без барган саен „Алтын тавы"на якынлашабыз, 100 чакрым җир килдек инде дип шатланабыз һәм Тройцкидан чыккан вакытка караганда да күтәренке рух белән алга барабыз.

Шулай бара торгач, ул көнне кич ниндидер бер керәшен авылында кунып чыкканнан соң, иртәгесен көне буе йөреп, кичкә каршы „Восьмой" приискасына барып җиттек. Капчыкларыбызны аркаларыбызга аскан көенчә, бик озын бер казармага барып кереп, ишек төбендәрәк бер җиргә басып, тирә-якка каранып: „Инде нишләргә, монда тәртип ничек?!" дигән уйга калдык...

III

Без кергәндә, казармада ямау ямап, яшь баласын имезеп, камыр басып, кер юып, җырлый-җырлый кечкенә сандыкларын актарып утырган берничә хатын-кызлар, һәртөрле җиргә таралып уйнап йөргән эрелеваклы берничә дистә балалар гына булып, алар башта безнең керүебезгә игътибар итмәделәр.

Без, кемгә сүз кушарга белми, бераз аптырап торганнан соң гына, аларның күзләре безгә таба ташланды.

Бездән ерак түгел генә камыр басып торган бер хатын безгә әйләнеп, күзләрен тутырып, безгә бераз карап торды да, онлы кулын алъяпкычына сөртә-сөртә, электән таныш кеше төсле:

— Апайларым, сезгә кем кирәк иде? — дигән соальне бирде.

Без үзебезнең эш эзләп килүебезне һәм казармага кунарга керүебезне әйткәч, ул хатын:

— Ә, алай икән! Әллә сезнең монда танышларыгыз бармы? — дип сорады.

Баласын имезеп утырган яшь кенә хатын безнең җавап биргәнне көтеп тә тормый:

— Монда семьялы кешеләр генә торалар (кулы белән тәрәзә аркылы икенче якка күрсәтеп), сез әнә теге буйдаклар тора торган казармага барыгыз, анда урын күп, — дип, безгә икенче казармага барырга тиеш икәнен әйтеп бирде.

Хатыннар белән безнең арада сүз башлангач, теләсә кайда таралып йөргән балалар, безнең янга килеп, тирәләй сырып алдылар. Араларыннан берсе артык җәсарәт[1] күрсәтеп, минем янга ук килеп, кулымдагы таякны тотты. Минем кулымдагы таяк чынлап та балаларны кызыктырырлык һәм аларга ат-ат итеп уйнар өчен бик муафыйк иде. Ул таякны үзенә таба тарта башлагач, таякны аның кулына бирергә мәҗбүр булдым. Ул малай, таякны эләктерү белән, казарманың икенче башына таба шылды. Аның артыннан башка балалар да йөгерделәр.

Камыр басучы хатын безнең кайдан килүебезне, кемнәр икәнебезне белүне бик кирәксенгән рәвештә:

— Сез кайдан килдегез, үзегез кемнәр буласыз соң? — дип төпчеп сорашырга кереште.

— Без Тройцкидан килдек, кыш көне анда укыган идек, хәзер эш эзләп монда килдек әле, — дигән җавабыбызны ишеткәч, ул төсен үзгәртә төшеп, шәкертләрнең прискага эшкә килүләренә гаҗәпләнгән сыйфатта:

— Ә, ә, шәкертләр икәнсез! — диде, соңында үзендә бер нindидер җитешсезлек булганын сизгән төсле, башындагы яулыгын рәтләп, тирә-ягына карап алды.

Бала имезүче хатын, урыныннан торып, үзенең ачык күкрәген яба-яба:

— Сез кайсы як кешеләре буласыз соң? — диде дә, безгә туп-туры карап, җавап көтә башлады.

— Мин — Уфа ягы, ә бу иптәш Златоуст ягыннан була.

Камыр басучы хатын, безнең бу сүзебезне ишеткәч, тагын да кызыксына биреп:

[1] Җәсарәт — батырлык.

— Уфа ягыннан икән!.. Алай булгач, безгә якташ буласыз бит. Син кайсы авыл соң? Без үзебез дә Уфа ягыннан, Бәләбәй өязеннән булабыз,— дип, үзенең миңа якташ икәнен белдереп куйды.

— Мин Эстәрле өязе (. . .) авылының булам...

Безнең сүзләр шушы җиргә җиткәндә, җырлый-җырлый, сандыгын актарып утырган хатын да, җырлавыннан туктап, безнең янга килде. Ул, үзенә кирәкле бер сүз ишетәсе килгән бер рәвештә, безнең сүзләрне бик дикъкать белән бераз тыңлап торганнан соң, миңа карап:

— Синең әллә Кучкар приискасында да булганың бармы? Мин сине күргән төсле булам,— диде.

— Юк, анда булмадым.

— Алдашма, син анда торган идең бит!..

Аның бу сүзеннән соң никтер мин уңайсызланып киттем. Аның токтымалга „алдашма“ дип әйтүе миңа авыр булып тоелды. Башкалар да минем турыда шиккә төшкән кебек булып күренделәр.

Мин:

— Нигә алдашыйм, анда барган булсам, дөресен әйтер идем,—дип, үземнең Кучкар приискасында булмаганлыгымны исбат итеп сөйләргә мәҗбүр булдым. Иптәшем Зиннәт тә:

— Юк, ул анда барганы юк,—дип минем яктан төште.

Шулай да теге хатын, безнең сүзгә ышанмаган рәвештә миңа караган шикелле, карашын үзгәртмәде һәм:

— Мин сине кайдадыр күргән төсле булам,—дип, үзенең ачык калдырган сандыгы янына барып, әйберләрен рәтләргә кереште.

— Даң-даң-даң!

Эшчеләргә эштән туктарга вакыт икәнен белдереп, колокол кагылды. Шуннан соң безнең белән сөйләшеп яки безне карап торган хатыннар да кайсысы мич тирәсенә, кайберсе үзләренең урыннарына киттеләр.

Камыр басучы хатын, без казармадан чыгып киткәндә дә, тагын да безгә әйтәсе сүзләре яки сорашасы нәрсәләре булган кебек, безнең артыбыздан карап калды.

Буйдаклар казармасы бу казармага якын иде. Без бу казармадан чыгып анда таба карап барганда, эшлә-

реннән туктаган эшчеләрнең төрле яктан шушы казармаларга таба агылып килүләре күренә иде.

Без туп-туры „буйдаклар казармасы“на барып кердек. Бу казарма үзенең озынлыгы, тәрәзәләренең сирәк һәм кечкенәлекләре, мичләренең солы кибәне кебек җәелеп салынулары, шуның белән бергә тәбәнәклеге ягыннан караганда, нәкъ семьялы кешеләр торган казарма төсле булса да, эчендәге күренеш ягыннан бөтенләй башка иде. Аның җирме, тактамы икәнлеге беленмәгән идәнендә, ничә көннәрдән бирле җыелып килгән тәмәке төпчекләреннән башка, анда-монда ыргытылган иске чабаталар, балчык белән кызарган аяк чолгавы өзекләре, ашарга ярамаганлыктан ташланган балык (вобла) башлары, тагын әллә нинди чүпләр көрәп алырлык булып күбәйгәннәр иде.

Казарманың ике як стенасы буйлап киткән тычкан башы ярылырлык ялангач сәкеләре, күптән бирле адәм кулы якын бармаган ала-кола тәбәнәк мичләре, тышкы яктагы нәрсәләр күренмәслек дәрәҗәгә килгәнче тузанланып каткан тәрәзәләре, „бу казармада күптән бирле адәм заты тормый торгандыр“, дип әйтерлек ямьсез бер күренешне күз алдына китерәләр иде.

Чынлап та, без, ул казармага барып кергәч, үзебезне әллә нинди ташландык, куркынычлы бер хәрабәгә кергән кебек сиздек, монда ялгыш килеп кергәнбездер дигәнсымак бер уйда калдык... Казарманың кайсыдыр бер почмагыннан ишетелгән: „Уф-уф, ай-ай!“ дигән сызланулы ыңгырашулар һәм аңа каршы:

— Я, нәрсәгә балалар төсле чыдамсызланасың!— дигән сүзләр ишетелмәсә иде, без бу казармадан кире чыгып киткән булыр идек.

Без шөбһәләнә төшеп, шул тавышлар чыккан якка карап алга атладык. Хәзер безнең күзләр казарманың моңсу караңгылыгына ияләшә төштеләр: стеналарга кагылган арба кендеге юанлыгындагы агач чөйләргә эленгән капчыклар; шүрлекләргә куелган кечкенә агач сандыклар; тышлары бер карыш катып каралганлыктан, нәрсә икәнлекләре беленмәслек бер хәлгә киленгән кечкенә мендәр кебек әйберләр һәм башка иске кием затлары күзгә чалына башладылар.

— Анда кем йөри? — дигән тавышка без сискәнеп киттек һәм тиз генә шул тавышның иясе янына барып җиттек.

Хәзер безнең алдыбызда кызыл түбәтәен башына кыңгыр салып кигән, күптән бирле алдырмаган чәчен сул як чикәсенә каратып аударган, уң кулының бармаклары арасына махорка, сул кулының бармаклары белән озын гына мыекларын бөтереп утырган таза гына бер егет утыра иде.

Ул безгә башын күтәреп карады да, никтер бер сүз дә әйтми, безнең сүз башлауны көткән кебек, үткер күзләрен безгә терәде.

Шул вакытта теге авыру тагын да: „Уф, уф! Монысы миңа булсын, уф, хәлем бетте бит“,—дип ыңгыраша һәм саташа башлады.

Без, икебез дә, саташып авырып яткан кеше ягына караганыбызны сизми дә калдык.

Мич артындагы почмакта, ялангач сәкегә җәелгән иске бишмәт өстендә, аунап яткан авыруның гәүдәсе хәзер безгә ачык күренде.

Теге таза егет авыруга карап:

— Яткан җиреңнән самородок таптыңмы әллә? Монысы миңа булсын дисең. Самородок синең төшеңә генә керә торгандыр, өнеңдә тапсаң да, аны синең кулыңда тотмаслар! — дип сөйләнә-сөйләнә, урыныннан торып, авыруның янына барды һәм аның баш астындагы җечкенә һәм, караеп, әвәләнеп беткән мендәрен рәтләп куйды да:

— Су эчәсең киләме? — дип сорады.

Авыруның „килә“ дигән җавабын көтми үк, тәрәзә төбендә утырган, сыланып каткан кара тимер чәйнектән калай кружкага су салып:

— Мә, эч! Төшеңдә алтын казып, шахтада йөреп сусагансыңдыр,—дип алдына китерде.

Авыру бераз гына аңына килгән кебек булды да, күтәрелеп суны берничә рәт йотканнан соң, кире урынына ятты.

Таза егет, кире безгә таба борылып, авыруның хәлен безгә белдерергә теләгән бер сыйфатта:

— Шахтада эшләгәндә авырды да, шуннан терелә алмыйча ята. „Тир“ [1] авыруы булса кирәк. Шуны карап мин дә эшкә чыга алмадым, ул терелсә, бу каһәр прискадан китәр идем,—дип урынына килеп утырды.

Беренче күрүдә безгә куркыныч сыйфатлы күренгән

---

[1] Тиф авыруын әйтә. *М. Г.*

бу таза егет хәзер ару гына күренә башлады. Шуннан соң гына без аннан:

— Бу казармада безгә дә кунарга ярый торгандыр бит?— дип сорадык.

Ул һаман да йөзенә ачыклык чыгармый, кемгәдер ачуы бар кеше төсле:

— Бу казармада сезгә түгел, этләргә дә кунарга ярый. Күрәсез бит: эт абзары кебек,— дигән җавапны бирде һәм сүзен йомшата төшеп:

— Әллә сезнең моңарчы приискаларда булганыгыз юкмы?— дигән сөальне бирде.

— Юк!

— Туты шул!

— Сез үзегез монда күптән эшлисезме?

Ул сүзне озынга җибәрергә теләмәгән рәвештә генә:

— Күптән түгел, мин бүген монда, иртәгә анда! Себердән башлап Уфага чаклы мин күрмәгән приискалар калмагандыр инде!..

Таза егет белән безнең арадагы сүз шул җиргә җиткәндә, көрәк, кәйләләр күтәргән эшчеләр, берәмләп-икешәрләп, казармага кайтып керә башладылар.

Алар кергәч, казарма җанлана төште. Алар кәйлә, көрәкләрен сәке асларына, мич башларына ыргытып, күн бияләйләрен анда-монда кыстырып, кайберсе чәйнекләрен асып чәй кайнатырга чыгып киттеләр, кайберәүләре вак балчык тулган чабаталарын чишеп, аларны кагып, өс-башларын тузаннан әрчергә керештеләр. Аларга безнең барлыгыбыз-юклыгыбыз барыбер кебек булып күренгән булса кирәк: алар безгә карап-карап үтсәләр дә, бер сүз дә кушмадылар.

Иртәдән кичкә чаклы забойда эшләп, хәлдән таеп, шундый ямьсез күренешле, күңелсез бер казармага кайтып кергән кешеләрнең шулай булулары гаҗәп түгел!..

Эшчеләр кайтып, казармада икенче бер төрле хәрәкәт башлангач, без алардан буш калган бер урынга утырып, капчыкларыбызны сәкегә куеп, бер-беребезгә караштык. Бу вакытта иптәшем нәрсә уйлагандыр— миңа мәгълүм түгел.

Мин үзем: —Менә тормыш! Алтын чыга торган җир шулай була икән... Соң болар нигә бер дә рәтләнә алмаганнар? Әллә болар самородок тапмаганнардыр...

Теге таза егет әйткәндәй, самородок боларның төшләренә генә керә торгандыр яки өннәрендә тапкан булсалар да, боларның кулларыннан тартып ала торганнардыр, — дип уйлый идем...

Эшчеләрнең кайберләре үзләре чәй кайнатып эчәргә, кайберсе бәрәңге ашарга утырдылар.

Без әле мондагы тормышка өйрәнеп, төшенеп җитә алмаганга күрә, чәй кайнатып тормый, су белән Троицкидан алып чыккан күмәчнең калдыгын ашап ятырга уйладык та күмәч салган капчыкның авызын чишәргә керештек.

Эшчеләр чәй янына утыргач, күңелләләнә төшеп, үзләренең эшләре турында сөйләшергә керештеләр.

Хәзер кояш баерга якынлашып, аның соңгы яктылары, казарманың тузанлы тәрәзәләре үтә каршы стенага төшеп, моңлы бер күренеш ясыйлар иде.

Шул вакытта теге таза егет шүрлектә торган гармонен алып, аны сынап караган кебек телләрен тиз-тиз басып төрле тавышлар чыгарганнан соң, кыска гына дәртле бер көйгә уйнап җибәрде.

Шуннан ерак түгел генә чәй эчеп утырган икенче бер егет:

— Әйдә, әйттер! Безнең өчен гармонь моңлансын! — дип өстәп куйды.

Без, капчыктан күмәчне алып, инде ашыйбыз гына дип торганда, каршыдагы ишектән матур гына бер карт кереп, кулын маңлаена куеп, кемнедер эзләгән кебек карый да башлады. Эшчеләр бабайга карап:

— Сәлим бабай, нәрсә карыйсың, кемне югалттың? — дип сорагач, бабай үзенең бик яраткан танышларына сүз кушкан төсле:

— Монда яңа гына килгән ике егет булса кирәк, шуларны эзли идем, — диде.

Теге кеше кулын безгә таба сузып:

— Алар әнә тегендә утыралар! — дип безне күрсәтте.

Бу вакытта байтак эшчеләрнең күзләре безгә текәлгән иде.

Бабай безгә таба карап борылгач, без, кулларыбызга тоткан күмәч сыныкларын капчыгыбыз өстенә кире куеп, бабайның килгәнен көттек.

Ул безнең янга килеп безне бер кат карап алды да, исәнләшеп, сәкегә утырды һәм тиз генә арада кайдан килүебезне, кайсы яктан икәнлегебезне сорашып үтте. Без аңа теге казармадагы хатынга биргән җавапларыбызны бирдек.

Шулай сөйләшкән арада, икебезнең уртабызда яткан капчыкка һәм аның өстендәге күмәч кисәкләренә күз төшереп алды.

— Шулай икән! (Миңа карап.) Син безгә якташ буласың икән. Мин үзем дә асылда Бәләбәй өязенеке булам, — дип, үзенең миңа якташ икәнлеген белгәннән соң:

— Юлда арып килгәнсездер бит, нигә чәй эчмисез? — дигән сөальне бирде.

Мин аңа каршы:

— Приискага килеп җитәр алдыннан яланда күптән түгел генә чәй эчкән идек, хәзер эчәсе килми инде, — дидем.

— Хәер, яшь чакта ничек тә ярый инде, талымлап торып булмый. Шулай да эчү кирәк иде. Булмаса, әйдәгез безнең казармага. Анда әзрәк сөйләшеп утырырбыз, — дип, безне үзенең торган казармасына чакырды.

Без назланып тормадык; капчык белән икмәк һәм чәйнекне шунда калдырдык та, бабай белән бергә, теге семьялы кешеләр тора торган казармага барып кердек.

Хәзер бу казармада бая без кереп чыккан вакыттагы тынлык югалган, кырмыска оясы кебек мыжгып торган бертөрле тормыш башланган иде.

Һәрбер квадрат чамасы җиргә бер семья урнашып, ашар-эчәр өчен әзерләнгән урыннардан башка бөтен җирләре төрле яшьтәге, төрле төс, төрле сыйфаттагы кешеләр белән капланып, болар үзләренең шул казармага каратылып корылган кечкенә, ялыктыргыч тормышлары эчендә кайнашалар, иртәгә иртә үк торып эшкә китәргә хәл җыяр өчен, ашап-эчеп, ятарга хәзерләнәләр иде...

Бабай, безне үзе артыннан ияртеп, озын казарманың бер башындагы мич артындагы почмакка алып барды.

Бу почмак никтер башка җирләргә караганда аз гына иркен, шуның белән бергә, ару гына җыештырылган һәм стена буена төрле корамалардан теркәп

тегелгән тар гына юргансымак нәрсә җәелгән иде. Бабайның йөзе тагы да ачыла төште.

— Әйдәгез, түрдән рәхим итегез әле! — дип, безгә түрдән урын күрсәтте. Без кыяр-кыймасрак, чабаталарыбызны чишенеп, сәке өстенә менеп утырдык.

Бабай сүз башлап:

— Баягынак сез монда кереп чыккансыз икән, җиңгәгез әйтә: „Тройцкидан, ди, ике шәкерт эшкә килгән, ди, үзләре безнең якташлар икән“,— ди. Шуннан соң, тукта, боларны чакырып сөйләшеп утырыйм әле дип, сезне алып килдем. Шулай, менә безнең тормыш шушы инде. Барына риза булып торган булабыз. Җәен тагы бер хәл, эш тә җиңеләя төшә, тормыш та арулана. Кыш көне кыенрак була.

Казарманың чамасын күрсәткән рәвештә кулын сузып:

— Менә шул казармада ун-унбиш семья торып кара әле!

Бабай сүзен шул җиргә җиткергәч:

— Я, син чәеңне әзерләп җибәр әле! — дип, артына әйләнеп карады.

Аның шул сүзеннән соң, без бу казармага беренче рәт кергән вакытта камыр басып торган һәм, безнең белән сөйләшеп, артыбыздан карап калган җиңги килде дә, безнең белән тагын да исәнләшеп, чәй урынын хәзерләргә керешә.

Чәй урыны тиз хәзерләнде. Ашъяулык өстенә шикәр, күмәчтән башка, крендель белән ярты кадак чамасы йөзем җимеше дә куелды.

— Менә шушы приискада гына ун ел эшлим инде,— дип, үзенең үткән эшләрен сөйләп киткән бабай, капыл гына сүзен өзеп:

— Я, егетләр, рәхим итегез әле! — дип, безне ашарга өндәде һәм җиңгигә карап:

— Әйдә, утырып чәеңне ясый башла инде!.. Хәдичә кайда, ул да килсен, читтән килгән кунаклар белән сөйләшеп утырыйк, — дигән сүзләрне өстәде. Бабайның әйтүе белән җиңги, самовар янына утырып, чәй ясап бирә башлады.

Бабай чыдамады, тирә-ягына карап алганнан соң, бездән ерак түгел генә җыелышып утырган бер төркем хатын-кызлар арасына күзен төшереп:

— Хәдичә, әйдә, монда кил, нәрсәгә дип килмисең тагы? — диде дә безнең барыбызга да карата:

— Чәй эчсен, дим, көн буе алтын юып эштән чыгып арып кайта. Иртәгә тагын эшкә барырга кирәк, — дип куйды.

Хәдичә әтисенең сүзен кире какмады, ул, бераз гына ояла төшкән рәвештә, әнисенә каршы, самоварның икенче ягына килеп утырды. Ул безнең белән исәнләшмәгән кебек, без дә аның белән исәнләшергә кыймадык. Хәтта башта Хәдичә монда килеп утыруына уңайсызланган кыяфәт күрсәтте, без дә үзебездә ниндидер күңелле бер уңайсызлык сизгәндәй булдык.

Сәлим бабай, безнең уңайсызланганыбызны сизеп, шуны бетерергә теләгән кебек:

— Безнең монда хатын-кызлар яшеренеп-пошырынып тора алмыйлар инде. Урыны шулай булгач, ни эшләмәк кирәк. Шәһәр җирләрендәге эшләми генә торган хатын-кызлар яшеренеп йөрсәләр дә, безнең монда ул эш мөмкин түгел. Ирләрдән качып, нәмәхрәм дип йөрсәң, эш эшләми, ач калырга кирәк, — дигән берничә сүз белән, муллаларның башларын ваткан „хиҗап“ [1] мәсьәләсен әйтте дә бирде.

Аның бу сүзләре безне уңайсызлап торган пәрдәне күтәреп җибәргәндәй булды.

Хәдичә күзләрен тутырып безгә таба бик тирән карады да тагын да күзен түбән төшерде.

Без һаман да ачылып, сөйләшеп китәрлек сүз таба алмыйбыз. Сәлим бабай бу сүзсезлекне үзе генә бетереп бара, ул тагын:

— Җирле җирендә, җикән күлендә дигән кебек, һәр җирнең үзенә карап торырга туры килә... Шулай, бая сез монда кереп чыккансыз икән, җиңгәгез әйтә: Тройцкида укучы шәкертләр эшкә килгәннәр, ди, үзләре безнең якташлар икән, кем белән сөйләшергә белми аптырап торган кебек торалар, ди. Шуннан мин әйтәм: алар алай моңаеп тормасыннар, үзләрен чәйгә алып килим әле, дим. Мин үзем дә шулай, яшьтән үк ятим калып, кешегә эшләп үстем. Шуннан эш эзләп читкә чыгып киттем. Башта шулай сезнең кебек кыен булды. Кем белән сөйләшергә белми аптырап торам, бара-бара өйрәнеп китәсең аны... Ягез, чәйдән, нигъмәттән рәхим итегез әле!..

[1] Хиҗап — качу, битне каплап йөрү.

Туктаусыз рәвештә ашъяулыкның почмагын бер бөтереп, бер язып утырган Хәдичә, хәзер тагын да иркенәя төшеп, мәҗлескә табан әйләнкерәп утырды. Хәзер аның тулы йөзе, кара кашлары астындагы зур гына кара күзләре янтыктан түгел, бәлки капма-каршы күренәләр иде...

Сәлим бабайдан соң җиңги:

— Мин ни бая, болар килгәндә, камыр басып тора идем. Рәтләп сорашып та булмады. Үзебезнең якташлар килеп чыксалар рәхәт булып кала. Үзебезнең якны күргән кебек булып калам,— дип үзенең туган-үскән ягын һаман да исеннән чыгара алмаганын белдереп куйды.

Минем:

— Үзебезнең Уфа ягын сагынасыңмыни, җиңги? — дип соравыма каршы:

— Сагынмыйммы соң? Урак урган, печән җыйган җирләрем күз алдымнан китмиләр. (Сәлим бабайга ишарә итеп.) Менә аның исенә дә кереп чыкмый, өч ятып, бер төшенә дә керми ичмасам! — диде.

Сәлим бабай көлә төшеп:

— Инде ул җирләр онытылып беткән. Туган җирдән туйган җир яхшы, диләр. Сагынсаң, тагын кайда барасың?..

Мин Хәдичәнең сүзгә катнашуын көтми идем, ләкин бер дә уйламаганда ул да:

— Безнең әти инде ул шушы приисканы үлсә дә ташлап китмәс, авылга кайтыйк инде дисәң, монда да бик яхшы бит әле, безгә анда да әзерләп куймаганнар, дип кенә куя,— дигән сүзләрне әйтте дә, никтер үзе дә кызара төшеп, ашъяулыкның почмагын тотып, тагын да бөтерә башлады.

Аның тавышы ягымлы һәм бик ачык иде... Аңа каршы Сәлим бабай:

— Балам, безгә кайда да бер инде. Кара сакалың кайда барсаң да артыңнан калмас, дигәннәр. Мин илне сагынмыйм, тик сине тагын да бераз укыта алмый калуга кайгырам... Менә монда зуррак кызларны укытырга мәптек тә юк бит! — диде.

Хәдичә елмая төште дә:

— Мәктәп, диң, әти,— дип, әтисенең сүзен төзәтеп куйды һәм шул ук минутта безгә күзен төшереп алды.

— Безнең кебек надан кеше китапча сүзләрне дөрес әйтә алмас инде, балам,— диде Сәлим бабай.

Бу вакытта Сәлим бабайларга күрше торган семьялар да мондагы сүзләрне тыңлап утыралар иде.

Шуннан ерак түгел уртача яшьле берәү:

— Безне укыта торган мәптәкләр ачылмаганнар әле, без үлгәч кенә ачылырлар алар,— дип куйды.

Казарманың икенче ягындагы кешеләр ята башладылар, ул яктагы бала-чагаларның чыр-чу килгән тавышлары басыла төште. Яңарак кына яндырылган өчле, бишле лампалар сүндерелеп, казарманың ул як башы караңгылык эчендә калды.

Мин:

— Сезнең кызыгыз укыган төсле күренә,— дидем Сәлим бабайга.

Бабай тагы ачылып китте:

— Болай яхшы гына укыган укуын. Бәләкәй чагында авылда укыган. Мин үзем ул вакытта читтә йөри идем. Монда килгәч тә Гарифә абыстасыннан укып йөрде, тик ул мәрхүм вафат булгач кына туктады. Бөтен казармага килгән хатларны Хәдичә укый, һәм кешегә дә Хәдичә хат яза. Болай үзенең китаплары да бар. (Шүрлеккә күзен салып.) Әнә анда аның китаплары,— дип, Хәдичәнең укымышлы булуын белдергәннән соң:

— Берәр китабыңны алып бир әле! Шәкертләр укып карасыннар,— дип, Хәдичәгә китап алып күрсәтергә дә кушып өлгерде.

Хәдичә, китапларын күрсәтергә уңайсызланган кебек, урыныннан кузгалмыйрак торгач:

— Алып күрсәт, балам, гыйлемнең ояты юк,— дигән сүзен кабатлады.

Аның шул сүзеннән соң гына Хәдичә урыныннан торып, калын гына бер китапны алып, мәгънәле рәвештә генә елмаеп, минем кулга бирде.

Мин ул китапны ачып карау белән, аның „Сөбателгаҗизин“ китабы икәнен белдем.

Китапның исеме өстендә: „Ошбу китап ияси, яңы күлмәк кияси Хәдичә бинте Сәлим кызыдур“,— дип, үзенең исемен язган, китапның исеме астына: „Ошбу китапның хакы илле тиендер“,— дип, китапның бәясен язып куйган иде.

Китап тышындагы үзенең кулъязмасын укыганда, Хәдичә күзләрен бер түбән төшереп, бер миңа, бер әтисенә карап, кызара төшеп утырды.

Мин башка нәрсә әйтергә дә белми:

— Бу китапларны укый белгәч, бик ярый инде,— дидем. Шуннан соң Хәдичә күңелләнеп киткәндәй булды. Хәтта китаплар турында бераз сөйләшкәч, ул тагын да ачыла төшеп:

— Сез нинди китаплар укыйсыз соң? Анда сезне зур укыта торганнардыр инде?— дигән сүзләрне әйтте. Без дә үзебезнең укып үткән һәм хәзерге көндә укып йөргән китапларның исемнәрен әйттек. Безнең сүзләрдән Хәдичә дә, аның әтисе белән әнисе дә гаҗәпләнгән рәвештә безгә карап тордылар.

Иң соңыннан иртәгә безгә ни эшләргә кирәклеге мәсьәләсенә күчтек.

Сәлим бабай күп уйлап тормый:

— Байлар алар үзләре Орымбур каласында торалар, монда җәй көннәрендә килеп-китеп, кызык күреп кенә йөриләр. Аларның монда Ислам һәм Харис дигән управляющийлары тора. Ләкин алар да борыннарын бик югары тоталар. Күреп карарсыз, нәрсә әйтерләр. Ләкиннәһү[1] көнлеккә яллый торган Иван Василичны күреп сөйләшсәгез, сезнең өчен лутчырак булыр. Исән булсагыз, эш табылыр әле,— дип, безнең күңелне юатты. Шуннан соң без, түрдән төшеп, чабаталарыбызны киеп, исәнләшеп, „буйдаклар казармасына“ киттек.

Саф һавага чыккач, безнең күңел тагын да күтәрелеп китте, иптәшем уйламаган җирдән бернәрсә тапкан кебек, капыл гына:

— Матур бит, әй! — ди.

— Кем?— дим.

— Хәдичә!

— Ул матур да бит, безнең эшләрнең башка яклары ямьсез бит әле, эш булса ярар иде, бөтен җәйне шунда үткәрер идек,— дим.

Без казармага кергәндә, теге авыру янында гына өчле лампа яна, үзе тирәсендә торган ике кешенең йөзләрен күрсәтә ала. Башка җирләр бөтенләй караңгы булып, эшчеләрнең мышнап йоклаган тавышлары гына ишетелә иде.

Без капчыкларыбыз янына килеп аякларыбызны чишендек тә, астыбызга кыска җиңле бишмәтләребезне,

---

[1] Ләкиннәһү— ләкин.

баш астына бүрекләребезне салып, өстебезгә җиләннәребезне ябынып, йокларга яттык.

Авыру һаман сызланып уфлый, саташа һәм кайвакытта бер дә тавышсыз гына кала иде.

Шунда аны карап торган кешеләрнең:

— Бу егет бик начарлана бит, малаең әллә шытырга итәме?!.

— Хәле начар начарын да, шулай да чыкмаган җанда өмет бар бит,— дигән тавышлары ишетелеп, мине тагын да күңелсезләндерде.

Бу вакытта казарманың төрле җирләрендә төнге чикерткәләр туктаусыз кычкыралар, сәке асларыннан крысалар йөгереп үтәләр, чыелдашалар, кичтән арып яткан эшчеләр мышнап йоклыйлар; теге авыру саташып җибәрә,— шулар һәммәсе бергә җыелып, күңелсезлек һәм соң дәрәҗәдә авыр җанлылык бирәләр иде.

Шунлыктан мин бик озак йоклый алмый, тәрәзәдән күренгән айга карап ятарга мәҗбүр булдым...

Казарма таң белән бергә уянды.

Күзне ачып карау белән: тынчу һәм яртылаш караңгы казарманың төрле почмакларында, йокылары туймый торган эшчеләрнең яткан урыннарыннан торып иснәп утырулары һәм анда-монда ялт-йолт итеп яктырып киткән тәмәке утлары күзгә ташландылар.

Мин үзебезне шушы мал абзары кебек казармага кич килеп беренче төн кунуыбызны, мондагы күңелсез тормышны һәм үткән кич семьялы эшчеләр тора торган казармадагы күренешләрне уйлап алдым. Шул ук минутта Хәдичә дә күз алдымнан үтеп киткән кебек булды.

Озак үтмәде, казармада хәрәкәт көчәйде. Эшчеләр урыннарыннан торып, кыштыр-кыштыр киенеп, керепчыгып йөри башладылар.

Без дә урыннарыбыздан торып, инде нишләргә кирәклек турында сөйләшеп, эш сорап конторага барырга хәзерлек күрә башладык.

Бездән ерак түгел берәү безнең үзара сөйләшүебезне тыңлап торган күрәсең, ул безгә карап:

— Ну, сез кайда барырга җыенасыз? Тотыгыз да конторага барыгыз. Анда көнлекләп эшләргә яллыйлар,— дип, безгә юл өйрәтергә кереште.

— Үзебез дә шунда барырга уйлап торабыз. Анда эш бирәләр микән соң?

— Күп вакытта эш була торган, тулке анда сайланкырап ала торганнар инде. Сез эшкә әләгә алырсыз микән?

— Барып карыйбыз әле, әллә эш булып куяр...

Ул артык сүз әйтмәде. Тартып утырган трубкасын берничә рәт көчәнеп-көчәнеп суырды да, трубкасыннан төтен килмәгәнен белгәч, авызыннан алып, сәке казнасына кагып, көлләрен төшергәннән соң, аны тәмәке янчыгына урап, кесәсенә салды һәм урыныннан торып, мич башына ташлаган көрәк белән кәйләсен алып, нигәдер аларны әйләндереп-әйләндереп карый башлады.

Без аның „тулке анда сайланкырап алалар...“ дигән сүзенә төшенмәдек һәм ул сүзнең мәгънәсен сорап та тормадык.

Эшчеләр, ун-унбиш минут эчендә киенеп бетеп, көрәк, кәйләләрен күтәреп, икешәрләп, өчәрләп казармадан чыгып эшкә таралдылар. Аларны эш көтә... Аларның эш кораллары кулларында... Алар эш эзләп йөрми, туры барып, эшләргә керешәчәкләр... Шуның өчен алар безгә караганда бәхетлеләр булып күренделәр.

Казарма тагын тын калды. Теге озын чәчле таза егет, авыру эшчедән ерак түгел, йоклап ята, авыру эшченең бүген никтер тавыш-тыны беленми... Күрәсең, ул төн буе сызланып хәзер генә йокыга киткәндер.

Без казармадан чыгуга, иркен, саф һава безне үзенең кочагына алган кебек булды. Яңа үсеп килгән яшь үләннәрнең төчкелтем исләре танауга бәрелде. Әле үзе чыгып өлгермәгән кояшның югары сирпелеп торган кызыл катыш саргылт нурлары каршы алды... Казармадан ерак түгел өем-өем булып тезелеп киткән сары балчык тезмәләре үзләренең араларында зур-зур алтын кисәкләрен яшереп яткан төсле булып күренделәр. Семьялы эшчеләр тора торган казарманың ишек алдындагы хатын-кызларның тавышлары колак төбеннән үтеп китте. Алар арасында Хәдичә дә бар иде. Ул да, башка хатын-кызлар кебек эш киемен киенеп, алтын юарга китәргә хәзерләнгән, алтын комнарын юа-юа ялтырап, көмеш кебек булып беткән тимер көрәген уң кулына тотып, уңга-сулга әйләндерә, үзенең иптәшләрен көтә иде.

Без хатын-кызлар ягына таба бер генә күз ташладык та, Хәдичәләрне күрмәмешкә салынып, конторага

таба юнәлдек. Чөнки егет башы белән әле яңа контора алдына эш эзләп бару, шулар төсле көлешә-көлешә эшкә китми торып, аларның күзләренә күренү никтер уңайсыз кебек булып күренде...

Без конторага барып җиткәндә, контора алдында күбрәге яшь хатын-кызлардан, калганнары авыл крестьяннары киемендәге ирләрдән булган зур-зур төркем халык, эш көтеп, контораның ачылганын көтәләр иде. Без дә шулар рәтенә барып, чиратка торган кебек, бер читкә аяк бастык.

Монда җыелган хатын-кызларның өсләрендәге киемнәре, авыл рус хатын-кызларының киемнәре кебек булса да, үзләренең татарча бик оста сөйләшүләре мине бик кызыксындырды. Мин башта татарча сөйләшкән „марҗалар“ны күреп гаҗәпләнсәм дә, соңыннан боларның приискадан өч чакрым җирдә булган керәшен авылының хатын-кызлары икәнлекләрен белгәч, „татарча белгән марҗа кызларының“ кемнәр икәнен төшендем...

Озак көттерми, контора ишеге ачылып, таза гәүдәле, зур мыеклы, ялтыравыклы күзле, өстенә күн бишмәт (тужурка), аягына озын кунычлы итек кигән бер кеше чыгып, күтәрмәгә басты.

Эш эзләп көнлеккә килүчеләр бер минут эчендә бу усал кыяфәтле кешене әйләндереп алдылар. Без иң артта торып калдык.

Яллаучы, көнлеккә килүчеләр өстеннән күзен йөртеп алганнан соң, кайберәүләрнең исемнәрен әйтеп, кайберәүләрен бармак белән төртеп күрсәтеп, төрлесен төрле эшкә җибәрә башлады. Эшкә билгеләнгән кешеләр шунда ук үзләренә күрсәтелгән эш урыннарына киттеләр.

Байтак кешеләргә, шулар рәтеннән безгә дә эш җитми калды. Эшкә яллаучы артык бер сүз дә әйтми, конторага кереп китте. Без авызыбызны ачып, аның артыннан карап калдык...

Язгы кояш тау артыннан көлеп килеп чыкты. Аның беренче нурлары каршыдагы биек сырт өстенә, җир астыннан казылып чыгарылган кызыл балчыкларга, аннан соң конторадан ерак түгел, бик матур һәм иркен итеп салынган яшел түбәле йортларның зур-зур тәрәзәләренә төштеләр. Кояш кемгә карап көлә торгандыр — анысын без белмәдек... Конторага каршы өелгән бүрәнәләр өстенә барып утырдык та, үзебезнең

эш эзләп килүебезне әйтеп, хәлебезне сөйләп, бүгеннән берәр эш бирүен сорамакчы булып, управляющийның чыкканын көтәргә керештек.

Бездән соң безнең янга аркасы чыккан, сул кулы зәгыйфьләнгән бер карт килеп утырды. Ул, гадәт буенча, безнең кемнәр икәнебезне, кайдан килүебезне сорашып алды. Без дә аның кайсы як кешесе икәнен һәм нинди эштә булуын сораштык. Шулай сорашу аның өчен дә, безнең өчен дә кирәкле бер эш булып тоелды.

Ул үзе каравылчы икән...

Каравылчы икәнен әйткәннән соң, уфлап куйды да, асылда үзенең Казан губернасыннан булуын, аннан чыгып китүенә кырык елдан да артык гомер үтүен әйтеп үтте.

— Кырык ел!

Бу гомер, безнең кебек яшь кешеләргә чиксез күп бер гомер булып күренде. Аның кырык ел буена читтә йөргәнен уйлап алганнан соң:

— Кайтканың бармы соң? — дидек.

— Егерме еллар элек кайтып килгән идем, шуннан соң кайтканым юк. Анда инде минем кардәш-ыруларым да юк, анда кайтып ни эшлисең? — диде дә, үзенең япа-ялгыз бер карт икәнен исенә төшергән кебек, җыерчыклы йөзенә үкенү һәм кайгы билгеләре чыгарып куйды.

— Кырык ел күп гомер шул. Ул гомер эчендә күп җирләрне күргәнсеңдер инде, бабай? — дидек.

Ул, үзенең эчендә сакланган вакыйгаларның авыр җәрәхәтләрен безнең белән уртаклашасы килгән бер сыйфатта, үзенең тарихын сөйләп алып китте.

Ул, Урал эчендәге заводларның берсендә ун ел хезмәт иткәннән соң, Кучкар приискасындагы алтын шахталарында егерме биш еллар забойщик булып эшләүләрен, анда эшләгәндә, забой ишелеп, бер көн тәүлеге җир астында ятканнан соң гына казып алуларын, шуннан соң бервакыт таш астында калып сул кулының сынуын, шуннан зәгыйфьләнеп, башка эшкә яраксыз булып калганлыктан, моннан биш ел элек шушы приискага килеп, каравылчылыкка ялланып, шуннан бирле каравылчы булып тамак туйдыруын әрнүле рәвештә сөйләп бирде дә:

— „Кеше күрәсен күрми, гүргә керми“, — дигәннәре

дөрес икән, тагын әллә ниләр күрәчәгем бар,— дип, кояш нуры астында күмелгән яшел түбәле йортларга карады һәм алар өстендә рәнҗешле күзләрен йөртеп алганнан соң:

— Яшь вакытларны сагынам, карт көнемдә көзге, кышкы, янгырлы, буранлы озын төннәрне шул йортларның әйләнәсендә йөреп уткәрү миңа яшь чагымдагы сиксән аршин тирәнлектә булган шахталарда таш ватып йөрүләрдән дә авыр... Ул вакытта мин уйның, кайгының нәрсә икәнен дә, ару-талуны да белми идем. Хәзер шул йортлар әйләнәсендә йөреп арыйм. Төннәр буе уткән гомерләрне уйлап уткәрәм,—дип, тагын шул йортларга карап алды.

Бабайның кыяфәте безгә тагын да кызганычрак булып күренде. Аның сүзләрен тыңлап утыру бик-бик авыр булып бәрелде.

Без үзебез дә аның уткәргән авыр тормышының йөрәгендә калдырган җәрәхәтләрен сызлатмаслык, аның моңнарын уртаклашырлык бернәрсә дә таба алмадык. Артык бернәрсә дә әйтергә белми:

— Шулай инде,. бабай... Ә соң ул йортларда кемнәр торалар соң?—дигән сөальне бирдек.

Бабай, бераз сүзсез торганнан соң, кулын йортларга таба сузып:

— Әнә ул йортларның иң зурысы ел буена кешесез тора. Андагы әйберләр бозылмасын өчен, кыш буе тиккә ягып чыгалар. Ул йорт җәй көннәрендә, байлар үзләренең семьялары белән кунак булып килгән чакларда гына ачыла. Алар монда килеп, ике-өч атна торып, эшләрен карап, „Балкан“ приискасындагы имениеләренә китәләр... Калган йортларда прискаларның управляющийлары, конторщик-мазарлары торалар.

— Байлар нинди кешеләр соң?—дидек.

— Аларның нинди кешеләр икәнен каян беләсең?.. Болай читтән карап торырга бик кәттә егетләр күренәләр. Гәүдәләре балавыз шәм кебек туры булып тора. Гомер буйларына аркылыны буйга алып салмаган кешеләрнең гәүдәләре шулай булмый ничек булсын? Алар безнең урында берәр генә ай эшләп карасыннар иде, көянтә кебек бөгелеп төшәрләр иде...

Бабайның йөзенә ачу билгеләре чыкты:

— Куй инде аларны!—дип, үзе дә сизмәстән кулын селкеп куйды.

— Үзләре белән сөйләшеп караганың юкмы соң?

Бабай, безнең нәрсәдер аңлый алмаганыбыздан аптырагансыман, безне мыскыл иткән төсле көлә төшә дә:

— Рәзве байлар, безнең кебек кешеләрне сагынып, безнең белән сөйләшеп торалар?.. Байлар түгел, аларның сәнәктән көрәк булган конторщиклары да безнең кебек кешеләр белән рәтләп сөйләшмиләр. Әле беркөн, жалуниямне 15 сум ясагыз дигән идем:

— Бабай, син байларның санаусыз маллары бар дип беләсеңме әллә? Биргәнгә канәгать итеп, шул урынында тора бир инде. Әле без сине кызганып торабыз. Югыйсә, ул урынга керүченең исәбе юк... — дип, үземнән көлделәр генә. Байлар алар үзләренең этләре белән көлә-көлә уйнасалар да, безгә бер сүз кушарга да гарьләнәләр...

— Күпме жалованье аласыз соң, бабай?

— Унике сум...

Сүз шунда җиткәндә, кечкенәрәк яшел түбәле өйнең эчке яктан этәргән бер кул белән тәрәзә канатлары ачылып киттеләр.

Тәрәзә ачучы кешенең иң элек ап-ак беләкле кулы, аның артыннан ике як иңенә ябырылып төшкән кап-кара чәчләре уртасында ай кебек балкып торган йөзе күренде.

Тәрәзәне ачучы кеше яшь кенә матур хатын иде.

Ул тәрәзәдән башын чыгара төшеп, нәрсәдер эзләнгән рәвештә, ишек алдына карап алды. Аннан соң күзләрен без утырган якка ташлады да, кулы белән өйнең кояш чыгышы ягына ишарә итте. Соңра колачын аера төшеп, учларын җәеп, тагын да кулларын бергә китереп кушты да артка чигенде.

Без аның бу ишарәсеннән бернәрсә дә аңламадык.

Аның җылы түшәктән яңа гына торган гәүдәсен күргәннән соң, иртәнге салкын белән өшеп, куырыла төшкән тәннәр, әллә нинди җылылыкны искә төшергән кебек, чымырдап киттеләр.

Каравылчы бабай ул хатынның ишарәсен шунда ук аңлады:

— Ул миңа кояш чыгышы ягындагы тәрәзәләрне ябарга куша. Алар кояш яктысыннан да качалар, йоклый алмыйлар. Бер уянгачтан, тагын ничек итеп ятасылары килә икән? — дип, сукрана-сукрана торып китте

дә, кулындагы таягын коймага сөяп, тәрәзә капкачларын ябарга кереште.

— Гомергә эшләгән... төн буе каравылда йөргән карт!..

— Кояш нуры астында йоклый алмаган назлы хатын!..

Бер-берсенә капма-каршы булган бу ике төрле тормыш күңелне болгандырып җибәрде.

Күрәсең, картның эшен төнге каравылчылык белән генә чикләми, аңа башка хезмәтләр дә кушалар.

Карт, тәрәзәләрне япканнан соң, тагын безнең янга әйләнеп килде дә:

— Сез, егетләр, берәр кешене көтәсезме әллә? — дип, безнең монда утыруыбызның сәбәбен сорады.

— Әйе, управляющийны көтә идек...

— Ул бит кичә „Балкан“[1] приискасына китте. Икеөч көнсез кайтмас.

— Алай икән... Без аның үзен күреп, эш сорамакчы идек.

— Сез лутчы Иванны күреп карагыз. Ул күпне күргән кеше, сезгә эш бирер.

— Аны кайда күреп була соң?

— Ул, иртүк торып, яңа ачылган шахталарны карарга киткән иде, завтракка кайтыр.

Без бүрәнәләр өстеннән тордык та, бабай белән исәнләшеп, шуннан ерак түгел, вашгердлар[2] тезелгән буага карап юнәлдек.

Буа тирәсенә рәттән тезелгән вашгердлар янында алтын юучы хатын-кызлар һәм ирләр мыжгып эшлиләр иде.

Без, читтәрәк торып, аларның эшләүләрен карап тордык. Рәттән, һәрвакыт приискада торып эшләүче семьялылар казармасындагы хатын-кызлар белән бергә Хәдичә дә бар иде.

Аларның машиналашкан куллары тимер торбадан агып төшкән суларны уйнаталар, чыкырдап торган таш катнаш балчыкларны тимер иләкнең бер ягыннан

---

[1] „Балкан“ — Рәмиевләрнең күп прискаларыннан берсенең исеме. *М. Г.*

[2] Вашгерд — суны кулы белән тартып, алтын комын простой юл белән юа торган, тимер иләкле, авызы ачык зур ящик кебек бернәрсә. Вашгердта гадәттә өч кеше эшли. Машиналашкан җирләрдә бу ысул бетә бара. *М. Гафури искәрмәсе.*

икенче ягына йөгертеп, өйрәнмәгән тешләрне чагылдыралар иде.

Эшсез көенчә эшләгән кешеләргә карап тору уңайсыз булганга күрә, без күбрәге строительләр тора торган землянкалар арасыннан урап, баягы уңайсыз казармага кайтып, аның эченә керәсе килми, ишеге төбенә утырып киңәшкә керештек.

— Я, инде нишләргә? — ди иптәш.

— Нишләргә, бүген эш булмаса, иртәгә булыр әле.

— Ә бит безнең бер генә ашарлык күмәч бар. Аның белән нәрсә эшли алабыз?

Безнең күзләребез бер-берсенә караштылар да, телләр сөйләүдән туктадылар.

Без шулай уйда торганда, теге таза егет, ике кадак чамасы крендель һәм башка нәрсәләр алып кайтып, казармага керәм дигәндә, безне күрде дә, каршыбызга килеп туктады:

— Сезгә бүген эш булмадымы әллә, нәрсәгә аптырашып торасыз?

— Бүген булмады, иртәгә буламы — юкмы, аны да белеп булмый әле...

— Алай булса, менә моннан биш чакрым җирдә „Иванов“ приискасы бар. Тотыгыз да шунда барыгыз. Ул яңа ачылган прииска, анда эш күп. Иптәшем авырмаган булса, мин дә шунда китәр идем. Авыру иптәшне кем кулына калдырып китәсең? Чорт возьми, бүген дә эшкә чыгып булмады.

Җитез егет, шул сүзләрне әйтте дә, ашыгыч рәвештә казармага кереп китте.

— Ну, нишлибез? — ди иптәш. — Тотарга да, шул егет әйткән приискага китәргә кирәк. Базар мәхәлләсеннән киткән безнең якташлар да тәгаен шундадыр...

— Иң элек чәй эчеп алыйк әле. Аннан карарбыз.

— Мин үзем шунда китү ягында, монда эш буламы, юкмы дип көтеп торганчы, анда барып эшләргә керешербез.

— Мин китмәү ягында, анда да безнең баруыбызга эш әзерләп куймаганнардыр...

Без шулай икебез ике фикердә калып, чәй кайнатырга керештек.

Ул арада, завтрак вакыты җиткәнен белдереп, кыңгырау сугылып, звонок булды.

Чәй янында иптәш Зиннәт „Иванов“ приискасына

китәргә, анда эш булса, миңа хәбәр итәргә, булмаса, кире кайтырга, ә мин хәзергә монда торырга карар бирдек.

Мәсьәлә тиз өзелде: чәй эчеп беткәч тә, ул үзенең буш капчыгы белән чәйнекне аркасына асып, „Иванов“ приискасына китте, мин казарма янында калдым...

Эшсез дә, ялгыз да торуы авыр. Шуңа күрә, казарма янында әйләнгәләү тиз ялкытты. „Ник соң болай җансыз торырга, эзләнергә кирәк“... дидем дә, туптуры приисканың конторына киттем.

Мин конторага барып кергәндә, каравылчы карт тәбәнәгрәк уйчан гына бер рус белән нәрсәдер шунда сөйләшеп тора иде. Ул теге рус белән сүзен бетерде дә, миңа карап:

— Мин әйткән кеше шушы була инде, үзенә әйттегезме әле?

— Юк!

— Иптәшең кайда соң?

— Ул, эш булмас микән дип, „Иванов“ приискасына китте әле...

— Юкка анда киткән, монда да эш булыр әле.

Ул сүзне артыкка сузмады: теге руска карап, минем эш эзләп килгән бер укучы икәнемне әйтеп тә бирде.

Картның бу сүзләреннән соң, теге рус миңа баштанаяк карап алды да:

— Элек эшләгәнең бармы?—дип, минем эшкә яраклы булып-булмавымны ачык белергә теләгән рәвештәге сөален бирде.

Мин үземнең элек төрле җирдә эшләүләремне, заводларда балчык ташу, кирпеч сугу кебек эшләрдә йөрүемне әйтеп беткәч, ул минем эшкә яраулы булуыма ышанган бер төс алды, ләкин үзе һаман ачык җавап бирми иде әле.

Каравылчы карт чыдый алмады:

— Ул күпне күргән егет, яшь булса да, рудникларда эшләгән ул, — дип, минем сүзләремне дөреслəп куйды.

— Шахтада эшләгәнең бармы?

— Анысы юк.

— Анда эшли алырсыңмы?

— Нинди эш?

— Казылган алтын комнарын шахта авызына ташу эше...

— Ник эшли алмаска? Эшлим.

Эш эзләү мәсьәләсе шуның белән чишелде. Ул миңа иртәгә иртә үк эшкә килергә кушты. Мин эшкә килергә вәгъдә биреп конторадан чыктым.

Шахта! Мин аның ни рәвешле икәнен күз алдыма китерә алмыйм. Кое кебек тирән бер җиргә төшеп китәсең, аны беләм. Аръягы караңгы...

Башкалар эшләгәнне мин ник эшләмәскә, дигән уйга килдем дә, казармага кайттым. Хәзер мин үземне эш кешесе, башка эшчеләр белән казармада торырга хаклы бер кеше итеп сизә идем.

Хәзер мин, үземнең эш табу шатлыгымны уртаклашыр өчен, иптәшемнең кайтуын көтә идем. Кич булды, кояш батар вакыт якынлашты. Эшчеләр эштән туктадылар, ләкин ул һаман кайтмады.

Мин, аның кайтуыннан өмет өзеп, ялгыз көн күрүем, бүген нәрсә белән тамак туйдыруым турында уйланырга керештем.

Минем ялгызлыктан эчемнең пошканын һәм кешеләр ашаган вакытта ашамый торуымнан капчыгымның буш икәнен эшчеләр дә сизделәр бугай, алар берәм-берәм минем хәлне сораша башладылар.

Мин аларга ашамлык нәрсәм юк икәнен әйтмәсәм дә, алар шуны сизенеп, мине чәй эчәргә кыстарга керештеләр.

Мин дә артык назланып тормый, алар янына утырып чәй эчтем дә, иртәгә эшкә барачагымны уйлап, нәкъ кичәге күренештәге казармада йокларга яттым.

Иртән иртә торылды. Мин конторага барганда, теге рус карт эшчеләр белән сөйләшеп тора иде. Ул мине шул эшчеләрнең берсенә тапшырды. Озак та тормый, без ул эшче белән шахтага киттек. Шахтага барып җиткәч, теге кеше миңа кыска саплы көрәк бирде һәм чыгырга уралган озын арканның башына беркетелгән зур бадиянга утыртып, чыгырны әйләндереп түбән төшерә башлады. Мин бадиянга утырып арканга тотынып, караңгы җир астына төшеп киттем...

Шахтага түбән төшкән саен караңгылык арта. Иөрәк курку катыш кызыксыну белән тибә, үзеңне кире чыга алмаслык тирән бер упкынга төшеп югала торган кебек сизәсең. Күзләр ихтыярсыз югары күтәрелеп

җирнең өстенә карыйлар. Кояшның җир өстенә сыймый торган мул һәм көчле яктылыгы монда бер генә тамчы нурын да турыдан-туры бирә алмый. Югарыдагы яктылык, кечкенә йолдыз кебек елмаеп, ялтырап кына күренә...

Бадиян, җиргә барып бәрелгәч, бер якка авышып китте, бездән элек төшеп, төрле якка таралган тар һәм тәбәнәк кенә штулбәләр[1] буйлап, үзләренең эшли торган урыннарына китәргә әзерләнеп, кечкенә лампаларын кабызган эшчеләр куркыныч бер кыяфәттә күренәләр. Җир асты дөньясын үзләренең көндез тора торган икенче казармалары кебек күреп, анда йөрергә, эшләргә өйрәнеп беткән эшчеләр, минем нишләргә белми куркуда торуымны сизеп:

— Ну, егет, монда төшүен төштең дә, ничек чыгарсың икән? — дип, миннән көләләр һәм шул сүзләренә өстәп:

— Караңгыда эшләсәң, якты дөньяның кадерен яхшырак беләсең аны! — диләр.

Алар бу сүзләрен уйнап әйтсәләр дә, аларның бу сүзләре чындыр, мин моннан тиз генә чыга алмамдыр төсле булып күренде.

Забойда эшләүчеләр, шахтаның төрле тармаклары буйлап, җир астының төрле караңгы почмакларына кереп югалдылар.

Мин аның казыган алтын балчыкларын ташыячак карт җайлап кына лампасын кабызды да:

— Чиләгеңне ал да, минем артымнан ияр, башыңны түбән бөгеп бар. Монда башыңа бәрүчеләр күп булыр, — дип, алга китте. Мин, аның кулына тоткан лампасының яктысына карап, артыннан иярдем.

Без шулай „Мең дә бер кичә“ хикәясендә тасвир ителгән „хәзинә“не һәм „серле йөзек“не эзләп, „тылсымлы мәгарә“гә кергән Мәгъриби кебек, караңгы һәм тар гына юл белән алга киттек.

Мин аның артыннан барам. Үзем: „Якты дөнья белән безнең араны нинди калын җир каплаган, безнең өстебездә авырлыгы акылга сыймаслык таш һәм туфрак катламнары тора. Әгәр дә өстебезгә ишелеп төшә калса!..“ дип куркам, һәм „хәзер җир өстендә, кояш

[1] Штулбә — штольня — кирәкле мәгъдәнне казып, алга барылган юл. *М. Гафури искәрмәсе.*

яктысында, чиксез киңлектә йөргән кешеләргә нинди күңелледер“, дип уйлыйм. Монда тын алырга һава җитмәгән кебек сизелә. Ике яклап тезелгән юан терәүләр кабыргадан килеп кысарлар төсле күренәләр.

Карт кичә казып туктаган урынына җитеп, кечкенә лампаны юан терәүгә каккан кадакка элеп куйды да, тирә-ягына каранып алды. Шул арада миңа да күзен төшереп, безнең эш урыны шушы инде дигән уйны аңлаткандай булды.

Мин һаман үземне, хәзер генә батарга торган кораб өстендә торган кебек сизәм. Алай-болай хәл булса, һичбер качар җир юклыгын, әгәр кергән юл ишелеп калса, мәңге шул урында торып калырга, тын бетеп үләргә туры килүен уйлап куркам, тәннәр чымырдап китә.

Картның йөзе һаман җир өстендәге кебек. Ул, өсләренә кояш нурлары явып торган чәчәкләр уртасындагы кеше кебек, ачык йөз белән балчык өстенә утырып, тәмәке ясап, кабызып җибәрде. Аннан соң җайлап кына бишмәт чабуларын кайтарып билбавына кыстырды, күн бияләйләрен киеп, кәйләсен кулына тотканнан соң, җиргә тезләнеп утырды да, миңа карап:

— Ну, ярый, энекәш, син ул балчыкларны шахта авызына ташый башла инде. Ике арада абайлап йөр. Өйрәнмәгән кеше башын-күзен бәрә торган. Бара-бара өйрәнерсең әле.

Ул шушы сүзләрне әйткәннән соң, тезләренә уңайсызлык китереп торган вак ташларны кулы белән ике якка сыпырып, тагы да иплəп тезләнде, кәйләсен уңайлап тотты да, җир яратылганнан бирле миллионнарча тонналар туфрак, балчык, ташлар астында кысылып тыныч яткан, вак ташлар белән бергә укмашып каткан балчыкларга чык-чык бәреп төшерә башлады. Кәйләнең ташларга бәрелүеннән чыккан тавышлар җир асты юллары белән китеп яңгырый башладылар. Аның эшкә чыныккан һәм сәләтле куллары бик җитез йөриләр. Вак таш катыш балчыкларны умырып-умырып төшерәләр иде.

Мин ул казыган балчыкларны кыска саплы көрәк белән чиләккә тутырып, кармана-кармана шахта авызына таба киттем. Шахта авызына якын куелган лампа белән карт янындагы лампа арасындагы 10—15 сажень чамасы юлны ул лампалардагы фонарь яктылыгы як-

тыртып бетә алмаганга күрә, бу ике араны бик абайлап кына барырга туры килде. Башны ия төшеп, бөкрәеп берничә пот чамасы балчыкны күтәреп йөрүе баштa бик авыр тоелды. Сакланып йөрүгә карамастан, штулбәнең өстенә тезелгән агачларга башның бәрелгәнен сизми дә калам. Ике араны берничә рәт әйләнгәнче, минем баш берничә җирдән күбеп чыкты.

Башта тыныч кына торган җир асты, эшчеләр эшләргә керешү белән, үзенең мәңгелек тынлыгын югалтты. Төрле якка таралган юлларның һәрберсеннән дөпдөп дигән тавышлар чыгып, челтәрләнеп беткән җир астында әйләнеп йөри башладылар. Әллә кайдагы караңгылык эчендә йөткергән, яисә кемнәрнеңдер сөйләшкән тавышлары җир астына җан кертте. Кайвакытта юан терәүләр нишләптер шытыр-шытыр итеп тавышланып куялар. Аларның тавышларын ишетү белән, йөрәк жу итеп китә. Шахтаның өсте убылып, мондагы эшчеләрне сытар кебек була.

Шахта авызының тирәсе төрле якка ташылган алтын песоклары белән каплана бара. Анда берничә кеше, бу песокларны зур бадияннарга тутырып, югары җибәреп торалар.

Шахта авызыннан югары карап, җир өстендәге яктылыкның кечкенә чаткыларын күрү күңелне рәхәтләндереп җибәрә. Бераз булса да тын да иркенәйгән, үлемнән аз гына булса да ераклашкан кебек булып китәсең.

Карт өйрәнгән. Ул, һичбер нәрсә уйламаган кебек, үзенең эшен дәвам иттерә. Кайвакытта хәле беткән кебек гыжлап, ютәлләп куя. Шундый вакытында, кәйләсен алдына куеп, тәмәкесен тартып ала да, әкренләп кенә тарта-тарта, минем эшләгәнемне карап тора. Ул нәрсә уйлый торгандыр, аны белмим, ә үзем ул картны кызганам. Аны җир астының бу авыр эшеннән коткарып аласы килә.

Байтак эшләгәннән соң, карт миңа карап:

— Син, туган, бераз эшлә дә хәл җыеп ал. Байның эшен ничаклы эшләп тә бетереп булмас. Бу җир асты күпме генә эшләсәң дә бетми ул, — дип, миңа утырырга кушты.

— Син казыган песокларны ташып бетерә барырга кирәк бит, — дим.

— Ничего, бетәр әле. Син бик уңган егет күренәсең, шулай кирәк ул. Мин үзем җебеп торган кешене

яратмыйм. Шунда да хәл жыя-жыя эшләгән яхшы. Әйдә, шунда утыр да ял ит.

Аның сүзен какмадым: хәл жыярга дип, аның каршысына утырдым.

— Син элек шахтада эшләмәгән булсаң, курка торгансыңдыр әле? Башлап эшләгәндә кыен була ул. Мин үзем дә башта бераз шүрли торган идем, — дип, карт сүз башлап җибәрде.

— Алай бик нык курыкмыйм. Шунда да җимерелеп китәр төсле күренә. Шулчаклы калын җирне бу терәүләр әле дә күтәреп торалар әле,— дидем.

— Терәүләр тотмый аны, җир үзен-үзе тота. Бу терәүләргә калса — пучтәк ул. Болар тик өстән балчыклар җимерелеп төшмәсен өчен генә куелып барылалар. Бу шахтада бармак шартлатып сикерә-сикерә эшләргә була. Казыла торгач, җир асты челтәрләнеп, казылмаган җирләр саклык өчен анда-монда юан багана төсле булып кына калалар әле. Менә шул чакта монда эшләү хәтәргә әйләнә. Ул вакытта бу терәүләр үзләре үк куркынычның якын икәнен алдан хәбәр биреп куялар. Мин инде шахталарда күп йөрдем. Карт аюлар да җир астында минем кебек озак йөрмәгәннәрдер. Бу шахтада үз өеңдә утырып эшләгән кебек эшләргә ярый.

Без аның белән якынлашып киттек. Ул тәмәкесен тартып бетерде дә, тагын үзенең эшенә тотынды. Мин хәзер җир астында йөрергә өйрәнә башладым. Картның теге сүзләреннән соң күңелләрдәге курку да бетә төште.

Песокларны чиләккә тутырганда да, шахта авызына алып барып бушаткан вакытта да, зур алтын кисәге табармын төсле, сарырак булып күренгән ташларны алып карыйм. Алар минем күзгә сары самородок төсле булып күренәләр. Ләкин аларның берсе дә самородок булмыйлар.

Картның шахтага төшеп эшли башлаган вакыттагы сүзсезлеге бетте. Ул хәзер, мин урап килгән саен дип әйтерлек, берәр сүз таба да мондагы эч пошыргыч тынлыкны югалтып куя.

Без тагын бераз эшләгәннән соң, штейгер[1] килеп эшнең барышын һәм казылып алынган җирләргә сугы-

---

[1] Штейгер — мәгъдән казу эшләрендәге технический якларны карап эшләтүче кеше. *М. Гафури искәрмәсе.*

лып килгән терәүләрнең куелышларын, казылган балчыкларның сыйфатларын күзеннән үткәрде. Тегеләйболай эшләнергә тиеш икәнен әйтеп, икенче юлларга кереп китте.

Карт аның артыннан карап калды да:

— Шул нәрсәләрне күрсәм, йөрәгем тибә. Мин алар белән бервакытта да тыныч кына сөйләшә алмыйм. Алар бервакытта да безнең положениегә кермиләр, әйтер идем инде—торып торсын!..

— Нигә соң алар алай булалар? — дим.

— Беләсең бит, байның ишек алдын саклаучы этләр байның үзенә караганда да усал булалар. Ул этләр бервакытта да өрми тора алмыйлар. Тик торсалар, аларның тамак төпләре кычытып тора, күрәсең.

Мин, аның бу сүзләренә карата бер сүз дә әйтми, аның ачулы йөзенә карадым.

Ул үзенең әйтәсе сүзләрен әйтеп бетермәгән рәвештә миңа карап:

— Аларның миңа күп этлекләре тиде. Мин аларның усаллыклары аркасында төрмәдә дә утырып чыктым.

Ул мине үзенең сүзенә ышандырыр өчен, минем сораганымны көтеп тә тормый, сөйләп алып китте.

— Шулай, Миас тирәсендәге приискаларда эшләп йөргәндә, бер штигер эшчеләргә килә дә бәйләнә, килә дә бәйләнә бит!.. Ничек әйтсәң дә, аның җаена төшеп булмый.

Шулай бервакыт тагын килеп бәйләнде. Минем (бармагы белән тамак астына чиертеп) бераз төшереп алган чагым иде. Бу нәрсәгә ачуым килде:

— Вон отсюда! — дим, — мы без вас та своя работа хорошо знаем, пожалуйста не лай! — дим.

Минем шул сүземнән соң ул миңа котырган эт кебек җикеренеп өскә ташланды. Шул чакта үземне үзем белештерми: чалт берне яңагына!..

Ул вакытта беләкләрнең таза чагы. Малай очып барып төште.

Урыныннан торып, тагын ябышырга теләгән иде, колак төбенә тагын берне тондырдым. Әпәт тәгәрәп китте. Иптәшләр килеп, аралап алмасалар, тагын да ныграк биреп, тешләрен суырмакчы идем.

Ул мине болай җиңә алмагач:

— Син эштән баш тартасың! Бу алтын государствога китә. Син патшага каршы киләсең! Мин синең башыңны

төрмәдә чертермен! — дип, миңа угроза ясарга керәште.

Кызган баш кызган:

— Теләсә кайда китсен, минем анда эшем юк. Патша миңа бер акча!— дигән сүзне ычкындырып ташладым. Ул, собака, минем шул сүземне эләктереп алды да:

— Ә, ә! Шулаймыни? Патша сиңа бер акча икән! Бу зимагорның нәрсә сөйләгәнен ишеттегезме? — дип, шунда ук гуаһландырып[1] та алды.

Мин әйтәм:

— Әйттем шул, кызгач нигә әйтмим! Юк җирдә патшаны китереп кыстырма,— дим.

— Ярый, күп сөйләнмә. Судка баргач җавап бирерсең,— ди.

— Ярый, бирермен,— дим. Әйткән сүземне кайтарып алмадым, эт янында баш иярга гарьләндем.

Ул шунда ук, приискадагы жандармны чакырып алып килде дә, минем өстән акт ясап, прошение бирде.

Иптәшләр мине яклап:

— Я, ташлагыз инде, син Шаһига үзең элек килеп бәйләндең бит,— дип карасалар да, булмады.

— Төрмә өйрәсен ашап, бераз дөнья күреп чыксын әле!— ди.

Мин дә сер бирмәдем:

— Күрсәм күрермен. Безгә Себер ни, Сембер ни,— дип, артыннан гайрәт күрсәтеп калдым.

Шул эш аркасында, алты ай баструкта ятып чыктым. Шуннан бирле штигер дигән нәрсә күземә күренү белән чәчләрем үрә тора... Ну, ярый, завтрак җитә торгандыр инде, тагын бераз эшләп алыйк.

Ул казый башлады, мин ташырга керештем.

Күп үтмәде, шахтаның өстеннән:

— Завтракка звонок! Иптәшләргә әйтегез! — дигән хәбәрне бирделәр.

Җир астындагы эшчеләр, бер-ике минут эчендә шахта авызына җыелып, чират белән югары чыгарыла башладылар.

Миңа да җир өстенә чыгарга чират килеп җитте. Икенче берәү белән мине салмак бадиян әкрен генә югары күтәреп алып менеп китте.

---

[1] Гуаһландырып — шаһит итеп.

Өскә чыгу белән, кояш нурлары безнең күзләрне чагылдырып җибәрде. Әкрен генә искән саба җиле безнең битләрне сөеп китте.

Шахтада эшләп, кояшка чыккан эшчеләр төркемен беренче рәт күргәндә, кояш төшми торган келәт астында саргылт, зәгыйфь һәм нечкә булып үскән үсемлекләр күз алдыма килде.

Бу эшчеләрнең яшьрәкләренең яки бу ел гына эшли башлаганнарының каннары суырылып өлгермәгәнгә күрә, үзләренең табигый төсләрен, битләрендәге кызыллыкларын сакласалар да, бернича ел шунда эшләгәннәренең каннары суырылып, келәт астында үскән зәгыйфь, саргылт үләннәр кебек булып калганнар, йөзләре саргайган, күзләре эчкә батып кергән, икенче төрле әйткәндә: җир астында күп эшләп таш казармаларда тора торган, аларның тән тамырларындагы кызыл каннары агулы сары суларга әйләнгәнгә күрә, яңа гына озак авырудан терелеп чыккан кешеләр кебек, саргылт булып күренәләр иде...

Алар авыр шартлар эчендә байларга эшләп йөри торгач, үзләренең ярты сәламәтлекләрен югалткан булсалар да, кешелекләрен югалтмау ягына караганда бик күп кешеләрдән алда торалар иде.

Иртәнчәк, мин шахтага төшкән чакта, минем куркуымны сизеп, миннән уйнап көлгәннәре мине күргәч:

— Әле син кире чыга алдыңмыни? — диләр. Кайберләре:

— Ну, анда эшләр ничек булды? — дип сорыйлар.

Минем өчен үзем белән бергә эшләгән карт җавап биреп:

— Егет малатчина күренә. Кемгә дә иптәш булырга ярарлык, аны өйрәтеп торасы да юк! — диде.

— Шулай кирәк! Ато укыган кешеләрнең күбесе камыр кебек йомшак булалар...

— Бу алай түгел, тимер кебек. Ул бәләкәй чагыннан ук эшкә күнегеп үскән. Мин аны сораштым...

— Ярый, Сибгать агай, яшь кешене эшкә өйрәт...

— Аны өйрәтәсе дә юк инде.

Мин аларның үзем турындагы сүзләреннән үзем көләм, үзем аларны һаман үземә якын иптәшләр кебек күрә барам. Аларның керсез сүзләре күңелгә ягымлы тоела.

Болар яхшы, болар белән эшләү күңелле булыр, ләкин менә хәзер ашарга юклык эчне тырный. Казар-

мага кайтып, аларның ашаганнарын карап торганчы, завтрак вакытын шунда йөреп үткәрмәкче булып киләм.

Сибгать агай (минем белән эшләгән карт) минем хәлне аңлаган кебек:

— Соң син кем белән ашап-эчәсең? Чәйнек-мазарың бармы? — дип сорап та алды.

— Хәзергә мин ялгыз гына. Чәйнек-фәлән дә алганым юк әле.

— Әйдә алай булса безгә. Нәрсәгә алай адашкан каз бәбкәсе кебек ялгыз йөрергә!.. Безнең монда алай йөрү килешми.

Мин аңа күмәч-мазар алырлык акчам юклыгын әйтәсем килмәде. Шуның өчен:

— Әле минем күмәчем дә юк. Лавкага барып киләсем бар,— дидем.

— Анда барып йөрмә инде, бездә бар бит, әйдә безгә барабыз, ату соңга калырсың.

Мин күп назланып тормадым:

— Ярар алай булса, соңыннан исәпләшербез...

— Анысын сөйләмә син, әйдә безгә!

Мин тоттым да Сибгать бабай белән туп-туры семьялылар казармасына киттем. Ул үзенең карчыгы белән Хәдичәләр тора торган казарманың икенче башында тора икән.

Без казармага житкәндә, Хәдичә үзенең иптәш кызы белән казарма алдында көлешә-көлешә юына, аның бите яңа гына күпертелеп сөртелгән ап-ак сабын күбекләре белән капланып, тик ике күзе генә күренә иде.

Ул, Сибгать агай белән мине күргәч, көлүеннән туктала төшеп, йөзен икенче якка әйләндерде һәм битендәге ап-ак сабын күбекләрен тиз-тиз генә юып төшергәннән соң, тагын бер мәртәбә әйләнеп карады. Бу вакытта аның йөзендә шатлыклы елмаю балкып тора иде.

Мин аның безне күрүгә капыл гына хәрәкәтен үзгәртеп, шатлыклы елмаюының мәгънәсенә төшенмәдем. Тик өченче көн кич, аларның үзләрендә чәй эчеп чыкканнан соң, иптәшем Зиннәтнең:

— Матур бит, әй!— дигән сүзе исемә төште дә:

— Чынлап та, матур шул! — дип уйладым һәм аңа таба тагын бер мәртәбә әйләнеп карыйсым килсә дә, карарга уңайсызланып, Сибгать агай артыннан казар-

мага кереп киттем. Аның иптәше белән сөйләшкән ягымлы тавышы ишетелеп калды...

Сибгать карт мине туп-туры үзләренең тора торган почмакларына алып барды һәм миңа үзенең бер кунагы кебегрәк карап:

— Әйдә, рәхим ит әле. Менә хәзер чәй эчәрбез. (Карчыгына карап.) Карчык, мин бүген үземнең янымда эшли башлаган иптәшемне дә алып килдем әле. Ул ялгыз гына икән, аңа күңелсез булмасын дидем.

Әби минем белән исәнләште дә:

— Бик әйбәт! Без икәү генә бит, өчәүләп чәй эчү күңелле булыр,— дип ачык йөз белән каршылады.

Без бит-кулны юып алганчы, ашъяулыкны зурайтыңкырап җәйде. Ике пар чынаяк янына өченчесен куйды. Таш тәлинкәдә торган күмәчләрнең телемнәрен арттырды, яңа гына пешереп, суынмасын өчен таш табакка салып өстен ябып мичкә куйган бәрәңгесен китереп куйды да шунда ук чәй ясап җибәрде.

Сибгать бабай белән без икәү, аның ашарга өндәвен көтеп тә тормый, ашарга керештек.

Ашыгыч кына эчкән чәй арасында алар үзләренең гаилә тормышын сөйләп алдылар.

Аларның сөйләүләренә караганда, аларның үз гомерләрендә җиде балалары булып, аларның бишәвесе төрле җирдә төрле авырулар белән чирләп үлгәннәр икән. Җиде баланың икәвесе исән булып, Зәйнәп исемле кызларын үткән ел гына кияүгә биргәннәр, ул кияве белән икенче бер прискада тора икән. Сәфәргали исемле уллары өченче ел солдатка алынып, ул хәзерге көндә моннан „35 мең чакрым" җирдә, Кара диңгез дигән диңгезнең буенда, бер дә мондагы кешеләргә охшамаган кешеләр арасында „Патум" (Батум) исемле шәһәрдә патша хезмәтенә грифтар булып тора икән. Аның хезмәте андагы зур начальникларга охшаган. Шуның өчен аны фельдфебель чинына мендергәннәр. Язу-сызу белмәгән көенә, Сәфәргалиләренең шул дәрәҗәгә менүенә карт та, карчык та бик шатланалар. Киләчәк көндә тәүфыйклы, бәхетле булуын телиләр.

Мин, бер яктан, аларның сүзләрен тыңлыйм, кайчакта үзләренә сөаль биреп куям, икенче яктан, казармадагы ыгы-зыгы килгән тормыштан күзләремне ала алмыйм.

Казарма гөж килә, 20—25 урында түгәрәкләнеп ашарга утырган кешеләрнең авызлары ашыгыч кыймылдыйлар. Шул түгәрәкләр арасында байтак кына авырып ятучылар, кәефсезләнеп елап утыручы балалар да күренә. Аны-моны карап, уйлап тормый ычкындырылган төрле сүзләр дә еш-еш ишетелеп кала.

Казарманың теге башында йөргән Хәдичә дә берике рәт күренеп калды. Ул һаман да күңелле, шат күренә. Бу тормыш эчендә шундый Хәдичәләрнең булулары яшьлек вакытының яшел бер яфрагы кебек булып сизелә иде...

Чәй эчелеп беткәнче, минем хакта да сүз булды. Сибгать бабайның кузгатып җибәрүе буенча, әби үзе теләп үзләрендә ашап-эчеп йөрүне мәслихәт күрде. Аларның киңәшләре буенча, мин болар белән ашапэчеп, тик кунарга гына „буйдаклар“ казармасына барачак идем.

Юеш һавалы казармада торып күгәреп беткән будильник сәгатькә караганнан соң, Сибгать бабай эшкә барырга вакыт җиткәнен аңлаткан рәвештә:

— Сөйләшеп чәй эчә торгач, заманның үткәнен белми дә калабыз,— дип урыннан тора башлады. Башка эшчеләр дә, минут эчендә урыннарыннан торып, ашыгыч рәвештә үзләренең эш урынннарына китә башладылар.

Без ишектән чыкканда, Сәлим бабай безгә очрап, дөнья күргән олы кешеләрчә исәнләшеп, минем Сибгать карт белән бер җирдә эшләвемне белде һәм аңа карап:

— Бик яхшы булган! Синең кебек дөнья күргән кеше белән бергә эшләү яшь кеше өчен яхшы булыр,— дип, үз эшенә китте. Хәдичә дә үзенең иптәшләре белән безнең арттанрак чыгып, алтын юа торган бурага таба юнәлде.

Шахтага барганда, Сибгать карт тагын да шушы приискалар һәм үзенең кайларга йөргәнен сөйләп барганга күрә, без шахтага барып җиткәнебезне сизми дә калдык.

Бу юлы миңа шахтага төшү иртәнчәк төшкәндәге кебек кыен да, күңелсез дә, куркыныч та булмады. Хәзер мондагы эшчеләр дә миннән көлмиләр, алар миңа күптәнге иптәшләр кебек күренәләр иде. Без шахтага төшкәндә, кояш безнең артыбыздан көлеп карап калды.

Бүген якшәмбе — эшчеләрнең ял итү көннәре. Казармаларда бүген икенче төрлерәк тормыш.

Буйдаклар казармасы бүген соңгарак калып уянды. Мондагы эшчеләр, үзләренең кечкенә иске сандыкларын ачып, ял көннәрендә генә кия торган чиккән якалы күлмәкләрен һәм кыска җиңле камзулларын, тужуркаларын алып, „бәйрәмчә“ киенергә хәзерләнәләр.

Кайберәүләре, тәрәзә аркылы төшкән кояш яктысына каршы утырып, сакал, мыекларын төзәтәләр. Анда берсе кызыл саплы пәке белән икенче бер иптәшенең чәчен кыра. Атна буена чәч арасына утырган ком-тузаннар аның пәкесенең йөзен шунда ук кайтаралар, күрәсең. Ул чәч алучы минут саен кулындагы пәкесен кайчакта иптәшенең каешланган аркасына, кайвакытта үзенең чалбарына янып азаплана. Теге озын чәчле таза егет, һәммә кешеләрдән элек торып, үзен рәтләп өлгергән. Ул инде үзенең бер иптәше белән чәй эчәргә дә керешкән. Атна буенча арыган гәүдәләрне ял иттерү шатлыгыннанмы, булмаса, икенче „бәхет“ көткәнгәме — болар бүген шат һәм сүзчән күренәләр. Тик теге таза егетнең авыру иптәше генә әле булса үзенең авыруыннан айный алмаган. Ул мондагы хәрәкәтләрдән, ял итәргә хәзерләнү шатлыкларыннан хәбәрсез рәвештә, каты сәке өстендә бөкрәйгән көе тик ята. Ул әллә йоклый, әллә инде авыруының катылыгыннан шулай бернәрсә дә сизмәслек бер хәлгә килгән — анысы билгесез.

Семьялылар казармасындагы җанлылык бүген бөтенләй башкача. Аның ишегеннән керү белән, авыр май исләре бәреләэ, нәрсәнедер ашыгып көткән вакытта гына була торган ашыгыч бертөрле буталчык күзгә ташлана.

Анда хатын-кызлар зык кубалар. Казарманың мичләре алдында хатын-кызлар чират торып кабартма, коймак кебек нәрсәләр пешерәләр, бәрәңге кыздыралар. Дистәләгән эреле-ваклы самоварлар, төрле тавышлар чыгарып, үзләренең чәй урыннарына утыртылуларын көтәләр.

Минем әби һәммәсеннән иртә өлгергән. Сибгать бабай белән мин ашъяулык янына килеп утыру белән,

ул гөжләп кайнаган самоварын китереп утыртты. Аның артыннан ук зур гына таба белән коймак китереп куйды. Шунда ук үзенең карт сандыгын ачып, крендель, йөзем җимеше, шикәр кебек нәрсәләр алып ашъяулык янына китереп тезде дә чәй ясап җибәрде һәм ачык йөз белән:

— Ягез, коймагы суынып бетмәс борын ашагыз, көтә-көтә ачыгып беткәнсездер, бүген утын чи булып, мичне яндыра алмый аптырап беттем, — дип сүз башлап җибәрде.

Сибгать бабай салмак кына рәвештә:

— Эшкә барасы булмагач, ашыгып нәрсә бар. Кояш чыккан чакта тышка чыгып, көннең матурлыгына сокланып, бераз йөреп, тагын кереп яткан идем. Бик тәмле йокыга киткәнмен. Төшемдә забой казыганда бик зур — менә шушы баш бармак чаклы булыр — самородок таптым. Инде алып чыгыйм дигәндә генә, менә күршенең баласы елаган тавышка уянып киттем, — дигән сүзләр белән чәй мәҗлесен ачып җибәрде.

— Син шул самородкыны төштә генә табасың, — ди әби.

— Ярый инде, нишлисең?..

Казарманың һәрбер урынында чәй эчүләр башланды. Менә Сибгать бабайларга янәшә генә, яшь кенә хатынлы һәм кечкенә балалы берәү кәефләнеп чәй эчә.

Ул чәй арасында үзенең артына куйган шешәсеннән аз-аз салып төшереп ала, үзе хәзер үк яхшы ук кызган. Әби эшчеләрнең эчүләреннән зарланып китте.

Бабай аның сүзенә артык кушылмады:

— Яшьрәк чакта була инде ул. Көн буе җир астында эшләгәч, ял көнендә сөякләрне йомшартырга кирәк бит. Ләкин күбрәк төшереп, эшне бозып куялар. Эчкәндә дә, акылны эчәргә ярамый. Минем үземдә дә яшь чакта андый эшләр була торган иде. Ләкин һичбер вакыт акылны эчмәдем, — дип, ике яклырак сүз сөйләп куйды.

— Араларында шул нәрсәне авызларына якын да китермәгәннәре бар. Алар лутчы торалар, — ди әби.

— Шулай инде. Бездә наданлык та зур. Әлепне таяк дип белмибез... Ичмаса, менә бу балаларны укытырга мәктәп тә юк бит!

Чәй эчү яхшы ук озакка сузылды. Сүздән сүз чыгып, казарма, эшчеләр тормышыннан күп сүзләр сөй-

ләнде. Тамакларын туйдырып алган кешеләр, казармадан чыгып, кояшка каршы утырып, әңгәмәгә керештеләр. Теге, Сибгать бабайларның күршесе, иртә үк „төшереп“ алган кеше, нәрсәдер сөйләп, башкаларны көлдерә.

Кызлар аерым бер төркем булып күзгә бәреләләр. Алар нәрсә сөйләп кызыклана торганнардыр — белеп булмый.

Мин кайтып кергәндә, „буйдаклар казармасы“ бөтенләй икенче төс алган.

Бер почмакта җиде-сигез кеше урталарына бөтен чирекне утыртып чәкәштерергә керешкәннәр. Урта бер җирдә тагын шундый ук әкәмәт корып утыралар. Озын чәчле бер егет, үзен-үзе бик нык тотып, гармонь уйный. Мәҗлес казарманың эчендә генә сыеп тора алмады, казарманың тышына да чыкты. Семьялылар казармасыннан да берничә кеше килеп кушылдылар. Алар килгәч, казарманың эченнән:

— Карлыгачкай кара, муены ала,
Канат очкаеннан кан тама;
Аталардан калган, ай, яшь бала
Күкрәк көче белән мал таба...

дип җырлаган тавыш боларның күңелләрен тагын кытыклап җибәрде.

— Әйттер шуны, әйдә!

Озак та үтмәде, гармонь да тышка чыгарылды. Гармоньның сикереп-сикереп уйналган тавышына шул ук көйгә җырланган җыр тавышы кушылды. Җыр һәм аңа кушылган гармонь тавышына семьялылар казармасындагы хатын-кызларның да колаклары торды.

Җыр һәм гармонь тирәсендә бик аз вакыт эчендә бик күп кешеләр җыелып өлгерделәр. Кемдер берәү:

— Әйдә, бию көен әйттер әле! — дип әйтү белән, тагын гармоньчы бармаклары белән бию көен басарга кереште. Бию көе уйнала башлау белән, кызыл күлмәгенең якасын ычкындырган, үзе кызмача булып алган бер егет уртага төшеп, башын бер алгарак чайкап, кемнедер кочакларга теләгән кебек, ике кулын җәеп, гәүдәсен әрле-бирле сыгылдырып, аякларын җиргә ныклап тибеп, түгәрәкне әйләнеп йөри башлады.

Егетнең дәрт белән биюе карап торучыларның да күңелләрен күтәреп җибәрде. Дистәләгән күзләр биюче егетнең җитез йөргән аякларына текәлделәр.

Хатын-кызлар уен түгәрәгенә тагын да якынлаштылар. Аларга бер яктан урын бирелде. Биюче егет тагын да дәртләнә төште. Ул, кесәсендәге кулъяулыгын алып, битен сөртеп алды.

Икенче бер егет, аңа каршы төшеп, үзенең биюгә осталыгын күрсәтергә кереште. Бу соңгысы, биюеннән туктамаганы хәлдә, җиргә утырырга теләгән кебек чүгәләде дә, аякларын алга чыгарып, ике кулын тезләре астыннан алмаш-тилмәш үткәреп, учларын чәпелдәтә башлады, төрле күренешләр ясап, караучыларны көлдерде. Карап торучылар:

— Я инде, арыгансыздыр, бераз хәл җыегыз,— дип әйткәнгә кадәр егетләр биюләреннән туктамадылар.

Алар биюләреннән тукталуга, шунда карап торучылардан берәү, хатын-кызлар төркеме ягына карап:

— Я, сез нигә карап кына торасыз? Аякларыгыз сызламасын,— дигән сүзне ташлады.

Йөрәкләре тибеп торган хатын-кызлар, бер-берсен төрткәләп, биергә кысташа башладылар:

— Әйдә, Хәсби апа, булмаса, һөнәреңне күрсәтеп ал әле,— дигән сүздән соң, без беренче көнне семьялылар казармасына кергәндә, җырлый-җырлый сандыгын актарып утырган хатын уртага чыкты. Ул башта кыяр-кыймас бер кыяфәт күрсәтеп, яулыгының бер як чите белән битенең бер ягын каплап кына бии башласа да, бара торгач ачылып китте. Ул үзенең аякларын яңа чыккан яшел үләннәрне измәскә тиешле кебек йомшак һәм вак кына баса, гәүдәсен дә дулкынсыз суда йөзгән аккош кебек тигез генә йөртә иде.

Уен барган саен кызды.

Казармада мәҗлес корып утыручылар да берәмберәм якты кояш астына чыга башладылар.

Уен-көлке шулай кызып барганда, алпан-тилпән килгән берәү, караучыларның теләкләренә каршы, биергә теләп, уртага төште. Ләкин аның пима кигән аяклары үзе теләгәнчә йөри алмадылар. Ул гәүдәсен тота алмый бер якка авышып китте.

— Әй, синең шөребең бушаган, юкка мәшәкатьләнмә!— дигән сүзгә аның намусы килде бугай, ул тагын биергә тырышып карады, тагын булдыра алмый, бер якка ауды.

Караучылар арасыннан:

— Лутчы син мишайт итмә! — дигән сүзгә аның ачуы кабарды:

— Мин ни барыгыздан да шәп! — дип җилкенеп куллары белән нәрсәдер эзләнергә кереште.

Аның иптәшләреннән берсе янына килеп:

— Әйдә, болай ярамый, казармага кер,— дип кулыннан тоткан иде, ул икенче кулы белән теге кешенең башына кундырды. Аны тотучы кеше ачуланып:

— Синең башың кычыта икән әле,— дип, уңга-сулга бирергә керешге.

Бу ямьсез күренешкә һәркемнең кәефе китте:

— Ул һәрвакыт шулай скандал чыгара! — дип, төрле яктан ачулы тавышлар чыгардылар.

Хатын-кызлар, бу эштән сискәнеп, бер якка тайчандылар һәм берәм-берәм үзләренең казармалары ягына тайдылар.

Ул арада теге биюче егетләрнең берсе, исерек биюченең җилкәсенә берне төшерде дә, кулларыннан шакарып тотып:

— Житәрме, әллә тагын кирәкме? — дип, үзенә карады. Исерек биюче капыл гына йомшады:

— Кара әле, мине җибәр әле, мин тик болай гына...

— Шулай булгач, тукта дигәндә — тукта!.. Исерүең җиткән икән, кер дә ят. Нәрсәгә монда хатын-кызлар арасында теләсә нәрсә кыланып йөрисең?!

— Бетте, мин болай гына...

— Бетсен шул!..

Шуннан соң исерекне, ике яктан култыклап, казармага алып киттеләр.

Бу скандалдан соң уен-көлкенең кызыгы югалды, караучылар таралдылар.

Көндезге аш вакытында Сибгать бабай да, әби дә мондагы тормыштан һәм ял итү көннәрендә һәрвакыт шушындый тәртипсезлекләр булып торуыннан зарланып алдылар.

— Ни эшлисең соң инде? Аларның башка нәрсә кызыклары бар? — диде Сибгать карт.

— Эчеп, сугышып йөрүдән нинди кызык булсын? — ди әби.

— Алар башта күңел ачар өчен генә эчәбез дип эчәләр. Бара торгач, шундый күңелсезлекләр булып китә. Һәркемгә бертөрле күңел ачу кирәк бит.

— Ярый ла ул авыл яисә шәһәр җирләрендә кызык

ачу урыннары бар. Безнең монда бит аларның берсе дә юк,— дип, бер яктан, теге эчүчеләрне артык гаепләмәскә тели, икенче яктан, аларга бер яңа нәрсә, яңа тормыш бирергә теләгән кебек була иде.

Яңа гына булып үткән ямьсез тормыш тиз онытылды. Семьялылар казармасында яңадан үзенә күрә бертөрле ыгы-зыгы килү, төшкә хәзерләнгән, төрле урыннарда пешерелгән бер үк төсле ашларны ашау башланды. Бәләкәй балаларның үзара кычкырышуларын, аналарының үзләренең кечкенә балаларын юату тавышларын исәпкә алмаганда, мондагы тормыш тәртипле юлга төшкән кебек булды.

Эш шулай барганда, буйдаклар казармасыннан берәү килеп, теге авыру егетнең үлүен хәбәр бирде һәм Сибгать бабай белән Сәлим бабайның шунда баруларын үтенде.

Бу үлем хәбәре бөтен казарма эченә бертөрле күңелсезлек ташлады. Бөтен эшче гаиләләре, йөзләрен үзгәртеп, алларындагы ризыкларын ашауларын оныттылар.

Бик күп авызлардан:

— Яңа гына типсә тимер өзәрлек егет әрәм булды...

— Дөньяның әчесен-төчесен күп татыган, уңган егет иде...

— Күптән түгел Гәрәйне туфрак басып үтергән иде, инде монысы эшләгән жиреннән авырып кайтып үлде...

— Безнең монда шул бик күп кешеләр вакытсыз әрәм булалар.

— Дару-дәрмән итәргә рәт юк...— кебек сүзләр дә чыкты.

Болар, вакытсыз үлемнәрне кемнәндер күргән төсле булсалар да, ул кемдер — атап әйтмиләр, бары тик мондый вакыйгаларны үзләренең „тәкъдирләреннән“, я булмаса „бәхетсезлекләреннән“ күргән кебек булалар иде.

Сибгать бабай башын түбән иеп бераз уйланып торганнан соң:

— Барысы да шул үзебездән. Әнә үткән ел бер егет килеп, безгә эшнең нәрсәдә икәнен, эшчеләрне начальстволар белән байлар берләшеп изүен, безнең дә аларга каршы торырга кирәк икәнебезне астыртын рәвештә бик әйбәтләп төшендерә башлаган иде дә бит, аны бик озак тотмадылар. Халыкны начальствога

каршы баш күтәрүгә өндәп йөри торган бер кеше икән диделәр дә, алып киттеләр... Иллә, үзе зәһәр, үткер егет иде!.. Үзен арестовать иткәндә, йөзен дә чытмый аларга каршы сөйләште:

— Сез, ди, байларның ялчылары! ди. Сез сатлык җаннар, эшчеләрнең каннарын эчәсез, палачлар!.. ди. Тагын әллә нәрсәләр әйтеп бетерде. Аны күп сөйләндерми алып киттеләр. Киткән чагында безгә карап:

— Без сезне онытмабыз. Сез дә үзегезнең кемнәр икәнегезне исегездән чыгармагыз. Безнең көч күп!..— дип әйтеп китте. Без ни эшләргә дә белми алай-болай иттек тә, тордык та калдык. Шунда без бергәләшеп ул егетне алар кулына бирмәскә кирәк икән дә бит!..

Бу вакытта Сибгать бабайның йөзендә нindидер бер кирәкле эшнең булмый калуына үкенү билгесе күренә иде.

Әби аның сүзен тыңлап беткәч:

— Син үзең дә бик күп сөйләнәсең. Я үзеңне дә алай-болай итеп куярлар! — дип, тирә-ягына каранып алды.

Сибгать бер дә исе китми генә:

— Дөресе шулай булгач, нишлисең? Эшчеләрнең берсе кичә, берсе бүген үлә дә тора. Аның причинасын тикшерү юк! — диде дә, урыннан торып, казарманың теге башына барды, анда Сәлим карт белән очрашып сөйләшкәннән соң, казармадан чыгып киттеләр.

Мин дә, үзебезнең казармага кайтырга дип, иркен һавага чыктым.

Бу вакытта Хәдичә ишектән ерак түгел бер скамья өстендә, үзенең бер иптәш кызы белән, искереп беткән нindидер бер китап карап утыра иде. Ул мине күргәч, кулындагы китабын тиз генә ябып куйды да, нәрсәдер әйтергә теләгән кебек, миңа таба карады. Минем дә аңа нindидер әйтергә тиешле сүзләрем бар кеше кебек уңайсызланып калдым. Әллә нигә мин аңа нинди булса да берәр нәрсә турында сүз әйтсәң ярамас, яраса да килешмәс төсле була иде. Шулай да мин аларга карап:

— Исәнмесез әле, нигә монда утырасыз? — дигән сүзләрне әйттем һәм „нигә монда утырасыз" дигән сүземне ни өчен әйткәнемне үзем дә сизми калдым.

—Исән әле... Тик шулай гына утырабыз.— Бу җавапны Хәдичә бирде.

Безнең сүз бетте дә куйды. Инде моннан китәргә кирәк, ә үземнең болар яныннан бер дә китәсем килми. Әле дә бәхеткә каршы:

— Нинди китап укып утырасыз?—дигән сүз искә төште.

— Бу... болай гына, китап...

— Кайда, күрсәтегез әле, нинди китап икән?..

— Юк, аны сиңа күрсәтергә ярамый. Син көләрсең... Мин сүзнең болай озынга китүенә шатландым һәм:

— Күрсәт әле, көлмәм. Китаптан көләләрмени?

Шушы сүздән соң ул, кулындагы китабын төрле төстәге дөбетләр (гарс) белән чәчкә рәвешендә бизәкләр төшереп чиккән ап-ак алъяпкыч астына яшерә төшеп:

— Юк, бу китапны сиңа күрсәтергә ярамый,— дигән сүзләрне кабатлады.

— Нигә ярамасын икән?—дидем.

Хәдичәнең иптәш кызы чыдамады, ул Хәдичәгә карап:

— Күрсәт тә куй. Кешегә күрсәтергә ярамаса, ташка басып чыгармаслар иде бит,—дип, китапны миңа күрсәтү ягында икәнен белдерде.

— Шулай шул. Әллә нинди яшерен нәрсә түгелдер әле,—дидем.

— Мә, алай булса... только шунда гына кара да кире бир!—дип, китапны минем кулга бирде.

Китапны кулыма алу белән, аның яшьләр арасында, борынгы вакытта кулдан кулга йөртелгән „Таһир-Зөһрә“ икәнен белдем. Мин аны кулга алу белән, алар икәвесе дә, „бу нәрсә әйтер икән“ дигән кебек, миңа карадылар.

— „Таһир-Зөһрә“ икән!.. Бу китапны кайда булса да укыйлар бит. Мин үзем дә берничә рәт укыганым бар,—дидем.

Хәдичәнең иптәше капыл гына:

— Без аның белән укыйбыз. Алар бик җәл. Шулар чынлап та шулай булдылар микән?—диде дә, бер Хәдичәгә, бер миңа карап алды.

Хәдичә миңа җавап биреп торырга урын калдырмый:

— Булмаган эшләрне китапка язмаслар инде,— дигән сүзне чын күңеленнән әйтеп өлгерде.

Күрәсең, ул шундый китапларда язылган нәрсәләрнең вакыйгада булуына һичбер шиксез ышана икән...

Аның шул сүзеннән соң иптәше:

— Зөһрә мескеннең әтисе бигрәк тә каты бәгырьле булган икән! — дигән сүзне өстәде.

Безнең сүзләр шунда җиткәндә, Хәдичәнең әнисе ишектән чыкты.

Без аны күрү белән, өчәвебез дә бик зур килешсезлек эшләгән кешеләр кебек, ни эшләргә белми аптыраштта калдык. Ул безгә таба аз гына карап торды да:

— Хәдичә, кил әле монда! — дип, Хәдичәне казармага чакырды.

Кызыклы күрешүнең иң матур җирендә шулай күңелсез рәвештә киселүе кызларга нинди тәэсир биргәндер, ә минем үземә бик күңелсез тәэсир калдырды.

Мин китапны Хәдичәнең кулына бирдем дә үзебезнең казармага киттем. Ә алар, үзләренең нindидер бер яшерен серләре ачылган кешеләр рәвешендә, казармаларына кереп киттеләр.

Мин үзебезнең казармага кергәндә, безнең казарма эчен тирән бер тынлык баскан кебек иде. Әле күптән түгел генә зык кубып йөргән эшчеләр, айныган кебек, хәтта үзләренең бүген эчүләреннән үкенгән кебек күренәләр иде.

Шушы тормыш, шушы моңсу казарма эчендә яңа гына үлгән эшченең сузылып яткан гәүдәсе минем күңелгә дә бик авыр тәэсир бирде. Ул үзе үлгән булса да, аның шул газап чигеп үлгән гәүдәсе, аның үткән тарихын, төрле прискаларның шахталарында эшләп йөрүләрен, ниһаять, шушы „шагыйрьнең алтын прискасы“на килеп эшләгәндә авыру эләктереп, шушы ямьсез казармада, докторга-нигә күренә алмый, каты сәке өстендә авырып ятып, җан бирүен сөйләп торган кебек була иде.

Мин аның янына барып, бераз карап тордым да, бу казармадан чыгып китәргә ярамаган төсле бер хәлгә килеп, шуннан ерак түгел бер урынга утырдым. Шул вакытта, ул үлгән егетнең туган илендә карт әнисе, аннан соң аның кайтуын көткән ятим сеңелесе бардыр... алар аның исәнлек хәбәрен көтә торганнардыр кебек булып күз алдыма килде.

Теге озын чәчле егет үзенең күп җирләрдә бергә йөргән, бергә эшләгән иптәшенең үлүенә чыннан кайгыра һәм аның хакында бик күп нәрсәләр сөйләп, аны

мактый, ниһаять, прииска хуҗаларын һәм шушы тормышны сүгеп, аларга каршы булган ачуына чыдый алмый, көчле йодрыгын төйнәп:

— Вот без кемнәр өчен эт көнен күрәбез!— дип, тирә-ягына каранып куя иде.

Ял итү көненең матур кояшы көлеп чыккан булса да, ул моңсуланып батты. Ул әллә кемнәргәдер көлеп карап баткан кебек булгандыр... Ләкин безгә моңсу күренде.

Бүген безнең казармада төн буе ут сүнмәде. Аның саран яктысы төн буенча үлгән эшченең гәүдәсен һәм аны каравыллап утырган картларның җыерчыклы битләрен яктыртып торды.

IV

Прискада эшләр барган саен кайный. Әллә кайдагы заводлардан эшләнеп килгән очлы кәйләләр җир астын ашап алга баралар. Миллиард еллар буенча тыныч яткан ташлар, балчыклар өскә чыгарылып юылалар да, алтыннары алынып, кайдадыр җибәрелә баралар. Кәйләләрнең очлары ашалып тупасланалар да контора аша яңадан тимерлеккә җибәреләләр. Эшчеләр, ташларны ватып, тимерләрне ашалдырып, үзләренең эшләрен дәвам иттерәләр. Аларның каннары әкренләп кибә, итләре күзгә күренми ашала, сөякләре сызлый...

Аларның берәрсе авыр эшкә яраксызланса, ул эшче, алтыннары юылып алынган песок кебек, читкә ташлана. Аларның кайберәүләре өсләренә җимерелеп төшкән балчыклар астында калып үләләр...

Шулай авырып, эштән чыгып читкә ташланган яки җир астында калып үлгән эшчеләр урынына, эш эзләп яңа кешеләр, яңа көчләр килеп, аларның эшләрен шул ук урыннан башлап алып китәләр. Әллә ничә урында, әллә ничә шахтада эшләр туктаусыз бара. Җир астында тыныч яткан алтын песогы катлавы актарылып өскә чыгарыла.

Эшчеләр, тукран кебек, очлы кәйләләре белән чукый-чукый, без эшли торган шахтаны да бер-ике ай эчендә кола яланга әйләндерделәр. Хәзер өстендәге җир җимерелеп төшүдән саклык өчен тик анда-монда гына зур мичләр юанлыгында казылмаган җирләр белән чиксез күп терәүләр тезелешеп калдылар. Эш бу хәлгә

килгәч, шахтада эшләү яхшы ук куркынычка әйләнеп, һәрвакыт аның җимерелү ихтималы турында сөйләнә башланды.

Әллә ничә еллар шахтада эшләп, җир асты кешесенә әйләнеп беткән Сибгать бабай да хәзер бу шахтада эшләүнең куркынычка әйләнүен еш-еш кына телгә алып:

— Бу шахтаның гомере күпкә бармас, озакламый басылып төшәр. Тик менә эш барган вакытта гына андый-мондый булып куймасын иде. Бервакыт шулай... приискасында эшләгәндә, шахта җимерелеп, әллә ничаклы кеше һәлак булды. Белеп булмый тагы, кайбер җир тиз генә убылучан булмый. Ташланган шахталар да байтак вакытлар җимерелми торалар. Шулай да хәзер сак булган яхшы. Шахталар бервакытта да үзләренең җимерелүләрен алдан әйтеп тормыйлар,— дигән сүзләрне ычкындырырга кереште...

Башка эшчеләр дә үз араларында һәм штейгерга шахтага төшкән вакытларда, хәзер бу шахталарда эшләүнең куркынычлыгын, тиздән җимерелеп төшү ихтималы барлыгын сөйли башладылар.

Ләкин штейгер забойщикларның бу сүзләренә каршы:

— Нигә җимерелсен, ди, әле ул. Бу җирнең почвасын, катламнарын без сездән яхшы беләбез. Монда комсу җир түгел, сез юкка куркасыз, куркаклар! — дип, көлеп кенә җавап бирә иде.

— Ә соң җимерелсә ни эшләрбез, без бит ул чакта, зур таш өстендә торган зур йомырканы икенче бер зур таш белән бәргән кебек сытылып калачакбыз...

— Калмассыз!.. Сез бит тавык йомыркасы түгел. Сезнең җаннарыгыз бар. Рязе забой җимерелүеннән куркып, шундый бай урынны эшләп бетерми, ташлап чыгарга ярый? Менә тиздән икенче шурфлар өлгерәләр, озакламый шунда күчәрсез.

— Алар өлгергәнче без үлем көтеп яшәргә дигәнмени? Әнә күрше шахтада эшләр урыннар күп бит, нигә безне шуларга күчермисез?..

— Сезне шул үлемнән качырып, бер урыннан икенче урынга күчер дә йөр, имеш! Сезгә һаман ансат булсын, аның кем җилкәсенә барып төшкәнен беләсезме?..

Эшчеләр, куллары белән җилкәләрен кагып:

— Ул менә безнең җилкәгә төшә.

— Ялгышасыз!.. Ул менә шушы зур эшләрне эшләтүче хуҗалар җилкәсенә төшә.

— Кем аркасында баеганнар соң алар. Алар миллионнарны тик яткан җирләреннән тапканнармыни?

— Миллионнарны табар өчен дә баш кирәк. Берегез дә бушка гына эшләп йөрмисез.

— Әллә инде безне бушка эшләтер идегезме?.. Акыллы башлар!..

— Бер миңа гына әйтмәгез. Монда бер мин генә түгел, әнә управляющийлар бар, барыгыз да, шуның белән сөйләшегез!..

— Син шулай һәрвакыт „эт эткә — эт койрыкка“ юлы белән барасың. Оренбургка барып, байларның үзләрен күреп сөйләшергә кушмыйсыңмы тагын?

— Как мин эт! Абайлап сөйләшегез. Алай бик эшлисегез килми икән, сезне беркем дә көчләп эшләтми. Дүрт ягыгыз кыйбла!..

— Без синнән кыйбла сорап тормыйбыз, рас монда эшләү опасно икән, ташларга кирәк...

— Ташлар вакытны правление сездән сорап тормас!..

Штейгер белән эшчеләр арасында һәрвакыт шундый талашлар булып тора. Ләкин шахтада эшләүне һаман туктатмыйлар.

Кайберәүләр бу шахтада эшләүдән бөтенләй баш тарталар. Эштән „баш тартучы“ эшчеләргә, бу прискада икенче бер эш бирелмәгәнгә күрә, алар талашып расчет алалар да, икенче приискаларга китәләр.

Берничә көннәргә сузылган талашлы һәм эшчеләр өчен соң дәрәҗәдә куркынычлы булган бу мәсьәлә табигатьнең үзе тарафыннан чишелде.

Беркөн иртән эшчеләр эшкә китәргә җыенганда, беренче номерлы шахтаның җимерелүен хәбәр иттеләр.

Шахта беркемнән дә сорап тормаган, меңәрләгән терәүләргә карамый, аларны йомычкага әйләндереп, убылган да төшкән...

Аның төнлә белән, эшчеләр юк вакытта җимерелүе анда эшләүчеләр өчен шатлыклы бәйрәм булды. Һәркемнең авызында:

— Ярый әле, безнең бәхеткә каршы, төнлә белән җимерелгән!.. Әгәр дә эш вакытында убылган булса, бер генә кеше дә исән калмас иде.

— Без ул шахтаның тиздән җимереләчәген атна буена әйтә килдек. Ләкин администрация безнең сүзне колагына да элмәде...

— Аларның үзләрен шунда эшләтергә кирәк иде, эшнең ничек икәнен белерләр иде,— дигән сүзләр йөрде.

Шахтаның җимерелүе аркасында, прииска идарәсе белән эшчеләр арасында байтак талашлар булып алды: шушы мөнәсәбәт белән кайбер эшчеләр билгесез вакытка кадәр эшсез калдылар; кайсыберләре икенче бер эшкә күчерелделәр; кайбер „телләре бик озын“ кешеләргә, мондый „кечкенә мәсьәлә“не зурайтып йөрүчеләргә, бөтенләй эш бирелмәгәнгә күрә, алар, бу приискага кул селтәп, икенче эшләргә чыгып киттеләр...

Бу приисканы ташлап китүчеләр арасында, аркасында керле капчыкларыннан башка бер йөкләре дә булмаган буйдаклар булган кебек, берничә балалы, үзләренә күрә эшчеләрдә була торган вак-төяк нәрсәләре булган семьялы кешеләр дә бар иде. Бу соңгыларының кайберләре хәлләре житкән җиргә кадәр ат яллап китсәләр дә, кайберәүләре әйберләрен кечкенә кул арбаларына төяп, бәләкәй балаларын шунда утыртып, зуррак булганнарын җитәкләп, мең төрле михнәт белән моннан китәргә хәзерләнәләр иде. Шулай китүче эшчеләрнең йөзләре ачулы, балаларының күзләре яшьле, хатыннарының битләре моңлы булып, аларны карап тору күңелгә соң дәрәҗәдә авыр тәэсир бирә иде.

Бу приискада калучылар, китүче иптәшләренә карап:

— Сез барган җирдә эшләр шәп булса, хат җибәрегез, без дә барырбыз,— дигән теләкләрен белдерәләр. Китүчеләр:

— Ярый, бик ярый! Тик бит әле безнең кайда баруыбыз, анда баргач, эш булу-булмау билгесез,— дип, үзләренең киләчәкләре турында бернәрсә дә белмәүләрен әйтәләр иде.

Китүчеләр, бер төркем булып, прискадан кырга таба күтәрелгән юл белән әкренләп кенә алга киттеләр. Алар бик әкрен баралар, нигәдер еш-еш тукталып, бәләкәй арбаларын рәтлиләр, шуннан тагын да кузгалып, алга елышалар иде.

Нәкъ шул вакытта биек кырның өстеннән кыңгырау тавышлары ишетелде, шуның белән бергә, өчәр ат

җиккән өч-дүрт повозканың, пыр туздырып, приискага таба килүләре күренде. Эш эзләп китүчеләр төркеме, аларга юл бирер өчен, чак-чак төрле якка таралып өлгерделәр.

Бер-берсен таптардай булып килгән тройкаларның туп-туры приискага килгәнен күргән эшчеләрнең:

— Байлар киләләр!..

— Ну-да, соң үзләре дә йөри беләләр...

— Аларның атлары да бит солы өстендә генә торалар...

— Алар кебек кесәңә туктаусыз алтын агып торса, без дә шулай йөрер идек...

— Шакир абзый белән Закир абзый икәвесе дә хатын, балалары белән киләләр ахры...— дип сөйләгән сүзләреннән мин ул килүчеләрнең прииисканың хуҗалары икәнлекләрен аңладым.

Ул тройкалар, пыр туздырып, теге кыш көне буш тора торган яшел түбәле йортларның капкасыннан кереп киттеләр.

Эш эзләп китүчеләр төркеме, бәләкәй арбаларын юлга төшереп, артларына карый-карый күздән югалдылар.

Минем белән рәттән торып карап торган Сибгать бабай бик авыр сулады да:

— Шулай! — диде.

— Шулай!..

Шахта җимерелү аркасында күптән эшләп килгән эшчеләрнең байтагы эшсез калганда, стажлы эшчеләр кул астында эшләгән минем кебек яшь кешенең эшсез калуы бик мәгълүм һәм табигый иде. Миңа да берничә көн эшсез калырга туры килде. Ләкин эшсез калу миңа авыр булып сизелмәде. Чөнки мин ялгыз. Минем акча табуымны, азык алып кайтуымны көтеп торган, ике-өч көн эшсез тору белән генә ач калачак семьям юк.

Семьялы кешеләр өчен эшсезлекнең авырлыгы бик тиз сизелә. Ата-аналарының җим китергәнен көтеп, авызларын ачып торган сыерчык балаларына охшаган балалары, байның шахтасы җимерелү белән дә, эшсезлек мәсьәләсе белән дә исәпләшеп тормыйлар. Аларга бүген табып, бүген ашатырга кирәк...

Өч-дүрт көн эшсез йөргәннән соң, миңа да эш табылды. Мин вашгердта алтын песогы юучыларга су тартып тору эшенә ялландым.

Мин өй түбәсеннән су агар өчен куелган тимер труба юанлыгы озын тимер трубадан су тартып чыгарып торам. Шул суда ике кеше көрәк белән алтын комын юалар. Су тартып тору комны юуга караганда авыррак булганга күрә, бу эштә күбрәк ирләр була. Хатын-кызлар юалар.

Буа буйлап тезелеп киткән шундый вашгердлар берничә дистәләргә тулалар.

Бу эш үзе яхшы ук авыр булса да, бердән, җир өстендә булганга, икенчедән, күп кешеләр, шулар арасында хатын-кызлар да эшләгәнгә күрә, җиңел төсле күренә.

Монда эш кайный, шуңа күрә күңелле...

Эш бик каты каравыл астында бара. Нарядчиклар вашгерд иләгеннән юылган песоклардан күзләрен алмый, эшчеләрнең хәрәкәтләрен күзәтеп кенә торалар. Күрәсең, алар песок арасыннан самородок килеп чыгар да, эшчеләр алырлар, вашгердка алтын бөртекләрен җыяр өчен терекөмеш тирәсенә җыелган алтыннарны әләктерерләр дип курка торганнардыр...

Аларда эшчеләргә ышанмаучылык бик көчле. Шуның өстенә йөзләре чытык, үзләрен бик югары тоталар. Шулай да монда хатын-кызлар күңелле. Алар, үзләренең күп эшләп аруларына карамастан, эш араларында җырлау, бер-берсе, хәтта ирләр белән уйнаудан ялыкмыйлар.

Эшләрнең барышын карау, аерым хәл җыярга туктаган вакытлардан башка вакытларны эшчеләрне бер минут та тик тотмыйча эшләтү — нарядчикларның бурычлары.

Байлар килгәннән соң, бу контрольлек тагы да көчәйде.

Шулай ныклы контроль астында эш кайный. Менә бүген шулай эш кайнап торганда:

— Байлар килә! — диделәр.

Без башыбызны күтәреп караганда, теге яшел түбәле өйләр ягыннан байлар белән управляющийлар әкренләп кенә без эшләгән җиргә таба киләләр иде.

Алар безгә якынлашкан саен нарядчикның йөзе үзгәрә башлады. Эшчеләргә күзләре белән боерык биргәндәй булып, төрмә каравыллаган борынгы солдатларча, вашгердлар тирәсендә әрле-бирле йөрергә керешге. Ул үзенең эчке тойгысын, байларга ярарга тырышуын, үзенең эчендә генә саклап тора алмады:

— Байлар килгәндә, кулларыгыз эштә булсын! Алар сезне күрер өчен түгел, мондагы эшнең порядкасын карарга киләләр!— дип боерык бирде һәм юар өчен вашгердлар янына китерелеп түгелгән алтын песокларын шунда ук бер җиргә өйдереп куйдырды.

Эшчеләр, туктаусыз рәвештә, аерым бер кызулык белән эшкә керештеләр.

Байлар буаның теге як башыннан башлап, һәрбер вашгерд янында бераз туктап, управляющийлар белән нәрсә турындадыр сөйләшеп бераз торганнан соң, әкренләп алга атладылар. Алар шулай әкренләп безнең янга килеп җиткәнче, сәгатьләрчә вакыт үтте. Байлар килгәндә, эшчеләр эштә булырга тиеш булганга күрә, эш туктаусыз дәвам итте. Беләкләр талдылар, күз аллары караңгылана башлады. Йөрәкләр еш-еш тибеп, тын алу авырлаша башлады.

Алар безнең янга килеп җиттеләр дә тагын туктадылар. Аларның күзләре безгә түгел, иң элек безнең эшкә ташланды. Нарядчик аларга честь биреп, рапорт ясарга хәзер торган бер кеше хәленә төште. Ул үзен нигәдер алар алдында гаепле санаган бер кеше сыйфатына керү белән бергә, үзенең өстенә йөкләнгән эшләрне соң дәрәҗәдә яхшы башкаруын белдерергә теләгән кебек, бер безгә, бер байларга карады.

Байлар, гүяки, монда бер кеше дә юк кебек, тик нарядчикның баш июенә каршы ияклəрен кактылар да эшчеләргә бер сүз генә дә әйтмәделәр.

Байлар икәвесе дә гәүдәгә бертигез, озын һәм пар аргамак кебек килбәтле, таза кешеләр. Аларның зур куе кара мыеклары, тулы битләренә матурлык биреп, байлыкларын күрсәтеп торгандай күренә.

Өс киемнәре европача булса да, үзләренең татарлыкларын, икенче төрле әйткәндә „мөселманлыкларын“ саклар өчен башларына кара түбәтәйләр кигәннәр. Аларның шәм кебек туры булуларыннан һичбер эш белән мәшәкать күрмәгәнлекләре беленеп тора.

Эшчеләргә алар алдында эштән туктарга ярамаганга күрә, эш гадәткә караганда да кызурак бара. Тимер иләк өстендәге вак таш катыш балчыклар юылып читкә ташланалар. Алар үзләрен бик җитди һәм эре тоталар, йөзләрендә көләчлек яки хәлдән таеп барган хатын-кызларның битләреннән агып төшкән тирләрен күреп аларны кызгану хисе һәм, авыр хәлдә икәнлекләрен

аңлап, эштән туктатып тору теләге күренми. Алар алдында эшчеләр үзләрен ниндидер бер куркыныч нәрсәләр алдында торган кебек хис итеп, үзләрен байларга бурычлы һәм шул бурычны үтәргә тиеш төсле аерым бер кызулык белән эшлиләр.

Күңелләр аларның тизрәк китүләрен, сәгатьләр буенча һич туктаусыз эшләп арыган беләкләрен ял иттерүне көтәләр... Ләкин алар эшчеләрнең, бигрәк тә хатын-кызларның аяктан егылырлык булып аруларын сизмиләр, яки сизсәләр дә, алар белән исәпләшергә кирәк тапмыйлардыр, ахры.

Шул арада теге яшел түбәле өйләр ягыннан, җәйнең эссе көненә карап киенгән, чәчәкләрдән чәчәкләргә очып йөргән күбәләкләр кебек, 8—10 яшьләрендә ике кыз йөгереп килделәр.

Аларны күрү белән байларның йөзләре көләчләнде. Алар, килү белән назланып һәм иркәлек күрсәтеп, әтиләренең итәкләренә сарылдылар.

Аларның әтисе, аркаларыннан сөеп, кызыл ефәк тасма белән бант ясалган чәчләреннән сыйпады да:

— Былбылларым, шулай балчык арасында йөрергә ярыймыни? Башыгызга эссе кабар бит!.. Монда нигә килдегез?— диде.

— Әннәләр сезне көтәләр...

— Ярый, хәзер!

Шул кызлар килгәннән соң гына, байларның берсе түш кесәсеннән алтын сәгатен алып карады һәм үзенең туганына нәрсәдер әйтте. Шуннан соң гына алар әкренләп алга киттеләр.

Алар киткәч, эшләүчеләрнең өсләреннән авыр йөк төшкән кебек булып калды, һәм, алар ераклаша төшү белән, һәркем эштән туктап, әрле-бирле селкеп талган кулларын яздылар...

Һәркем шунда ук хәл җыярга утырды. Тәмәке тартучылар махорка кәгазьләрен төрә башладылар. Хәл җыю арасында сүз байлар хакында булды. Эшчеләрдән берәү:

— Менә күрдегезме?.. Безнең байлар шулар инде,— дип сүз башлады. Һәм аларның басып торган урыннарын кулы белән төртеп күрсәтеп:— Менә шунда торганы, теге алтын сәгатне алып караганы, Закир исемле аның. Ә тегесе, теге балаларны сөйгәне — Шакир абзый...

Икенче бер эшче:

— Ну, үзләрен эре күрәләр дә икән соң!.. Мин

мондый гөрбиян кешеләрне күргәнем юк. Без „Иванов“ рудникгында эшләгәндә, хужа килсә, һич булмаса, башын иеп исәнләшә торган иде... Ә болар безне бар дип тә белмәделәр. Ачуыңнан шартларсың...

— Синең шартлавыңа аларның исләре китәр дип беләсеңме әллә? Үткән ел Вәли абзыйны балчык басып үтерде, алар аңа „ә“ дә димәделәр. Җиңги ике баласын иялтеп бернәрсәсез өч йөз чакрым җиргә җәяү кайтып китте. Аларның күңелләрендә миһербан булса, шуны кызганып ярдәм итәрләр иде.

— Шундыйларны уйласаң, чорт возьми, йөрәк әлләни эшләп китә! — Ул шул сүзләрне әйтте дә, кулындагы тәмәке төпчеген җиргә атып бәрде.

Өченче берсе салмак кына тавыш белән:

— Юк инде, малай, әллә безнең бәхет юк, әллә үзебез берәр нәрсәгә төшенмәгәнгә шулай кеше себеркесе булып йөрибез? Ә алар үзләре елына монда бер рәт килеп карап кына китәләр, шулай да пычаклары май өстендә.

Тәмәке төпчеген атып бәрүче:

— Нәрсә бәхет сөйләп утырасың, бәхетне беркемдә китереп бирми аны. Үзең табарга кирәк. Былтыр әнә теге озын буйлы, урысча оста егет безгә сөйли торган иде бит,— дип, нәрсәдер сөйләргә теләгән иде, аның иптәше каршы төште:

— Теге нәрсәнең (нарядчикны әйтә) башы кара бодай саламы белән ябылган (татарча да аңлый димәкче була), теге егетне дә шул әрәм иттерде, диләр бит...

— Тапкансың куркыр кеше, менә миңа бәйләнеп кенә карасын!..

— Ул синең белән бәйләнеп тормый, тиешле җиргә барып әйтә генә икән...

— Әйтсә, чәчрәп китсен! Кайда булса да шундый эшкә җибәрерләр, миңа барыбер.

Сүз шунда җиткәндә, нарядчик сәгатен карап:

— Ну, егетләр, сүз бетмәс, әйдәгез эшкә! — дип, ачулы тавыш белән әмер бирде һәм кайберәүләрнең эшкә башламый торуларын күргәч:

— Я, нәрсә тагын, аркагызга таш аскан кебек, кузгалмый торасыз? Монда акыл сатып, сөйләшеп утырыр өчен килдек дип белдегезме әллә?

Аның бу сүзеннән соң эшчеләр һәммәсе дә эшкә керешсәләр дә, эш аралаш кайберәүләр аңа бәйләнеп

тә алдылар. Ләкин бу бәйләнеш озакка бармый басылды, тагы да элекке кебек эш башланып китте. Нарядчик ачулы кыяфәте белән, кабырганы аркылы тешләгән эткә ошаган мыегын борып, вашгердлар тирәсендә әрле-бирле йөрергә кереште.

Нарядчик ул бүген генә түгел, һәрвакыт шулай грубый булып, бөтен эшчеләргә ачулы төсле йөри, әгәр дә үзе белән эшчеләр арасында талаш, тартыш китсә, тырпаеп торган мыекларын борып, әрле-бирле атларга керешә иде... Күрәсең, аның шул сыйфаты өчен байлар да, управляющий да аны ярата торганнардыр...

Бер дә уйламаганда, „Восьмой“ приискасына Тройцкида минем белән бер мәдрәсәдә укыган өч шәкерт килеп чыкты.

Алар берничә приискага барып, кайберсендә юллык һәм ашарлык эшләгәннәр дә, йөри торгач, монда килгәннәр икән.

Аларның килүләре минем өчен бик күңелле булды. Алар приискага килгәч, җәй тору өчен соң дәрәҗәдә күңелсез булган казармада торасылары килмәде. Шуның өчен, башка сезонниклар кебек, болар да палатка тектереп, землянкалар артындагы яшеллеккә палатка корып, шунда тора башладылар. Алар мине дә үзләре белән бергә торырга чакырганга күрә, Сибгать бабайлар белән исәп-хисапны өзеп, мин дә аларның палаткаларына чыктым.

Ямь-яшел үләннәр өстенә корылган, аккош кебек киерелеп торган ап-ак палаткада тору, әлбәттә, бик күңеллегә әйләнде.

Минем бу яңа иптәшләрем, хәзергечә әйткәндә, Зилаер контонынннан, „Ирәндек“ таулары тирәсендәге авылларның башкорт егетләре булып, шуннан Тройцкига укырга барганнар, бу ел авылларына кайтмыйча, монда эшкә килгәннәр иде[1].

---

[1] Шушы прискада, аннан соң Орск өязендә алтын разведкасында бергә йөргән бу иптәшләремне әле дә исемнән чыгара алмыйм. Алар: Фәйзулла, Шакир һәм Лотфулла исемле егетләр булып, һәрвакыт „Ирәндек“ тавын, „Кызыл“ суын һәм „Төмәс“ авылын бик сагынып сөйли торганнар иде. Фамилияләрен белмим. Хәзер аларның берсе исән булса, мин аның белән хат язышкан булыр идем. *М. Гафури.*

Хәзер безнең уртак тормыш башланды. Аш пешерү һәм чәй кайнату өчен алмашлап беребез палаткада кала, калганнарыбыз эшкә бара идек. Эш булмаган көнне юылган алтын песоклары арасыннан „самородок" эзләргә барабыз. Аннан ялыккач, сахрада йөрибез.

Бу араларда безнең эшсез көннәр байтак булды.

Фәйзулла курай уйнарга оста гына икән. Ул, тик торуның күңелсезлеген каплар өчен, каяндыр курай табып алып кайтты. Ул үзенең өске ирене белән курайның башын ябып, иренен калтырата-калтырата уйный, Шакир „Ирәндек" көен вә башкаларны җырлап аңа кушыла, без аларның курай уйнап җырлауларын тирән уйга калып тыңлый идек.

Курай, җыр безнең палатка тирәсен җанландырып җибәрде. Күрше палаткалардагы эшчеләр һәм хатын-кызлар да, безнең тирәгә җыелып, күңел ача торган булып киттеләр... Бу эш, безнең өчен дә, алар өчен дә күңелле булып, үзенә күрә кечкенә бер концерт төсен ала торган иде.

Көн аяз. Кояш, Урал тауларына карап, түбән төшеп бара. Ул хәзер, безгә таба артына әйләнеп көлеп, китеп барган кебек күренә.

Бүген дә эшкә бара алмаган кешеләр капыл гына, нигәдер, прискадан сөзәкләнеп, югары күтәрелгән кыр өстендәге вак кына каенлыкка таба карап йөгерешә башладылар.

Аларның ашыгып йөгерүләренә караганда, каенлык эчендә нинди дә булса мөһим бер вакыйга булуы күренеп тора иде. Без дә, палаткадан чыгып, ашыга-ашыга шулай таба йөгердек.

— Нәрсә бар анда?

Ашыгып баручыларның берсе бик зур әһәмият биреп:

— Ат башыдай алтын табылган!— диде дә безне узып китте. Икенче берәвесе:

— Үзен күтәреп тә булмый икән!— дигән сүзне өстәде.

Ат башыдай алтын!

Без баруыбызны әкренәйтә төштек тә, „ат башыдай алтын" турында сөйләшә башладык.

— Ничек табылды икән?

— Аны табучы нинди бәхетле кеше!.. Башкалар

монда күгәрчен күкәе чаклы самородок таба алмыйлар, ә ул кеше „ат башыдай алтын“ тапкан.

Халык телендә — „ат башыдай алтын бирсәң дә, ул эшне эшләмәм...“ дигән сүз йөрсә дә, вакыйгда, җир астыннан „ат башыдай алтын“ табылуына күп кешеләр ышанмыйлар, ә үзләре, шулай булса да, шуны күрергә ашыгып йөгерәләр.

Тауга каршы ашыгып бара торгач, безнең хәлләр бетте. Кайберәүләр, тыннары бетеп, артта кала башладылар.

Ниһаять, без бара торгач, вак кына каенлык арасындагы бер ялан җиргә барып чыктык.

Анда җыелган халык төркеме, түгәрәкләнеп, исләре китеп карашып торалар.

Без, кешеләр төркеме янына барып җитү белән, „ат башыдай алтын“ны тизрәк күрәсебез килеп кысыла-кысыла уртага кердек һәм күзләребезне мәйдан уртасына аттык.

Иң элек кечкенә мәйдан уртасына җәелгән кып-кызыл персидский палас өстендә утырган байларга күзебез төште.

Ни күзебез белән күрик, чынлап та, байларның алдында ат башы чаклы кызгылт һәм кытыршы бер таш. Ул гына түгел, шул зур кисәк янында йодрык һәм аннан кечкенәрәк тагын берничә кисәк кызгылт нәрсәләр торалар.

Бу нәрсәләрне үз күзебез белән күргәч, безнең гаҗәпсенү тагы да артты. Кешеләр, алтын кисәкләрен тагын да якыннанрак күрер өчен бер-берсен этеп, алга җыелыша башладылар. Ләкин шунда каналга куелган стражник кешеләрне читкә куарга кереште. Кешеләр артка чиктеләр. Безнең күзләр һаман да алтын кисәкләрендә: аларның иң зурысы чынлап та ат башы чамасында булса да, ул саф алтын булмый, тимер рудасы кебек кызгылт тузанга манчылган таш белән аралаш булып, шул ташның арасыннан йөргән бармак юанлыгы алтын тамырлары күренеп торалар иде. Кечкенә кисәкләрдә дә алтын шулай ук кызгылт таш белән аралашкан.

Бу „ат башыдай алтын“, үзенең кечкенә балалары кебек булган бәләкәй алтын кисәкләре белән, өч чирек чамасында гына тирәнлектән, чирәм астыннан чыккан икән.

„Ат башыдай алтын“ны табучы — Урал ягыннан килгән башкорт агае. Ул һаман байлар һәм стражник карамагы астында шул тирәне казый. Хәзер ул үзенең аруын да, ашау-эчүен дә оныткан төсле күренә.

Кем белә, ул үзенең шундый зур хәзинә табуы шатлыгы белән эченнән әллә нәрсәләр уйлый торгандыр...

Ул, шулай ашыгып, бөтен көчен биреп кавый. Аның маңгаеннан агып төшкән тирләре, тузанга манчылган йөзендә эз калдырып, түбән агып төшкәннәр.

Байлар үзләренең күзләрен алларында яткан „ат башыдай алтын“ өстеннән җир казучы башкорт агае алдына төшергәннәр. „Ат башыдай“ гына алтын аларны канәгатьләндереп бетми, күрәсең. Аларның күзләрендә шатлык юк. Алар ни өчен шатлана алмый торганнардыр, аны кем белә?

Бераздан соң байларның зурысы, стражникны янына чакырып, аның колагына нәрсәдер әйтте. Стражник шунда ук карап торучыларны, бу җирдән китәргә кушып, куарга кереште.

Без көлә-көлә кайтып киттек, байлар ачулы күзләре белән иран паласы өстендәге „ат башыдай алтын“га карап калдылар.

Без хәзер җайлап, рәхәтләнеп кайтабыз.

Юлда кайтып баручыларның авызларында тик шул „ат башыдай алтын“ хакында сүз бара:

— Вәт, малай, ат башыдай алтын кайда гына яткан бит!.. Без шуның өстеннән атлап йөргәнбез...

— Аны табучы агай бәхетле инде!.. Ул бүгеннән соң бер дә эшләмәсә дә тора алыр. Аның калган гомеренә җитәрлек наград бирерләр...

— Күпме булыр икән?

— Алтынны ташларыннан аерып алып үлчәгәч, беленер әле.

— „Милиюм“[1] тәңкәлек алтын бардыр анда!..

— „Милиюм“ булмас булуын да, шунда да күп булыр инде.

— Тик торган җирдән байларга шулчаклы алтын керсен әле, ә? — дигән сүзләр агып торалар.

[1] Милиюм — миллион.

Без иптәшләр белән башкорт агаена очраган бәхетнең безгә дә очравын өмит итәбез. Безнең күңелгә хәзер һәр җирдә алтын булыр төсле күренә. Шуңар күрәдер инде, безнең бер иптәш, юлда очраган зуррак, кызгылт ташларны кулына алып әйләндереп-әйләндереп карый да ташлап китә.

Бүген кичке чәй вакытында һәрбер палатка, һәрбер землянка һәм казармаларда шул „ат башыдай алтын“ хакында сүз бара торгандыр инде.

Кичке чәйне кайнатып эчәргә утыру белән, безнең дә беренче сүз шуннан башланды.

Безнең Шакир дигән иптәшебез беркатлы ачык кеше иде. Ул сүз арасында:

— Ну, малай, шул алтын миңа табылһа, мин ни эшләргә белер инем! — диде.

Аның бу сүзе безгә бик кызык тоелды. Без аннан:

— Я, шул алтын сиңа табылса, ни эшләр идең? — дип сорадык. Ул бер дә уйлап тормый:

— Төмәскә[1] кайтып, бик шәп йорт һалдырыр инем дә... фәлән байның кыдын алып, һедде кунакка сакырып, атна-ун көн бик яхшы һыйлап, үдегедгә аксалар биреп, Троицкига укырга ебәрер инем, — диде.

Без аның бу сүзеннән көлештек һәм:

— Ул бай сиңа кызын бирер микән соң? — дигән сөальне бирдек. Ул һаман да шулай бик гади иттереп:

— Бирмәй ни ди, аксаң күп булһа, үддәре сакырып бирерләр, — ди.

— Аның кызын күргәнең бармыни соң?

— Үткән яй бед уларга утын ташыгайнык. Шунда ул беддән касмай йөренә. Бедден менән һөйләшеп тә тордо. Үде тап мәрия кыды кебек: оялып-нитеп тороудо уена да килтереп сыгармай...

Аның бу сүзләреннән без тагын көлдек. Ләкин ул безнең көлүебезгә ачулану түгел, үзе катнашып китте:

— Бәй! уның нәмәһеннән көләһегед? Улай булгас, шундай алтын тапһагыд, һед ни эшләр инегед? — дип, безнең фикерне сорады.

Лотфулла аз гына уйлап торды да:

---

[1] Төмәс — элекке Орск өязендә яртылаш шәһәргә әйләнеп барган зур бер авыл. Анда бик күп рус һәм татар сәүдәгәрләре урынлашып, тирә-яктагы башкортларны имеп ятканнар. *М. Гафури искәрмәсе.*

— Мин бүгеннән Троицкига кайтып, бер җиргә дә китми, җәен-кышын шунда ятып укыр идем,— диде.

Шакир аңа каршы:

— Пустәкте уйлайһың. Шундай күп аксам булһа, баш ватып укып тораммы һуң!..— диде.

— Бер дә пустәк түгел. Бер укып сыкһаң, дүрт ягың кыйбла булып, гомергә бер эш тә эшләмәй ятаһың бит!

Алтын табылу турысында сөйләшә торгач, чынлап та, безнең кесәдә хәзер үк алтыннар тулып яткан кебек булып китте.

— Ә һин һуң ней эшләр инең?—дип, минем дә уемны сорадылар.

— Табылмаган алтын белән ни эшлисең?

— Юк, бәлфәраз табылһа?

Алар шулай дигәч, җавап бирү турысында авыр хәлдә калдым. Үземне аларга җавап бирергә мәҗбүр кебек сиздем. Алар әйткәнчә, шулай „ат башыдай алтын“ түгел, бәхеткә каршы берәр кул кисәге чаклы алтын табыла калса, нәрсә эшләр идем икән? дигән уйга төштем.

Мин инде бу вакытта, кайдандыр кулга төшереп, Каюм Насыйриның „Җәгърафияи кәбир“ен, Төркиядә басылган кайбер нәрсәләрне укып тәрәккыйләшә[1] башлаган идем. Шуларны уку минем күңелемдә читкә китү фикерен тудырган иде.

(. . . .)

Иптәшләрнең соравы уңае белән, минем шул теләгем күз алдыма килеп басты һәм миңа да берәр көнне алтын табылырдай булып китте дә:

— Әгәр миңа шундый алтын табыла калса, сезнең белән уртаклашыр идем дә, үземә дигән өлешемне акчага әйләндереп укырга китәр идем,— дидем.

(. . . .)

Алтын табылса, ни эшләү фикерен әйтү чираты Фәйзуллага җитте. Без аңа карап:

— Я, Фәйзулла, алтын тапсаң, син нәрсә эшләр идең?—дидек.

— Мин, үз өлешемә дигән алтынны алу белән, авылга кайтып шунда тора башлар идем...

— Син бигрәк тә пустәкне уйлыйсың,— диде Лотфулла.

---

[1] Тәрәккыйләшә — алга китә.

— Нигә пустәк булсын? — ди.

— Пустәк булмыйни, кеше, укуны ташлап, авылга кайтамы соң? Авылда ни кызык бар анда?..

„Ат башыдай алтын“ таба алсак, үзебезнең ни эшләргә теләгән фикеребезне яклап бик озак сөйләшкәннән соң гына ак палатка астына йокларга киткәнбез.

Иртән торуга, кичә безнең сөйләгән хыялларыбыз күңелләребездән юылып алынып ташланган бер хәлдә, эшкә киттек...

Эш арасында һаман шул „ат башыдай алтын“ турында сүз бара иде.

Эшчеләр арасында, кичә табылган алтыннарны ташлардан аерып үлчәгәч, бер пот та утыз биш кадак саф алтын[1] чыгуы сөйләнә, бу эшкә һаман да һәркем хәйран кала иде.

Алтынның бер пот та утыз биш кадак икәнен ишетү белән, һәркем бер-берсеннән:

— Ә аны тапкан башкорт агайга күпме, ничә мең тәңкә награт бирделәр икән соң? — дип сораша башладылар.

„Бер йөз тәңкә награт биргәннәр икән...“ хәбәре шунда ук таралып өлгерде.

— Булганы бер йөз тәңкәме?..

— Әйе, бер йөз. Мин ул агайның үзен күрдем, аның үзенең авызыннан ишеттем.

— Аз, бик аз. Ат башыдай алтын табып биргән бер кешегә йөз тәңкә негратмыни ул! Һич булмаса, бер мең сум бирергә кирәк иде.

Башкорт агайга йөз генә тәңкә награт бирелүенә һәркемнең эче пошты. Һәркем байларның жадныйкомсызлыкларына аптырашка калды:

— Оятсызлар! Алай иткәнче, лутчы бирмәскә кирәк иде.

— Башкорт агай аны алмаска, үзләренең йөзләренә бәреп китәргә кирәк иде!

— Алмасаң, байларның исләре китәр дип беләсеңме әллә?

---

[1] Чынлап та, бу урыннан шундый зур кисәкле алтыннар табылуы бик сирәк була торган вакыйгалардан икән. Шуның өчен бу вакыйга шул вакытта рус газеталарында да аерым хәбәр булып басылган иде. *М. Гафури.*

— Әйдә, алсын. Дуңгыздан бер кыл! — дип, эшчеләрчә сүгенеп тә алдылар.

Без кичен эштән кайткач, тагын шул алтын турында сүз башладык. Һәм акчага әйләндергәндә күпме булачагын исәпләргә керештек.

Иң элек Лотфулла, бармаклары белән санап:

— Мыскалы биш тәңкәдән — бер мыскалы биш тәңкә, ун мыскалы йөз тәңкә...

— Вәт, дурак, ун мыскал йөз тәңкә булсын, ди! Илле сум диң.

— Ну, илле тәңкә булсын. Бер кадакта ничә мыскал була әле?

— Туксан дүрт...

— Юк, туксан алты мыскал була.

— Ну, чама белән әйткәндә, йөз мыскал булсын, ди. Йөз мыскал алтын бишәр тәңкәдән биш йөз тәңкә була. Вәт кайда китә ул.

Бераз санагач та, безнең бармакларның саны бетте. Акчаның саны бик күпкә китә башлады. Җепнең очын югалттык, саннарны саташтыра башладык.

Шакир, бик озак уйлап торганнан соң:

— Ун мең тәңкә бер миллион була түгелме? — диде.

Безнең кайсыбыздыр аңа каршы:

— Юк, мең җирдә мең бер миллион була, — диде.

Санның болай күпкә китүе безнең башларыбызны тагын да ныграк әйләндерде.

Безнең кара хисапка караганда, „ат башыдай алтын" бер исәпләгәндә йөз мең, икенче исәпләгәндә әллә ничә миллионга китте. Ничек тә ул акчаларның күплеген безнең башлар сыйдыра алмады. Шуның өчен исәпләүне ташладык.

Лотфулла башын селкеп:

— Вәт, әй, байлар тик торганда, теге агай аларга нинди зур хәзинә табып бирде. Ә аның үзенә — булганы йөз сум биргәннәр...— диде.

— Тик торганда, ул да ярый инде.

— Нигә тик торсын ул? Җирне казып, алтынны табучы ул бит.

— Ә җир кемнеке?

— Байларныкы...

— Оренбурда торган байларга кайдан килсен, ди, ул җир?

— Чынлап та, җир кемнеке?

Без ул вакытта үзебезнең бу сөалебезгә җавап бирә алмадык. Чөнки җир мәсьәләсе һәм социализм хакында беребез дә, бернәрсә дә белми һәм бер китап та укымаган идек.

Шуның өчен: „Җир кемнеке?..“ сөале җавапсыз калды.

Соңгы ун-унбиш көн эчендә без приискадан бер чакрым чамасы болынлыкта (тугайсымак җирдә) дүртебез бергә разведкада йөрдек.

Аршины егерме тиен көмештән җир астына туптуры түгәрәк тишек (шурф) казып төшәбез. Гадәттә, алтын була торган балчык катламына җиткәч, бер-ике бадиян балчыкны юып карыйбыз. Бу эшләр, әлбәттә, штейгер карамагында эшләнә. Кайсы җирдә ничә доля алтын бөртеге чыга, яки бер дә чыкмый, шуңа карап, шул урынга багана утыртып, билге куеп китәбез. Соңыннан ул җирдә алтын казыту файдалымы, түгелме— аны байлар үзләре беләләр. Безнең анда эшебез юк. Ләкин бу разведка эше безнең өчен шәп „кәсеп“ булып төште. Һәр көн кеше башына берәр тәңкә төшереп кенә торабыз.

— Бер тәңкә!.. Бу аз акча түгел,—дибез.

Ун-унбиш көн эчендә болын кып-кызыл туфрак чүмәләләре белән чуарланды. Алты-җиде аршин тирәнлектәге коелар берничә дистәгә тулды. Без хәзер үзебезне прииcканың чын эшчеләре рәтеннән исәпләп йөри башладык.

Шимбә көн акча алабыз.

Шуны алыр өчен Фәйзулла белән Лотфулла конторага киттеләр. Без Шакир белән җир учакта аш пешерә калдык.

Әнә алар кайтып киләләр. Малайлар бик шат күренәләр. Ахрысы, безгә акча тигәндер...

Без икәвебез дә, аягүрә басып, аларны каршыладык:

— Ну, күпме акча тиде?

Алар, тел белән җавап бирми, чатырга керделәр, ашъяулыкның өстенә акчаларны актарып җибәрделәр. Бер учтай көмеш тәңкәләр өстенә, шулар арасында бишәр сумлык берничә алтын тәңкәләр ялтырап торалар.

Фәйзулла санарга кереште. Иң элек алтын тәңкәләрне алып:

— Бер, ике... алты... барысы утыз тәңкә, — дип, бер якка куйды.

Көмешләрне санагач, утыз ике сум кырык тиен булдылар.

— Алтмыш ике сум кырык тиен!..

Без бер-беребезгә караштык. Унбиш көндә шулчаклы акча эшләгәнбез, бу аз түгел.

Фәйзулла белән Лотфулла бер-берсенә карашып алганнан соң:

— Сезгә яңа хәбәр әйтикме? — диләр.

— Әйтегез, нинди хәбәр?

— Безне Орски ягына разведкага барырга кушалар. Безгә кирәк булган бөтен корал һәм атларны контора үзе бирә. Ә эш хакы болай: биш аршин тирәнлеккә чаклы аршины 20 тиен; аннан ун аршин тирәнлеккә чаклы 25; егерме аршинга чаклы — аршины 30 тиен; аннан да тирәнгә китсә, 30 аршинга чаклы, аршины 35 тиен...

— Ә аннан да тирәнгә китсә?..

— Аннан да тирәнгә китмәс, диләр.

— Кайчан китәргә.

— Иртәдән соңга китәргә. Безнең белән барачак штейгер безне бик димли. Анда сезгә яхшы булыр, ди, мин сезне конторага үзем әйттем, кадерен белегез, ди.

Без сөйләштек-сөйләштек тә барырга карар бирдек.

— Без инде иртәдән соңга китәрбез!..

Иртәнгесен без, эшкә бармый, үзебез белән алып китәчәк әйберләрне, арбаларны һәм коралларны кабул итү белән көн үткәрдек. Безнең сәфәр кирәк-яраклары әзерләнеп бетте. Йөрәкләр нигәдер тибәләр...

Кич белән мин семьялылар казармасына, Сибгать һәм Сәлим бабайлар белән күрешеп китәргә бардым.

Мин казармага барып керүгә, аның Сәлим бабайлар тора торган як башында байтак кешеләр җыелышып, нәрсә өчендер аптыраштa торалар һәм кемнедер кызганып сөйләшәләр иде. Мин туры шул кешеләр янына бардым. Сәлим бабайның хатыны мине күрү

белән: „Абзаң имгәнде бит“, — диде дә күзләрен яшьләндерде.

— Ничек, кайда имгәнгән?..

Ул яшьле күзләрен яулык очы белән сөртеп:

— Яңлышлык белән югарыдан агач төшеп, шуның бер башы аның кулбашына килеп бәрелгән. Ярый әле башына төшмәгән. Башына төшкән булса, шунда ук үләр иде, — диде.

Аның ыңгырашкан тавышы әллә кайдан ук ишетелеп тора иде.

Мин Сәлим бабайның янына бардым. Аның янында Сибгать бабай һәм аның хатыны вә башка берничә кеше, кулларын уып, ни эшләргә белми торалар:

— Кулбаш сөяге чыккандыр.

— Әллә кулбаш сөяге сынды микән? — дип сөйләшәләр иде.

Сәлим бабай чалкан төшеп ята, үзе һаман сызлана, сыкрана иде.

Хәдичә, картларның әйтүе буенча, бер иске күлмәкне ертып китерде. Аны тозлы суга манчып, Сәлим бабайның кулына һәм кулбашына бинт ясадылар. Бу вакытта аның сызлануына күп күзләрдән яшь килде. Хәдичә чыдый алмый, мичкә таба әйләнеп, елый башлады.

Байтак вакыт үткәннән соң гына Сәлим бабайның сызлануы кими төшкән кебек булды да, тирә-ягына карап алды. Шунда аның күзе миңа төште:

— Исәнме әле?

— Яхшы әле. Сезгә күрешеп китәргә килгән идем дә, сез бик зур күңелсезлеккә очрагансыз икән...

— Шулай булды инде... Кайда китәсең?

— Разведкага...

— Хәерле булсын... Кайтканда безгә төш.

— Ярый...

Мин, аны озак торуым белән борчымас өчен, күрешеп китәргә булдым. Ул миңа сул кулын сузды. Аның сөякле кулы ут кебек кызу иде. Күзгә карады да:

— Исән бул...— Аның күзе яшьләнде, мин тагы исәнләшеп, башымны иеп, аның яныннан киттем.

Сибгать бабайлар, әбиләр һәм башкаларның һәммәсе белән дә күрештем. Алар һәммәсе дә мине үзләренең бик якын кешеләре кебек кайта-кайта күрешеп, кайтканда үзләренә төшәргә кушып озаттылар.

Мин казармадан чыкканда, караңгы төшкән булып, каршымда бер карачкыл тора иде. Текәләп карагач, аның Хәдичә икәнен белдем.

— Китәсеңмени?

— Китәм шул...

— Нигә китәсең инде? Монда да эш бар бит...

— Шулай да, иптәшләр белән китәргә уйладым.

— Кире монда кайтасыңмы соң?

— Без бер-ике айдан кайтабыз.

— Безгә төшәрсең инде.

— Ярый.

Без аз гына сөйләнгәч, мин аңа кулымны суздым. Ул, кулын бирү белән бергә, миңа бер кәгазь дә тоттырды. Аның кулы эссе, ләкин кулга рәхәт бирә торган эссе иде.

Ул кәгазьне биргәч:

— Только бер кешегә дә әйтмә, зинһар, кеше белмәсен! — диде.

— Әйтмәм, бервакытта да әйтмәм.

Тагын күрештек. Казармадан кемдер чыккач, ул артка чигенде. Мин башымны идем дә аннан аерылып, караңгыны ярып, үземнең чатырга кайттым.

Мин кайтканда, иптәшләр ятканнар иде. Чатыр алдындагы ут яктысында Хәдичәнең биргән язуын укыдым. Ул бу хатны биргәндә: „Только бер кешегә дә әйтмә, зинһар, кеше белмәсен“, — дигән иде бит. Мин дә кешегә әйтмәскә вәгъдә бирдем. Шуның өчен ул бу хатка нәрсәләр язганын бу урынга теркәмәскә булдым. Чөнки мин ул хатны монда язсам, Хәдичәгә биргән вәгъдәмне дә бозган булыр идем. Ул бу хикәяне укый калса, миңа ачуланыр, һич булмаса, үпкәләр иде...

Иртәнгесен без бөтен коралларны, чатырны һәм үзебез өчен кирәк булган азыкларны төяп, шагыйрьнең алтын приискасыннан көньяк-кояш батышына карап чыгып киттек. Көн матур, чиксез матур иде. Прииска әкренләп артта калды. Шуның белән бергә анда минем йөрәгемнең бер кисәге калган кебек булганга күрә, прииска биек кырның артында калып югалганчы карап бардым.

Шулай прииска артка калган кебек, минем гомеремнең дә бер кисәге шунда өзелеп калды.

Сахра кешене җырлата, күңелләндерә бит. Безнең

иптәшләр җырлый башладылар. Тик мин генә уйланып бара идем.

Аларның җырларын ярылырдай булып шалтыраган кыңгырау тавышлары бүлде. Без артыбызга әйләнеп карауга, аннан өчәр ат җигелгән өч көймә (повозка) килә, җирне җимерердәй булып шәп киләләр иде. Бездән алда барган штейгер (ул трантаста бара иде), көймәле кешеләрне күрү белән, башлап үзе юлдан чыкты да безне дә юлдан чыгарга кушты.

Без юлдан чыгып та өлгермәдек, көймәләр безнең яныбыздан үтеп киттеләр. Штейгер аягүрә басып, аларга честь биреп калды. Ләкин алар ләм-ялтәфит[1] үттеләр.

Көймәләрнең өсләре кайтарылып салынганга күрә, ул көймәләрдә кемнәрнең барын без ачык күрдек. Анда прииска хуҗалары һәм аларның хатыннары вә балалары иде. Без алай-болай юлга төшкәнче, алар күздән яздылар. Тик тузаннары гына күренә башлады. Шунда штейгер безгә карап:

— Шакир, Закир Садыйковичлар... Алар Балкан приискасына баралар, — диде.

— Шулай, Шакир, Закир Садыйковичлар. Ну, үзләре дә йөри беләләр дә соң!..

Минем иптәшләр байлар турында штейгер белән сөйләшәләр, ләкин мин, аларның сүзләрен бер дә ишетмәгән кебек, уйда барам.

Күз алдымда прииска, казармалар, землянкалар, „ат башыдай алтын“, бергә эшләгән эшче иптәшләр, Сибгать бабайлар, Хәдичә, теге ямау ямап утырган хатыннар басып торалар.

Сәлим бабайның кичәге сызланулары колак төбемдә яңгырап торгандай булалар...

Бу яңгырау әллә яңа гына үткән кыңгыраулар тавышы, әллә Сәлим бабайның сызлану тавышы — мин аларны аера алмыйм...

Еллар үттеләр. Приискада эшләгән көннәр артта калдылар. Тик андагы күренешләр, эшчеләрнең авыр тормышлары, аларның төрле һәлакәтләргә очраулары, „ат башыдай алтын“нар, Сәлим бабайның имгәнеп

[1] Ләм-ялтәфит — илтифатсыз.

сызланулары, байларның кәеф-сафада йөрүләре һаман да күз алдында торалар.

Еллар үткәннән соң гына „Дәрдмәнд“ имзасы белән язылган шигырьләрнең иясе „Закир әфәнде Рәмиев“ булып, аның шул ук прискаларның хуҗасы икәнен белдем. Без шагыйрьнең алтын прискасында эшләгәнбез икән. Теге меңәрләгән эшчеләр һәммәсе дә Дәрдмәнднең хәзинәсен баетучылар булган икән.

Ләкин ул үзенең шигырьләрендә бервакытта да аларны искә алмый; күрәсең, аның „шәрекъ гыйшкы“ белән янган йөрәге алар өчен тибә алмаган.

Ул һаман үз сыйныфы өчен генә яна:

„Янды Мәҗнүн, янды Фәрһат,
Бер янып ат алдылар;
Мин гарип мең кат янып та
Янцыга саналмадым...“, — ди.

Ул аларның көчләреннән файдалануны шигъри калыпка сала:

„Әгәр илгә таратсаң бер хәзинә,
Бер акчадан төшәр һәр өй беренә;
Бер акчадан әгәр алсаң алардан,
Булыр һәр көндә хасил бер хәзинә“,—

дип, алар арасында хәзинәләр ясауны үзенең фәлсәфәсе итеп ала.

Ул үзенең „дәүләтенә“ карап, ходасына шөкер итә:

„Ни зур бу дәүләт кем — шөкер итәм чук:
Минем беркемгә җәбер итәр көчем юк...“—

ди. Һәм эшчеләрне тиргә батырып эшләтүләрен җәбергә санамый.

Ул үзенең аш пешерүчесенең каймак ашавыннан шикләнә:

„Ашчы каймакны капкан,
Мәчегә яла япкан!
Ышаныр микән бае,
Ни әйтер абыстае?“

дип, бер кабым каймак өчен аш пешерүчегә ышанмавын белдерә.

Ул үзенең дәүләте кулыннан киткәнгә, эшчәннәр хуҗа булганга, соң дәрәҗәдә кайгыра:

„Илаһи, калмасын көнең аларга,
Малыңны алсалар, сат башкаларга;
Борын биргәннәреңне дә кире ал!“

Ләкин ул малын башкаларга, чит ил байларына сата алмады һәм „биргәннәрен“ кире кайтарып ала алмады бугай.

Шуның өчен аның борынгы шатлыклары югала:

„Без генә идек без, гайреләр ят иде,
Бер җирдә идек, даим күңелләр шат иде“.

Революция капиталны һәм аның хуҗаларын пракәндә иткәч [1], алар тараладар. Инглиз, француз, рус байларының Уралдагы рудник, алтын приискалары белән шагыйрьнең алтын приискалары да эшчеләр хөкүмәте кулына күчәләр.

Хәзер аларда яңа эшләр эшләнә, яңа калыпка җырлар җырлана, көчле машиналар шаулый. Уралда хәзер магнитстройлар бара...

„Кара туфрак тулы мазлум нидасы [2].
Алар кемдер?.. Алар кемнәр нидасы?.“

Ләкин инде хәзер ул җирләрдә мазлум нидасы түгел, гигант заводлар нидасы гына ишетелә...

---

[1] Пракәндә иткәч — туздыргач, тараткач.
[2] Мазлум нидасы — изелгәннәр тавышы.

ӘЧТӘЛЕК

Шигырьләр

Хөррият иртәсе 5
Бетсен сугыш 7
Кызыл байрак 9
Ирекле көннәр 10
Аждаһа 12
Хөрриятк ә каршы торучыларга 13
Азатлык хөрмәтенә 14
Нур 15
Безнең юл . . 16
Җилбердәсен кызыл байрак 17
Татар егетенә 18
Бир кулыңны 19
Гаҗәпме 20
Гаһет 21
Урак белән чүкеч 22
Беренче Май 24
РКСМ 25
Корбаннар 27
Очар идем 28
Яңа көчләргә 30
Шахтер 31
Карт батыр теләге 32
Чит ил кунаклары. 33
Кызыл Армия 38
Май ае 39
Тормыш көрәше 40
Чит дошманнар 44
Гөлләр бакчасында 45
Тантаналы бәйрәм 47
Кошлар киткәндә 49
Тәнкыйть 50
Златоуст 52
Балаларга 56
Эш һәм белем 58
Кызыл гаскәрләр җыры . . 59
Себер истәлеге 60
Ягез, әйдәгез 63
Мин ватанчы 65
Ул үлмәде 66
Колхоз фронтында җиңүчеләргә 68
Болытсыз күк күкрәгәндә 72
Элекке „ул“ инде кеше булды 76
Дәртле яшьләр 80

Мәсәлләр

Сарыкны кем ашаган . . . 83
Ике чебен 85
Бабай белән аю 86
Тавык белән үрдәк 87
Песи һәм тычканнар . . . 89
Чикерткә белән кырмыска . 92
Җиләк белән алма агачы . 93
Ике каз белән бака 94
Әтәч белән сандугач . . . 96
Кәҗә тәкәсе белән көзге . 98
Ат белән эт 99
Сандугачлар 101
Ишәк 103
Кара елан белән бакалар патшасы 105
Үгез белән бүре 107
Эт белән куян 109
Кәҗә белән төлке 111
Маймун белән күзлекләр .112
Алмаз ташы 113
Җанварларга килгән үләт .114

Хикәяләр

Кыр казы 119
Яңа урак 128
Ялчы 135
Безнең әйберләрне сатканда 143
Хәзер ансат ул — элек кыен иде 154
Югалган актырнак 173
Корыган агачлар 223
Шагыйрьнең алтын приискасында 254

ПРОВЕРЕНО
07 СЕН 2016
подпись